# ТАТАРСТАН
# ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
# ҖЫЕЛМА БАСМАСЫ

*№ 7*
*июль*
*2013*

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
РӘСМИ БАСМАСЫ
Казан
2013

**ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ҖЫЕЛМА БАСМАСЫ:**
Татарстан Республикасы Дәүләт Советы рәсми басмасы

Формат 60х84 1/16. Тираж 95 экз.

© Татарстан Республикасы Дәүләт Советы, 2013

Эчтәлек

# I
# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОННАРЫ

963. «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил турында» *Татарстан Республикасы Законы* .............7

964. «Татарстан Республикасында торак төзелеше үсешенә дәүләт ярдәме турында» Татарстан Республикасы Законының 6.1 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» *Татарстан Республикасы Законы* ................16

965. «Югары Ослан муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» *Татарстан Республикасы Законы* ..........................................17

966. «Инвалидлар һәм социаль яклауга аеруча мохтаҗ гражданнар өчен эш урыннары квоталау һәм резервлау турында» Татарстан Республикасы Законының 6 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» *Татарстан Республикасы Законы* ..........................................20

967. «Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексының 5.1 һәм 5.2 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» *Татарстан Республикасы Законы* ..........................................................................21

968. «Арча муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» *Татарстан Республикасы Законы* ..........................................................................22

969. «Татарстан Республикасы Гаилә кодексының 141[1] статьясына үзгәреш кертү турында» *Татарстан Республикасы Законы* ..............................................................25

970. «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» *Татарстан Республикасы Законы* ..........................................................................25

971. «Татарстан Республикасында куллану кәрзине турында» *Татарстан Республикасы Законы* ............................27

972. «Татарстан Республикасының административ-территориаль төзелеше турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» *Татарстан Республикасы Законы* ....................29
973. «Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексын кабул итүгә бәйле рәвештә «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 26 статьясына үзгәреш кертү һәм Татарстан Республикасы аерым закон актларының (закон актлары нигезләмәләренең) үз көчләрен югалтуын тану хакында» *Татарстан Республикасы Законы* ....................60
974. «Вөждан иреге турында һәм дини берләшмәләр турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» *Татарстан Республикасы Законы* ........64
975. «Татарстан Республикасы Әгерҗе суд районы буенча Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларының суд участоклары чикләре турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәреш кертү хакында» *Татарстан Республикасы Законы* ....................65
976. «Кеше һәм гражданның хокукларын һәм ирекләрен яклау мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы законнарын һәм башка норматив хокукый актларын бастырып чыгару һәм аларның үз көчләренә керү тәртибе турында» Татарстан Республикасы Законының 5 статьясына үзгәреш кертү хакында» *Татарстан Республикасы Законы* ....................68
977. «Мәгариф турында» *Татарстан Республикасы Законы* ..69
978. «Аерым муниципаль берәмлекләрне үзгәртеп кору һәм «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» *Татарстан Республикасы Законы* ....................98
979. «Татарстан Республикасы Бюджет кодексына һәм «Татарстан Республикасы Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» *Татарстан Республикасы Законы* ....................111

980. «Аерым муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен үзгәртү һәм «Бөгелмә муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» *Татарстан Республикасы Законы* ............................127

## III
## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ РӘИСЕ КҮРСӘТМӘЛӘРЕ

981. *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе күрсәтмәсе* ............................141
982. *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе күрсәтмәсе* ............................141
983. *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе күрсәтмәсе* ............................142
984. *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе күрсәтмәсе* ............................142
985. *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе күрсәтмәсе* ............................143
986. *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе күрсәтмәсе* ............................143
987. *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе күрсәтмәсе* ............................144
988. *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе күрсәтмәсе* ............................144
989. *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе күрсәтмәсе* ............................145
990. *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе күрсәтмәсе* ............................146
991. *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе күрсәтмәсе* ............................147
992. *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе күрсәтмәсе* ............................148

993. *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе күрсәтмәсе* ........................................................................148
994. *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе күрсәтмәсе* ........................................................................149
995. *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе күрсәтмәсе* ........................................................................149
996. *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе күрсәтмәсе* ........................................................................150
997. *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе күрсәтмәсе* ........................................................................150
998. *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе күрсәтмәсе* ........................................................................151
999. *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе күрсәтмәсе* ........................................................................151

# I
# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОННАРЫ

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

### 963. Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2013 елның 28 июнендә
кабул ителде

1 статья. **Әлеге Законның җайга салу предметы**

Әлеге Закон Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкилнең хокукый хәлен, төп бурычларын һәм компетенциясен билгели.

2 статья. **Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил**

1. Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил (алга таба – Вәкаләтле вәкил) вазыйфасы эшкуарлык эшчәнлеге субъектларының хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен дәүләт яклавы гарантияләре белән тәэмин итү һәм күрсәтелгән хокукларның дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары һәм вазыйфаи затлар тарафыннан үтәлүе максатларында булдырыла.
2. Вәкаләтле вәкил вазыйфасы Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасы булып тора.

3 статья. **Вәкаләтле вәкил эшчәнлегенең хокукый нигезләре**

Вәкаләтле вәкил эшчәнлегенең хокукый нигезләре Россия Федерациясе Конституциясеннән, «Россия Федерация-

сендә эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкилләр турында» 2013 елның 7 маендагы 78-ФЗ номерлы Федераль законнан, Татарстан Республикасы Конституциясеннән, әлеге Законнан, Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актларыннан гыйбарәт.

4 статья. **Вәкаләтле вәкилнең бурычлары**

Вәкаләтле вәкилнең төп бурычлары түбәндәгеләр:

1) Татарстан Республикасы территориясендә эшкуарлык эшчәнлеге субъектларының хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау, аларга юридик ярдәм күрсәтү;

2) эшкуарлык эшчәнлеге субъектларының хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклауга юнәлдерелгән иҗтимагый институтларны үстерүгә ярдәм итү;

3) эшкуарлар җәмәгатьчелеге белән үзара хезмәттәшлек итү;

4) Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары тарафыннан эшкуарлык эшчәнлеге субъектлары хокукларының һәм законлы мәнфә-гатьләренең үтәлүен тикшереп торуны гамәлгә ашыру;

5) эшкуарлык эшчәнлеген үстерү һәм эшкуарлык эшчәнлеге субъектларының хокукларын, законлы мәнфәгатьләрен яклау өлкәсендә дәүләт сәясәтен булдыруда һәм гамәлгә ашыруда катнашу;

6) эшкуарлык эшчәнлеге субъектларының хокукларын, законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү һәм яклау мәсьәләләре буенча мәгълүматны җыю, өйрәнү һәм анализлау;

7) эшкуарлык эшчәнлеге субъектлары хокукларының һәм законлы мәнфәгатьләренең үтәлү һәм яклану торышы турында җәмәгатьчелеккә хәбәр итү.

5 статья. **Вәкаләтле вәкил вазыйфасына билгеләп кую**

1. Вәкаләтле вәкил вазыйфага, Россия Федерациясе Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил белән килештерелеп, эшкуарлар җәмәгатьчелеге фикерен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан биш елга билгеләп куела.

2. Вәкаләтле вәкил вазыйфасына 30 яшьтән дә яшь булмаган, югары белемле Россия Федерациясе гражданы билгеләп куела.

3. Бер үк зат Вәкаләтле вәкил вазыйфасына рәттән ике тапкырдан күбрәк билгеләп куела алмый.

6 статья. **Вәкаләтле вәкил вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату**

1. Вәкаләтле вәкил вәкаләтләре түбәндәге очракларда вакытыннан алда туктатыла:

1) үз вәкаләтләрен туктату турында язма гариза бирсә;

2) вафат булса;

3) законлы көченә кергән суд карары белән хокукка сәләтсез яисә хокукка сәләте чикләнгән, хәбәрсез югалган дип танылса яисә вафат булган дип игълан ителсә;

4) судның гаепләү карары үз көченә керсә;

5) Россия Федерациясе гражданлыгын югалтса, чит дәүләт гражданлыгы алса йә чит дәүләт территориясендә Россия Федерациясе гражданына яшәүгә рөхсәт яисә даими яшәү хокукын раслый торган башка документ алса;

6) Вәкаләтле вәкил вазыйфасы бетерелсә;

7) ышанычны югалтса;

8) федераль законнар белән билгеләнгән чикләүләрне бозса.

2. Вәкаләтле вәкилне вазыйфадан вакытыннан алда азат итү Россия Федерациясе Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил ризалыгы белән яисә аның тәкъдиме буенча Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан башкарыла.

7 статья. **Вәкаләтле вәкил өчен чикләүләр**

Вәкаләтле вәкил Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар өчен билгеләнгән чикләүләрне һәм тыюларны федераль законнар нигезендә үтәргә бурычлы.

8 статья. **Вәкаләтле вәкилнең төп хокуклары**

1. Вәкаләтле вәкил үз эшчәнлеген гамәлгә ашырганда түбәндәгеләргә хокуклы:

1) дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан һәм вазыйфаи затлардан кирәкле белешмәләр, документлар һәм материаллар соратып алырга;

2) Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының, җирле үзидарә органнарының, федераль закон белән аерым дәүләт яисә башка гавами вәкаләтләр бирелгән бүтән органнарның, оешмаларның, вазыйфаи затларның норматив булмаган хокукый актларын гамәлдә түгел дип тану, аларның карарларын һәм гамәлләрен (гамәл кылмавын) законсыз дип тану турында гариза белән судка мөрәҗәгать итәргә, әгәр дәгъвалана торган норматив булмаган хокукый акт, карар һәм гамәл (гамәл кылмау) законга яисә башка норматив хокукый актка туры килмәсә һәм эшкуарлык эшчәнлеге субъектларының эшкуарлык эшчәнлеге өлкәсендә хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен бозса, аларга нинди дә булса бурычларны законсыз йөкләсә, эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен башка киртәләр тудырса;

3) Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына, җирле үзидарә органнарына Вәкаләтле вәкил эшчәнлеге өлкәсенә карый торган норматив хокукый актлар кабул итү турында (норматив хокукый актларга үзгәрешләр кертү яисә аларның үз көчләрен югалтуын тану турында) дәлилле тәкъдимнәр җибәрергә;

4) эшкуарлык эшчәнлегенә кагылышлы Татарстан Республикасының законнары һәм башка норматив актлары проектларын әзерләүдә катнашырга, күрсәтелгән проектларны карау нәтиҗәләре буенча бәяләмәләр әзерләргә;

5) Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары актларын юкка чыгару яисә гамәлдә булуын туктатып тору турында Татарстан Республикасы Президентына дәлилле тәкъдимнәр җибәрергә;

6) гариза бирүченең язмача ризалыгы белән гариза бирүчегә карата дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль кысаларында үткәрелә торган күчмә тикшерүдә катнашырга;

7) үз эшчәнлеге мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына тоткарлыксыз кереп йөрергә;

8) федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә үз компетенциясе кысаларында башка гамәлләр башкарырга.

2. Вәкаләтле вәкил үз компетенциясе чикләрендә дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, Россия Федерациясе Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил, Россия Федерациясе Президентының федераль округлардагы вәкаләтле вәкилләре, инвестицияләр буенча федераль округлардагы вәкаләтле вәкилләр һәм башка затлар белән үзара эшчәнлекне гамәлгә ашыра.

3. Вәкаләтле вәкил законнарда билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, Татарстан Республикасы Конституция суды утырышларында булырга, Татарстан Республикасының башка дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары эшендә, шулай ук алар уздыра торган киңәшмәләрдә катнашырга хокуклы.

9 статья. **Вәкаләтле вәкил тарафыннан эшкуарлык эшчәнлеге субъектлары шикаятьләрен карау**

1. Вәкаләтле вәкил Татарстан Республикасы территориясендә дәүләт теркәвен башкаручы органда теркәлгән эшкуарлык эшчәнлеге субъектларының шикаятьләрен һәм Татарстан Республикасы территориясендә хокуклары һәм законлы мәнфәгатьләре бозылган эшкуарлык эшчәнлеге субъектларының Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының, федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасындагы территориаль органнарының, җирле үзидарә органнарының, федераль закон белән аерым дәүләт яисә башка гавами вәкаләтләр бирелгән бүтән органнарның, оешмаларның, вазыйфаи затларның эшкуарлык эшчәнлеге субъектларының хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен боза торган карарларына яисә гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләрен карый.

2. Шикаять Вәкаләтле вәкилгә язмача яисә электрон документ рәвешендә бирелә.

3. Шикаятьтә гариза бирүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), почта адресы, әгәр җавап язма рәвештә җибәрелергә тиеш булса, электрон почта адресы, әгәр җавап электрон документ рәвешендә җибәрелергә тиеш булса, карарларына яисә гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять бирелә торган органның яисә вазыйфаи затның атамасы, гариза бирүче фикеренчә, эшкуарлык эшчәнлеге субъектларының хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен бозган яисә боза тор-

ган карарларның яисә гамәлләрнең (гамәл кылмауның) асылы бәян ителергә тиеш. Шикаятькә аны карау өчен кирәкле документларның һәм башка материалларның күчерелмәләре кушып бирелә.

4. Вәкаләтле вәкил исеменә кергән шикаятьтә гариза бирүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта) һәм почта яисә электрон адресы күрсәтелмәсә, мондый шикаять каралырга тиеш түгел.

5. Вәкаләтле вәкил эшкуарлык эшчәнлеге субъектының шикаятен карауга кабул итү яисә шикаятьне карауга кабул итүдән баш тарту турында ул кергән көннән 10 көн эчендә карар кабул итә, шул хакта гариза бирүчегә өч көн дәвамында хәбәр итә. Алга таба Вәкаләтле вәкил гариза бирүчегә аның бозылган хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен торгызу буенча чараларны гамәлгә ашыру нәтиҗәләре турында кимендә ике айга бер тапкыр хәбәр итеп тора.

6. Вәкаләтле вәкил, шикаятьтә гариза бирүченең почта һәм (яисә) электрон адресы булганда, түбәндәге нигезләр буенча шикаятьне карауга кабул итүдән баш тарту турында гариза бирүчегә хәбәр итә:

1) язмача җибәрелгән шикаять тексты укырлык булмаса;

2) шикаятьтә Россия Федерациясе Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил, Вәкаләтле вәкил тарафыннан гариза бирүчегә элек җибәрелгән шикаятьләр белән бәйле рәвештә мәсьәләнең асылы буенча күп тапкыр язмача җавап бирелгән мәсьәлә генә булса һәм шикаятьтә әлеге мәсьәлә буенча яңа хәлләр китерелмәсә;

3) шикаятьтә куелган мәсьәләнең асылы буенча җавап федераль закон белән саклanучы дәүләт серен һәм башка серне тәшкил итүче белешмәләрне фаш итүдән башка бирелә алмаса.

7. Вәкаләтле вәкил каравына шикаять кабул ителгәннән соң шундый ук шикаять Россия Федерациясенең башка субъекттагы вәкаләтле вәкил тарафыннан каралуы ачыкланган очракта, шикаять алга таба каралмый һәм аның белән мөрәҗәгать иткән эшкуарлык эшчәнлеге субъектына кире кайтарыла.

8. Вәкаләтле вәкил шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге гамәлләрнең берсен яисә берничәсен үтәргә тиеш:

1) гариза бирүчегә аның хокукларына һәм законлы мәнфәгатьләренә, шул исәптән Россия Федерациясе законна-

рында каралган аларны яклау рәвешләренә һәм ысулларына кагылышлы мәсьәләләрне аңлатырга;

2) үз компетенциясенә шикаятьне асылы буенча хәл итү кергән дәүләт хакимияте органына, җирле үзидарә органына яисә вазыйфаи затка шикаятьне җибәрергә. Карарына яисә гамәленә (гамәл кылмавына) шикаять бирелгән вазыйфаи затка шикаятьне карау өчен җибәрү тыела;

3) карарларында яисә гамәлләрендә (гамәл кылмавында) ул эшкуарлык эшчәнлеге субъектларының хокуклары һәм законлы мәнфәгатьләре бозыла дип таныган әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән органга, вазыйфаи затка яисә оешмага, күрсәтелгән субъектларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен торгызу буенча чараларны күрсәтеп, үз бәяләмәсен җибәрергә;

4) әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән органга, вазыйфаи затка яисә оешмага эшкуарлык эшчәнлеге субъектларының хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен бозуда гаепле затларны Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә дисциплинар, административ яисә җинаять җаваплылыгына тарту турында мөрәҗәгать җибәрергә;

5) Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының, җирле үзидарә органнарының, федераль закон белән аерым дәүләт яисә башка гавами вәкаләтләр бирелгән бүтән органнарның, оешмаларның, вазыйфаи затларның норматив булмаган хокукый актларын гамәлдә түгел дип тану, аларның карарларын һәм гамәлләрен (гамәл кылмавын) законсыз дип тану турында гариза белән судка мөрәҗәгать итәргә, әгәр дәгъвалана торган норматив булмаган хокукый акт, карар һәм гамәл (гамәл кылмау) законга яисә башка норматив хокукый актка туры килмәсә һәм эшкуарлык эшчәнлеге субъектларының эшкуарлык эшчәнлеге өлкәсендә хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен бозса, аларга нинди дә булса бурычларны законсыз йөкләсә, эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен башка киртәләр тудырса;

6) хокук саклау органнарына эшкуарлык эшчәнлеге субъектларының хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен бозу фактлары турында хәбәр итәргә.

9. Вәкаләтле вәкил үзе кабул иткән бәяләмәне бастырып чыгарырга хокуклы. Гамәлгә куючыларның (уртак гамәлгә куючыларның) берсе Татарстан Республикасы дәүләт органнары булган вакытлы матбугат басмасы Вәкаләтле вәкилнең

бәяләмәләрен һәм башка документларын бастырып чыгарудан баш тартырга хокуксыз.

10. Эшкуарлык эшчәнлеге субъектларының шикаятьләрен карау нәтиҗәләре турында мәгълүмат шәхси белешмәләрне мәҗбүри рәвештә иясез калдыру шарты белән «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Вәкаләтле вәкилнең рәсми сайтында урнаштырылырга (бастырып чыгарылырга) тиеш.

10 статья. **Вәкаләтле вәкилнең җәмәгатьчелек вәкилләре**

1. Вәкаләтле вәкил иҗтимагый башлангычларда эш итүче җәмәгатьчелек вәкилләрен билгеләп куярга хокуклы.

2. Вәкаләтле вәкилнең җәмәгатьчелек вәкилләре вәкиллекле һәм эксперт функцияләрен башкара.

3. Вәкаләтле вәкил иҗтимагый башлангычларда эш итүче экспертлар, консультатив һәм иҗтимагый советлар, эш төркемнәре һәм башка киңәшү органнары төзергә һәм, алар эшчәнлегендә катнашу өчен, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, эшкуарлар җәмәгатьчелеге, иҗтимагый оешмалар вәкилләрен җәлеп итәргә хокуклы.

4. Вәкаләтле вәкил Татарстан Республикасы территориясендә эшкуарлык эшчәнлеге субъектларына Вәкаләтле вәкил компетенциясенә караган мәсьәләләр буенча консультатив ярдәм күрсәтүче җәмәгать кабул итү бүлмәләре булдырырга хокуклы.

11 статья. **Вәкаләтле вәкилнең үз инициативасы буенча тикшерү хокукы**

Эшкуарлык эшчәнлеге субъектларының хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен массакүләм яисә тупас бозу турында хәбәрләр алганда йә аеруча иҗтимагый әһәмияткә ия очракларда Вәкаләтле вәкил үз инициативасы буенча үз компетенциясе чикләрендә чаралар күрергә хокуклы.

12 статья. **Вәкаләтле вәкилгә аның вәкаләтләрен гамәлгә ашырганда ярдәм күрсәтү**

1. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан

Республикасындагы территориаль органнары, җирле үзидарә органнары җитәкчеләре һәм башка вазыйфаи затлары тиешле мөрәҗәгать алынган көннән 15 көннән артык булмаган срокта Вәкаләтле вәкил тарафыннан соратыла торган белешмәләрне, документларны һәм материалларны тапшырырга бурычлы. Вәкаләтле вәкил мөрәҗәгатенә җавап ул турыдан-туры адресланган вазыйфаи зат имзасы белән җибәрелә.

2. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасындагы территориаль органнары, җирле үзидарә органнары җитәкчеләре һәм башка вазыйфаи затлары Вәкаләтле вәкилне кабул итүне тәэмин итәргә тиеш.

3. Вәкаләтле вәкил Татарстан Республикасы Дәүләт Советы кабул иткән документлар, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, Татарстан Республикасы Конституция суды, Татарстан Республикасының башка дәүләт органнары рәсми рәвештә тарата торган документлар, башка мәгълүмати һәм белешмә материаллары белән тәэмин ителә.

13 статья. **Вәкаләтле вәкилнең үз эшчәнлеге нәтиҗәләре турында мәгълүмат бирүе**

1. Календарь ел тәмамланганнан соң, Вәкаләтле вәкил Татарстан Республикасы Президентына, Татарстан Республикасы Дәүләт Советына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына, Татарстан Республикасы Конституция судына, Татарстан Республикасы Югары судына, Татарстан Республикасы Арбитраж судына, Татарстан Республикасы Прокурорына, Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасына, шулай ук Россия Федерациясе Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкилгә, Татарстан Республикасында эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыру шартларын бәяләп, эшкуарлык эшчәнлеге субъектларының хокукый хәлен камилләштерү турында тәкъдимнәр белән үз эшчәнлеге нәтиҗәләре хакында мәгълүмат (алга таба – еллык мәгълүмат) җибәрә. Вәкаләтле вәкил Татарстан Республикасы Дәүләт Советы утырышында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты утырышында еллык мәгълүмат буенча доклад белән чыгыш ясый.

2. Вәкаләтле вәкилнең еллык мәгълүматы мәҗбүри рәвештә «Республика Татарстан» һәм «Ватаным Татарстан» газеталарында һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация

челтәрендә Вәкаләтле вәкилнең рәсми сайтында рәсми басты-рып чыгарылырга тиеш.

14 статья. **Вәкаләтле вәкил эшчәнлеген тәэмин итү**

Вәкаләтле вәкил эшчәнлеген оештыру ягыннан, мәгълүмати, документлар белән, матди-техник тәэмин итүне Татарстан Республикасы Президенты Аппараты гамәлгә ашыра.

15 статья. **Вәкаләтле вәкил эшчәнлеген финанслау**

Вәкаләтле вәкил эшчәнлеген финанслау Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән башкарыла.

16 статья. **Әлеге Законның үз көченә керү тәртибе**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 елның 5 июле
№ 54-ТРЗ

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

## 964. «Татарстан Республикасында торак төзелеше үсешенә дәүләт ярдәме турында» Татарстан Республикасы Законының 6.1 статьясына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2013 елның 28 июнендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында торак төзелеше үсешенә дәүләт ярдәме турында» 2004 елның 27 декабрендәге 69-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 6.1 статьясы-на (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 12 (II өлеш); 2005, № 7 – 8; 2008, № 5 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) исемендә «социаль ипотека системасында» сүзләрен төшереп калдырырга;

2) 1 өлештә:

а) беренче абзацта «социаль ипотека системасында» сүзләрен төшереп калдырырга;

б) өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«социаль ипотека системасында эшчәнлекне гамәлгә ашыру, шулай ук законнар нигезендә аерым категорияләрдәге гражданнарга торак шартларын яхшырту буенча чаралар күрү өчен махсуслаштырылган оешма (республика коммерциячел булмаган оешма) милкенә.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 елның 5 июле
№ 55-ТРЗ

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

### 965. «Югары Ослан муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2013 елның 28 июнендә
кабул ителде

**1 статья**

«Югары Ослан муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» 2005 елның 31 гыйнварындагы 19-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 1 (II өлеш); 2008, № 12 (VI өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:


1) 2 статьяның бишенче абзацында «Петропавел Бистәсе» сүзләрен «Иннополис, Петропавел Бистәсе» сүзләренә алмаштырырга;

## 2) 1 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Югары Ослан муниципаль районы" муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында" Татарстан Республикасы Законына
1 нче кушымта

### "Югары Ослан муниципаль районы" муниципаль берәмлеге составына керүче муниципаль берәмлекләрнең чикләре

### <u>**карта-схемасы**</u>




Шартлы билгеләр

- муниципаль район чиге
- тоташу ноктасының тәртип саны
- 10 - җирлекләрнең чикләре һәм аларның сан белән билгеләнеше
- торак пунктлар
- муниципаль районның административ үзәге
- җирлекнең административ үзәге

Муниципаль районның чиктәш чикләре тасвирламасы

| | |
|---|---|
| *5(40) - 18(41)* | - Казан шәһәре муниципаль берәмлеге |
| *18(41) - 35(42)* | - Лаеш муниципаль районы |
| *35(42) - 41(87)* | - Кама Тамагы муниципаль районы |
| *41(87) - 37(38)* | - Апас муниципаль районы |
| *37(38) - 22(39)* | - Кайбыч муниципаль районы |
| *22(39) - 5(40)* | - Зеленодольск муниципаль районы |

«Югары Ослан муниципаль районы»
муниципаль берәмлеге составына керүче авыл җирлекләре

| Карта-схемадагы № | Муниципаль берәмлек |
|---|---|
| 1 | Олы Мәми авыл җирлеге |
| 2 | Борнаш авыл җирлеге |
| 3 | Вахитов авыл җирлеге |
| 4 | Введенский Бистәсе авыл җирлеге |
| 5 | Югары Ослан авыл җирлеге |
| 6 | Канаш авыл җирлеге |
| 7 | Килди авыл җирлеге |
| 8 | Карагужа авыл җирлеге |
| 9 | Куралово авыл җирлеге |
| 10 | Мәйдан авыл җирлеге |
| 11 | Макыл авыл җирлеге |
| 12 | Яр буе Морквашы авыл җирлеге |
| 13 | Түбән Ослан авыл җирлеге |
| 14 | Яңа Рус Мәмәтхуҗасы авыл җирлеге |
| 15 | Октябрь авыл җирлеге |
| 16 | Печище авыл җирлеге |
| 17 | Соболевский авыл җирлеге |
| 18 | Шыланғы авыл җирлеге |
| 19 | Ямбулат авыл җирлеге |

».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 елның 10 июле
№ 56-ТРЗ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

## 966. «Инвалидлар һәм социаль яклауга аеруча мохтаҗ гражданнар өчен эш урыннары квоталау һәм резервлау турында» Татарстан Республикасы Законының 6 статьясына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2013 елның 28 июнендә
кабул ителде

**1 статья**

«Инвалидлар һәм социаль яклауга аеруча мохтаҗ гражданнар өчен эш урыннары квоталау һәм резервлау турында» 2006 елның 24 июлендәге 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 6 статьясындагы 2 өлешенә (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 7 (I өлеш); 2012, № 7 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 пунктта «(алга таба – эш урыннары квоталарын һәм резервлауны билгеләү турында карар)», «һәм әлеге карарларның үтәлеше турында Татарстан Республикасының халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте органнарына мәгълүмат бирергә» сүзләрен төшереп калдырырга;

2) түбәндәге эчтәлекле $1^1$ пункт өстәргә:

«$1^1$) инвалидларны һәм социаль яклауга аеруча мохтаҗ гражданнарны эшкә урнаштыру өчен булдырыла яисә бүлеп бирелә торган эш урыннары турында белешмәләр булган локаль норматив актлар кабул итәргә;»;

3) 2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) ай саен Татарстан Республикасының халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте органнарына вакантлы эш урыннары (вазыйфалар) булу, инвалидларны эшкә алу өчен билгеләнгән квота нигезендә инвалидларны эшкә урнаштыру өчен булдырылган яисә бүлеп бирелгән эш урыннары турында, бу эш урыннары, инвалидларны эшкә алу квотасы үтәлеше турында белешмәләр булган локаль норматив актлар хакында мәгълүматны да кертеп, мәгълүмат тапшырырга;»;

4) түбәндәге эчтәлекле $2^1$ пункт өстәргә:

«$2^1$) Татарстан Республикасының халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте органнарына хезмәткәр эштән җибәрелгән көннән алып 10 көн эчендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән форма буенча инвалидларны һәм социаль яклауга аеруча мохтаҗ гражданнарны эшкә урнаштыру өчен резервлана торган эш урыннарының санын билгеләү турындагы карарлар кысаларында бүлеп бирелгән яисә булдырылган бушый торган эш урыннары хакында мәгълүмат тапшырырга;».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 елның 10 июле
№ 57-ТРЗ

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

### 967. Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексының 5.1 һәм 5.2 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2013 елның 28 июнендә
кабул ителде

**1 статья**

Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 12 (I өлеш); 2007, № 11; 2009, № 2, № 7 – 8 (I өлеш), № 9 – 10, № 12 (I өлеш); 2010, № 1 – 2, № 3, № 6 (I өлеш), № 7 (I өлеш), № 7 (II өлеш), № 10 (II өлеш); 2011, № 6 (I өлеш), № 8 (I өлеш), № 10 (I өлеш), № 11 (I өлеш); 2012, № 1, № 6 (I өлеш), № 7 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2013, № 1; Ватаным Татарстан, 2013, 2 март, 22 июнь) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 5.1 статьяның икенче абзацында «йөз» сүзен «өч йөз» сүзләренә алмаштырырга;

2) 5.2 статьяның икенче абзацында «йөз» сүзен «өч йөз» сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 елның 12 июле
№ 58-ТРЗ

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

### 968. «Арча муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2013 елның 28 июнендә
кабул ителде

**1 статья**


«Арча муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» 2005 елның 31 гыйнварындагы 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 1 (I өлеш); 2008, № 12 (VII өлеш); 2010, № 5 (I өлеш); 2011, № 8 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 статьяның унынчы абзацында «Корайван» сүзе татарча текстта үзгәрешсез кала;

2) 1 нче кушымтаны түбəндəге редакциядə бəян итəргə:

"Арча муниципаль районы"
муниципаль берəмлегенең һəм аның
составындагы муниципаль берəмлеклəрнең
территориялəре чиклəрен билгелəү һəм
аларның статусы турында" Татарстан
Республикасы Законына
1 нче кушымта

"Арча муниципаль районы"
муниципаль берəмлеге составына керүче
муниципаль берəмлеклəрнең чиклəре
**карта-схемасы**




Шартлы билгелəр

- Татарстан Республикасы чиге
- муниципаль район чиге
10 - тоташу ноктасының тəртип саны
10 - җирлеклəрнең чиклəре һəм аларның сан белəн билгелəнеше
- торак пунктлар
- муниципаль районның административ үзəге
- җирлекнең административ үзəге

Муниципаль районның
чиктəш чиклəре тасвирламасы

| | |
|---|---|
| 13(12) - 8(13) | - Марий Эл Республикасы |
| 8(13) - 24 (50) | - Балтач муниципаль районы |
| 24(50) - 58(49) | - Саба муниципаль районы |
| 58(49) - 66(48) | - Телəче муниципаль районы |
| 66(48) - 64(46) | - Питрəч муниципаль районы |
| 64(46) - 53(47) | - Биектау муниципаль районы |
| 53(47) - 13(12) | - Әтнə муниципаль районы |

«Арча муниципаль районы»
муниципаль берәмлеге
составына керүче шәһәр һәм авыл җирлекләре

| Карта-схема-дагы № | Муниципаль берәмлекләр |
|---|---|
| 1 | Арча шәһәре |
| 2 | Апаз авыл җирлеге |
| 3 | Кәче авыл җирлеге |
| 4 | Наласа авыл җирлеге |
| 5 | Яңа Кенәр авыл җирлеге |
| 6 | Яңа Кишет авыл җирлеге |
| 7 | Яңа Кырлай авыл җирлеге |
| 8 | Сеҗе авыл җирлеге |
| 9 | Урта Аты авыл җирлеге |
| 10 | Урта Курса авыл җирлеге |
| 11 | Иске Кырлай авыл җирлеге |
| 12 | Иске Чүриле авыл җирлеге |
| 13 | Ташкичү авыл җирлеге |
| 14 | Үрнәк авыл җирлеге |
| 15 | Утар Аты авыл җирлеге |
| 16 | Шушмабаш авыл җирлеге |
| 17 | Яңасала авыл җирлеге |

».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 елның 12 июле
№ 59-ТРЗ

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

### 969. Татарстан Республикасы Гаилә кодексының 141[1] статьясына үзгәреш кертү турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2013 елның 28 июнендә
кабул ителде

**1 статья**

Татарстан Республикасы Гаилә кодексының 141[1] статьясындагы 1 өлешенә (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 1, № 12 (I өлеш); 2010, № 12 (II өлеш); 2011, № 9 (I өлеш); 2012, № 6 (I өлеш); Ватаным Татарстан, 2013, 28 май), «2500 сум» сүзләрен «3000 сум» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

**2 статья**

1. Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

2. Әлеге Законның гамәлдә булуы 2013 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 елның 13 июле
№ 60-ТРЗ

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

### 970. Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2013 елның 28 июнендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында җан башына һәм халыкның төп социаль-демографик төркемнәре буенча яшәү минимумы күләмен билгеләү тәртибе турында» 2005 елның 20 июлендәге

92-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 7 – 8) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 статьяның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«куллану кәрзине – кеше сәламәтлеген саклау һәм аның тормыш эшчәнлеген тәэмин итү өчен кирәкле азык-төлек продуктларының, шулай ук азык-төлек булмаган товарларның һәм хезмәт күрсәтүләрнең минималь җыелмасы, аларның хакы азык-төлек продуктларының минималь җыелмасы хакына нисбәттә билгеләнә;»;

2) 2 статьяның 1 өлешендәге беренче абзацында «чыгымнарга куллану бәяләре дәрәҗәсе» сүзләреннән соң «һәм азык-төлек продуктларына куллану бәяләре индекслары» сүзләрен өстәргә.

**2 статья**

«Татарстан Республикасында минималь куллану бюджеты турында» 2008 елның 23 июлендәге 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2008, № 7 (I өлеш), 2 өлешнең беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«2. Яшәү минимумы – куллану кәрзине хакын бәяләү, шулай ук мәҗбүри түләүләр һәм җыемнар.».

**3 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 елның 13 июле
№ 61-ТРЗ

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

### 971. Татарстан Республикасында куллану кәрзине турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2013 елның 28 июнендә
кабул ителде

**1 статья**

Татарстан Республикасында халыкның төп социаль-демографик төркемнәре өчен куллану кәрзине кимендә биш елга бер мәртәбә билгеләнә.

**2 статья**

1. Татарстан Республикасында халыкның төп социаль-демографик төркемнәре өчен куллану кәрзиненә кертелә торган азык-төлек продуктлары түбәндәге составта һәм күләмнәрдә (натураль күрсәткечләрдә) билгеләнә:

| Исеме | Үлчәү берәмлеге | Куллану күләме (уртача елына бер кешегә) | | |
|---|---|---|---|---|
| | | хезмәткә сәләтле халык | пенсионерлар | балалар |
| Икмәк продуктлары (икмәк һәм, онга күчереп исәпләгәндә, макарон әйберләре, он, ярмалар, кузаклылар) | кг | 131,0 | 103,4 | 78,7 |
| Бәрәңге | кг | 87,8 | 70,0 | 81,0 |
| Яшелчә һәм карбыз-кавын | кг | 121,1 | 110,0 | 123,3 |
| Җиләк-җимешләр | кг | 60,0 | 45,0 | 118,1 |
| Шикәр һәм, шикәргә күчереп исәпләгәндә, кондитер әйберләре | кг | 23,8 | 21,2 | 21,8 |
| Ит продуктлары | кг | 58,5 | 54,0 | 44,2 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| Балык продуктлары | кг | 20,0 | 17,0 | 20,1 |
| Сөт һәм, сөткә күчереп исәпләгәндә, сөт продуктлары | кг | 258,6 | 230,8 | 360,2 |
| Йомырка | данә | 210,0 | 200,0 | 201,0 |
| Үсемлек мае, маргарин һәм башка майлар | кг | 13,0 | 10,0 | 6,4 |
| Бүтән продуктлар (тоз, чәй, тәмләткечләр) | кг | 4,9 | 4,1 | 3,5. |

2. Азык-төлек булмаган товарларның һәм хезмәт күрсәтүләрнең хакы белән азык-төлек продуктлары хакының түбәндәге нисбәте билгеләнә (процентларда):

| Исеме | Хезмәткә сәләтле халык | Пенсионерлар | Балалар |
|---|---|---|---|
| Азык-төлек булмаган товарлар | 45 | 45 | 45 |
| Хезмәт күрсәтүләр | 55 | 55 | 55. |

**3 статья**

Әлеге Закон үз көченә кергән көннән «Татарстан Республикасында куллану кәрзине турында» 2008 елның 7 августындагы 73-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2008, № 8 (III өлеш) үз көчен югалткан дип танырга.

**4 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 елның 13 июле
№ 62-ТРЗ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

## 972. «Татарстан Республикасының административ-территориаль төзелеше турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2013 елның 28 июнендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасының административ-территориаль төзелеше турында» 2005 елның 7 декабрендәге 116-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 12 (I өлеш); 2007, № 12 (I өлеш); 2010, № 12 (II өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) преамбулага түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: «Әлеге Законның гамәлдә булуы муниципаль берәмлекләрнең статусын билгеләү, чикләрен үзгәртү, үзгәртеп төзү белән бәйле мөнәсәбәтләргә кагылмый.»;

2) 1 – 3 статьяларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«1 статья. **Төп төшенчәләр һәм терминнар**

Әлеге Законда түбәндәге терминнар һәм төшенчәләр кулланыла:
1) Татарстан Республикасының административ-территориаль төзелеше (алга таба – административ-территориаль төзелеш) – Татарстан Республикасының административ-территориаль берәмлекләре (алга таба – административ-территориаль берәмлекләр) һәм торак пунктлар системасыннан гыйбарәт булган Татарстан Республикасының территориаль оешуы;
2) административ-территориаль берәмлек – Татарстан Республикасы Конституциясе һәм әлеге Закон нигезендә билгеләнгән хокукый статусы булган, дәүләт идарәсе функцияләрен гамәлгә ашыру өчен территориаль аерымланган территориаль берәмлек;
3) район – Татарстан Республикасы Конституциясе белән билгеләнгән, үз чикләрендә, республика әһәмиятендәге шәһәрләрдән тыш, үзара территориаль һәм административ

бәйләнгән торак пунктларны берләштерә торган административ-территориаль берәмлек;

4) республика әһәмиятендәге шәһәр – Татарстан Республикасы Конституциясе белән билгеләнгән, район территориясе составына керми торган шәһәр нигезендә төзелгән административ-территориаль берәмлек;

5) шәһәрдәге район – республика әһәмиятендәге шәһәрдә төзелгән административ-территориаль берәмлек;

6) административ-территориаль берәмлек, торак пункт төзү – әлеге Законда каралган тиешле хокукый статус биреп, яңа административ-территориаль берәмлек, яңа торак пункт булдыру;

7) административ-территориаль берәмлекне, торак пунктны үзгәртеп төзү – административ-территориаль берәмлекләрне, торак пунктларны берләштерү (кушу, кертү), административ-территориаль берәмлекләрне бүлү, торак пунктның категориясен яисә төрен үзгәртү;

8) административ-территориаль берәмлекләрне, торак пунктларны кушу – берләштерелә торган административ-территориаль берәмлекләрнең, торак пунктларның бетүенә һәм яңа исемле яңа административ-территориаль берәмлекнең, яңа торак пунктның төзелүенә китерә торган ике яисә аннан күбрәк административ-территориаль берәмлекне, торак пунктны берләштерү;

9) административ-территориаль берәмлекне, торак пунктны административ-территориаль берәмлеккә, торак пунктка кертү – кертелә торган административ-территориаль берәмлекләрнең, торак пунктларның бетүенә китергән административ-территориаль берәмлекләрне, торак пунктларны берләштерү, монда бер яисә берничә административ-территориаль берәмлек, бер яисә берничә торак пункт башка административ-территориаль берәмлеккә, башка торак пунктка кертелә;

10) административ-территориаль берәмлекне бүлү – административ-территориаль берәмлекнең бөтен территориясен аның бетүенә китерә торган бүлү хисабына ике яисә аннан күбрәк яңа административ-территориаль берәмлек төзү;

11) административ-территориаль берәмлекне, торак пунктны бетерү – Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарында һәм бүтән норматив хокукый актларында билгеләнгән тәртиптә исәпкә алу белешмәләреннән төшереп калдыруга китерә торган административ-территориаль берәмлекнең, торак пунктның булуын туктату (бетерү);

12) Татарстан Республикасында административ-территориаль берәмлекләр һәм торак пунктлар реестры – административ-

территориаль берәмлекләрнең һәм торак пунктларның системалаштырылган исемлеге.

2. Әлеге Закон максатларында түбәндәге төшенчәләр кулланыла:

1) торак пункт – расланган чик кысаларында төзелешләре булган һәм (яисә) төзелешләр булдырылырга тиешле, кешеләрнең даими яисә күбесенчә яшәве һәм тормыш итүе өчен каралган, әлеге Закон нигезендә билгеләнгән хокукый статуска ия территория;

2) торак пунктның состав өлеше – торак пунктта урам, мәйдан һәм гражданнар яши торган башка территория;

3) исәпкә алу белешмәләре – Татарстан Республикасында административ-территориаль берәмлекләр һәм торак пунктлар реестры, муниципаль берәмлекләрнең статусы һәм чикләре турында Татарстан Республикасы законнары, гомумроссия классификаторлары һәм административ-территориаль берәмлекләрнең һәм (яисә) торак пунктларның исемлекләрен үз эченә алган дәүләт органнары тарафыннан раслана һәм кулланыла торган башка мәгълүмат (исәпкә алу) системалары.

2 статья. **Административ-территориаль төзелеш мәсьәләләрен җайга салуның хокукый нигезе**

Административ-территориаль төзелеш мәсьәләләрен хокукый җайга салу Татарстан Республикасы Конституциясе, әлеге Закон, Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының бүтән норматив хокукый актлары белән гамәлгә ашырыла.

3 статья. **Административ-территориаль төзелеш мәсьәләләрен хәл итүнең төп принциплары**

Административ-территориаль төзелеш мәсьәләләрен хәл итү түбәндәге принциплар нигезендә башкарыла:

1) тиешле территориядә яшәүче халыкның фикерен һәм мәнфәгатьләрен исәпкә алуның мәҗбүрилеге;

2) дәүләт һәм муниципаль идарәнең мәнфәгатьләре ярашуы;

3) дәүләт хакимиятен гамәлгә ашыру өчен икътисадый һәм оештыру шартларын тәэмин итү;

4) тарихи, мәдәни, милли һәм башка җирле традицияләрне исәпкә алу.»;

3) 4 статьяда:

а) исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4 статья. **Административ-территориаль берәмлекләрнең һәм торак пунктларның исемнәрен язу теле һәм аны билгеләү»;**

б) 1 өлештә «Татарстан Республикасының» сүзләрен төшереп калдырырга һәм «административ-территориаль берәмлекләренә» сүзләреннән соң «һәм торак пунктларына» сүзләрен өстәргә;

в) 2 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Административ-территориаль берәмлекләр һәм торак пунктлар исемнәренең татар, рус һәм Татарстан Республикасы халыкларының башка телләрендәге язылышын билгеләү орфография кагыйдәләре һәм административ-территориаль берәмлекләрнең һәм торак пунктларның исемнәрен шул телләрдә куллану традицияләре нигезендә гамәлгә ашырыла.»;

4) 5 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5 статья. **Административ-территориаль берәмлеккә, торак пунктка исем бирү, аларның исемнәрен алмаштыру**

1. Административ-территориаль берәмлеккә, торак пунктка исем бирү һәм аларның исемнәрен алмаштыру турындагы тәкъдимнәрне Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан карау, мондый тәкъдимнәрне вәкаләтле федераль башкарма хакимият органына җибәрү географик объектларның атамалары турындагы Россия Федерациясе законнарына һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан расланган нигезләмәгә ярашлы рәвештә башкарыла.

2. Административ-территориаль берәмлеккә, торак пунктка исем бирү турында яисә аларның исемнәрен алмаштыру турында тәкъдимнәрне караганда таләп ителгән чыгымнар хакында тиешле территорияләр халкына мәгълүмат бирү, шулай ук күрсәтелгән тәкъдимнәр хакында халыкның фикерен белү Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан географик объектларга атамалар бирү турында яисә аларның исемнәрен алмаштыру хакында тәкъдимнәрне карау турындагы Татарстан Республикасы законында билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан гамәлгә ашырыла.»;

5) 2 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2 бүлек. **Административ-территориаль төзелеш нигезләре**

6 статья. **Татарстан Республикасы территориясе һәм аны үзгәртү тәртибе**

1. Татарстан Республикасының Россия Федерациясенең башка субъектлары белән чикләрен үзгәртү Татарстан Республикасының һәм аның белән чиктәш Россия Федерациясе субъектларының үзара килешүе буенча, чикләрне үзгәртүне алга таба Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Федерация Советы тарафыннан Россия Федерациясе Конституциясе нигезендә раслап башкарылырга мөмкин. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының Татарстан Республикасы чикләрен үзгәртү мәсьәләсе буенча карарларын кабул итү тәртибе Татарстан Республикасы законында билгеләнә.

2. Татарстан Республикасы чикләре үзгәрүгә бәйле административ-территориаль төзелеш мәсьәләләрен хәл итү Татарстан Республикасы законнары белән гамәлгә ашырыла.

7 статья. **Административ-территориаль берәмлекләрнең төрләре һәм исемлеге**

1. Районнар, республика әһәмиятендәге шәһәрләр, шәһәрдәге районнар административ-территориаль берәмлекләр була.

2. Татарстан Республикасы районнардан һәм республика әһәмиятендәге шәһәрләрдән гыйбарәт. Республика әһәмиятендәге шәһәрнең шәһәрдәге районнары булырга мөмкин.

3. Республика әһәмиятендәге районнар һәм шәһәрләр исемлеге Татарстан Республикасы Конституциясенең 65 статьясындагы 2 өлеше нигезендә билгеләнә. Шәһәрдәге районнарга административ-территориаль бүленеше булган республика әһәмиятендәге шәһәрләр һәм алар составына керә торган районнар исемлеге әлеге Закон белән билгеләнә.

4. Казан шәһәре составына Авиатөзелеш, Вахитов, Киров, Мәскәү, Яңа Савин, Идел буе һәм Совет районнары керә.

8 статья. **Торак пунктларның категорияләре һәм төрләре**

1. Торак пунктлар, халык саныннан, төзеклек дәрәҗәсеннән һәм социаль, җитештерү, транспорт һәм башка инфраструктура үсеше дәрәҗәсеннән, күпчелек халыкның шөгыленнән, тарихи үзенчәлекләреннән чыгып, шәһәр яисә авыл торак пунктлары категориясенә керәләр.

2. Шәһәрләр һәм шәһәр тибындагы поселоклар шәһәр торак пунктлары була.

3. Шәһәргә әлеге Законда билгеләнгән тәртиптә республика әһәмиятендәге шәһәр статусы бирелергә мөмкин. Республика әһәмиятендәге шәһәр статусы бирелмәгән башка шәһәрләр район әһәмиятендәге шәһәрләр була.

4. Авыл торак пунктлары авыллардан, поселоклардан, шәһәр торак пунктлары категориясенә карамаган башка төр торак пунктлардан гыйбарәт.

5. Халык саны кимендә 12 мең кешене тәшкил иткән, сәнәгать, мәдәни һәм административ үзәк булып торган, үсеш алган социаль, җитештерү, инженерлык һәм транспорт инфраструктурасы булган торак пункт шәһәр була. Аерым очракларда халык саны кимрәк булган, әмма алга таба социаль-икътисадый үсеш һәм халык саны арту перспективасы күзаллаланган торак пунктлар, шулай ук әлеге статьяның 6 өлешендә билгеләнгән критерийларга туры килә торган һәм мөһим тарихи әһәмияткә ия торак пунктлар шәһәрләргә керергә мөмкин.

6. Халык саны кимендә биш мең кешене тәшкил иткән, авыл хуҗалыгына карамаган эшчәнлек төрләре белән шөгыльләнүче эшкә сәләтле халкы кимендә 85 процент булган, катнаш торак төзелешле, үзәкләштерелгән су белән тәэмин итү, су чыгару, җылылык белән тәэмин итү коммуналь системалары булган торак пункт шәһәр тибындагы поселок була. Торак пункт территориясендә җитештерү инфраструктурасы объектлары йә шәһәргә хас түбәндәге объектларның (оешмаларның) берсе яисә берничәсе урнашкан булырга тиеш: урта һөнәри (югары) белем бирү оешмалары, фәнни-тикшеренү учреждениеләре, шифаханә-курорт, сәламәтләндерү оешмалары, мәдәни мирас һәм туристлык индустриясе объектлары комплексы. Аерым очракларда шәһәр тибындагы поселокларга халык саны кимрәк булган, әмма алга таба социаль-икътисадый үсеш һәм халык саны арту перспективасы күзаллаланган торак пунктлар керергә мөмкин.

7. Халык саны, кагыйдә буларак, 200 кешегә кадәр булган, күбесенчә индивидуаль торак төзелешләреннән гыйбарәт торак пункт авыл (деревня) була.

8. Халык саны, кагыйдә буларак, 200 кешедән күбрәк булып, күбесенчә индивидуаль һәм (яисә) азкатлы торак төзелешләреннән гыйбарәт торак пункт авыл (село) була.

9. Халык санының күпме булуына карамастан, күбесенчә индивидуаль һәм (яисә) азкатлы торак төзелешләреннән гыйбарәт торак пункт поселок була, аның эшкә сәләтле халкының күбесе

тимер юл транспорты, урман хуҗалыгы өлкәләрендә һәм, кагыйдә буларак, авыл хуҗалыгы культураларын үстерү һәм терлекчелек продукциясен җитештерү белән бәйле булмаган башка эшчәнлек өлкәләрендә эшли.

10. Башка төр авыл торак пунктларына (тимер юл разъезды поселогы, тимер юл станциясе поселогы һәм башкалар) әлеге статьяның 7 – 9 өлешләрендә билгеләнгән критерийларга туры килә торган, әмма авыл (село, деревня) яисә поселок статусы булмаган торак пунктлар керә. Башка төрдәге яңа авыл торак пунктларын төзү рөхсәт ителми.

11. Аерым урнашкан өйләр һәм хезмәт билгеләнешендәге һәм (яисә) вакытлыча булган, халык составы даими булмаган, мөстәкыйль торак пунктлар булып тормаган бүтән торак объектлар торак пунктларга территориаль торышына бәйле рәвештә кертелергә тиеш (административ буйсындыру). Төрле муниципаль берәмлекләрнең территорияләрендәге торак пунктларга күрсәтелгән объектларны административ буйсындыру рөхсәт ителми.

9 статья. **Административ-территориаль төзелешне үзгәртү төрләре**

1. Административ-территориаль төзелешне үзгәртү түбәндәге төрләрдә гамәлгә ашырыла:

1) административ-территориаль берәмлек төзү;

2) административ-территориаль берәмлекне үзгәртеп төзү;

3) административ-территориаль берәмлекне бетерү;

4) административ-территориаль берәмлекнең чикләрен билгеләү, үзгәртү;

5) торак пункт төзү;

6) торак пунктны үзгәртеп төзү;

7) торак пунктны бетерү.

2. Әгәр административ-территориаль төзелешне үзгәртү бер үк вакытта берничә төрдә башкарылса, административ-территориаль төзелешне үзгәртүнең һәр төре өчен әлеге Законда каралган шартлар үтәлергә тиеш.»;

6) 3 бүлекнең исемендә «мәсьәләләрен җайга салуда» сүзләрен «өлкәсендә» сүзенә алмаштырырга;

7) 10 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10 статья. **Административ-территориаль төзелеш өлкәсендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы вәкаләтләре**

Административ-территориаль төзелеш өлкәсендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) административ-территориаль төзелешне һәм аны үзгәртү тәртибен закон белән җайга салу;

2) Татарстан Республикасы чикләрен үзгәртү турындагы килешүләрне раслау;

3) административ-территориаль төзелешне үзгәртү турында карарлар кабул итү;

4) административ-территориаль берәмлеккә, торак пунктка исем бирү, аларның исемнәрен алмаштыру турындагы тәкъдимнәрне карау, мондый тәкъдимнәрне вәкаләтле федераль башкарма хакимият органына җибәрү;

5) федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары белән башка дәүләт хакимияте органнары карамагына кертелмәгән башка вәкаләтләр.»;

8) түбәндәге эчтәлекле $10^1$ статья өстәргә:

«$10^1$ статья. **Административ-территориаль төзелеш өлкәсендә Татарстан Республикасы Президенты вәкаләтләре**

Административ-территориаль төзелеш өлкәсендә Татарстан Республикасы Президенты вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) Татарстан Республикасы Дәүләт Советына административ-территориаль төзелешне үзгәртү турында тәкъдимнәр кертү;

2) әлеге Законда каралган очракларда административ-территориаль төзелешне үзгәртү турында бәяләмәләр бирү;

3) Татарстан Республикасында административ-территориаль берәмлекләр һәм торак пунктлар реестрын кертү тәртибен билгеләү;

4) әлеге Законда, башка законнарда каралган башка вәкаләтләр.»;

9) 11 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11 статья. **Административ-территориаль төзелеш өлкәсендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты вәкаләтләре**

Административ-территориаль төзелеш өлкәсендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) Татарстан Республикасы Дәүләт Советына административ-территориаль төзелешне үзгәртү турында тәкъдимнәр кертү;

2) әлеге Законда каралган очракларда административ-территориаль төзелешне үзгәртү турында бәяләмәләр бирү;

3) Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары административ-территориаль төзелешне үзгәртү инициативасы белән чыкканда, административ-территориаль төзелеш мәсьәләләре буенча халык фикерен белүне тәэмин итү;

4) әлеге Законда, бүтән законнарда каралган башка вәкаләтләр.»;

10) 12 статьяда:

а) исемендә «мәсьәләләрен җайга салуда» сүзләрен «өлкәсендә» сүзенә алмаштырырга;

б) беренче абзацта «мәсьәләләрен җайга салуда» сүзләрен «өлкәсендә» сүзенә алмаштырырга;

в) икенче абзацта «Татарстан Республикасы» сүзләрен «1) Татарстан Республикасы» сүзләренә алмаштырырга;

г) өченче абзацта «җирле үзидарә органнары» сүзләрен «2) җирле үзидарә органнары» сүзләренә алмаштырырга;

11) 4 бүлекнең исемендә «Татарстан Республикасының административ-территориаль төзелеше» сүзләрен «Административ-территориаль төзелеш» сүзләренә алмаштырырга;

12) 13 статьяда:

а) исемендә «Татарстан Республикасының административ-территориаль төзелеше» сүзләрен «Административ-территориаль төзелеш» сүзләренә алмаштырырга;

б) 1 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Административ-территориаль төзелешне үзгәртү Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан Татарстан Республикасы Президенты, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, муниципаль районнарның, шәһәр округларының вәкиллекле органнары инициативасы буенча – Татарстан Республикасы законы рәвешендә, ә әлеге Законда каралган очракларда – Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары рәвешендә башкарыла. Татарстан Республикасы Конституциясенең 65 статьясындагы 2 өлешендә билгеләнгән административ-территори-

аль берәмлекләрнең исемлеген үзгәртүне күз алдында тоткан административ-территориаль төзелешне үзгәртүләр инициативасы белән чыгу хокукына Татарстан Республикасы Конституциясенең 76 статьясындагы 2 өлешендә күрсәтелгән закон чыгару инициативасы субъектлары ия.»;

в) 3 өлештә «20 – 26 статьяларында» сүзләрен «22 – 26 статьяларында» сүзләренә алмаштырырга;

г) 6 өлештә «һәм районнарны бетерү, торак пунктларны, республика, район әһәмиятендәге шәһәрләр категориясенә кертү» сүзләрен «, административ-территориаль берәмлекләрне үзгәртеп төзү, бетерү, шәһәр төзү, торак пунктны шәһәргә үзгәртеп төзү» сүзләренә алмаштырырга;

д) 7 өлештә «(сызыгы)» сүзен төшереп калдырырга;

е) 9 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9. Административ-территориаль төзелешне үзгәртү түбәндәге очракларда муниципаль берәмлекләрне үзгәртеп төзү яисә аларның чикләрен үзгәртү белән бергә башкарыла:

1) муниципаль районнарның чикләрен үзгәртү, шулай ук муниципаль район һәм шәһәр округы чиктәш чиген үзгәртү;

2) муниципаль районнарны үзгәртеп төзү, җирлекне шәһәр округы белән берләштерү;

3) төрле муниципаль берәмлекләр территориясендәге торак пунктларны берләштерү.»;

ж) түбәндәге эчтәлекле 11 – 13 өлешләр өстәргә:

«11. Административ-территориаль берәмлек, торак пункт административ-территориаль берәмлеккә, торак пунктка исем бирү турында Россия Федерациясенең тиешле хокукый акты үз көченә кергән көннән төзелгән дип санала.

12. Административ-территориаль берәмлек, торак пункт мондый үзгәртеп төзү турындагы тиешле Татарстан Республикасы хокукый акты үз көченә кергән көннән яисә, әгәр үзгәртеп төзү нәтиҗәсендә административ-территориаль берәмлеккә, торак пунктка яңа исем бирү күз алдында тотылса, административ-территориаль берәмлеккә, торак пунктка исем бирү турында тиешле Россия Федерациясе хокукый акты үз көченә кергән көннән үзгәртеп төзелгән дип санала.

13. Бетерү турында тиешле Татарстан Республикасы хокукый акты үз көченә кергән көннән административ-территориаль берәмлек, торак пункт бетерелгән дип санала.»;

13) 14 статьяда:

а) исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«14 статья. **Административ-территориаль төзелешне үзгәрткәндә халык фикерен белү тәртибе»;**

б) 2 өлешнең беренче абзацына түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: «Әгәр тавыш бирү уздырылырга тиешле территориядә сайлау хокукына ия күп дигәндә 100 кеше яшәсә, тавыш бирү урынына «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25[1] статьясында каралган тәртиптә гражданнар җыены уздырылырга мөмкин.»;

в) 3 өлештә «сораштырулар» сүзеннән соң «, гавами тыңлаулар» сүзләрен өстәргә;

г) 4 өлештә «үзгәрткән очракта,» сүзләреннән соң «, әгәр тавыш бирүгә (гражданнар җыенына) чыгарылган мәсьәләнең формулировкасы административ-территориаль төзелешне тәкъдим ителгәнчә үзгәртүгә халыкның ризалыгын берсүзсез күрсәтә алса,» сүзләрен өстәргә;

14) 15 – 19 статьяларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«15 статья. **Административ-территориаль берәмлекләрне төзү, үзгәртеп төзү, бетерү**

1. Яңа административ-территориаль берәмлекне төзү тиешле административ-территориаль берәмлекләрне кушу яисә бүлү нәтиҗәсендә гамәлгә ашырыла, шулай ук түбәндәге рәвешләрдә гамәлгә ашырылырга мөмкин:

1) бер яисә берничә чиктәш административ-территориаль берәмлек территориясенең өлешләрен төзелә торган район составына бүлеп бирү хисабына район төзү;

2) шәһәргә республика әһәмиятендәге шәһәр статусын бирү;

3) административ-территориаль бүленеше булмаган шәһәрдә районнар төзү;

4) федераль законда билгеләнгән тәртиптә чиге үзгәртелүгә бәйле рәвештә республика әһәмиятендәге шәһәргә кертелә торган территориядә шәһәрдәге районны төзү.

2. Административ-территориаль берәмлекләрне үзгәртеп төзү түбәндәге рәвешләрдә гамәлгә ашырыла:

1) районнарны берләштерү, бүлү;

2) шәһәрдәге районнарны берләштерү, бүлү.

3. Административ-территориаль берәмлекләрне бетерү административ-территориаль берәмлекләрне берләштерү яисә бүлү нәтиҗәсендә гамәлгә ашырыла, шулай ук түбәндәге рәвешләрдә гамәлгә ашырылырга мөмкин:

1) шәһәрдән республика әһәмиятендәге шәһәр статусын алу;

2) шәһәрдәге районнарны бетерү.

4. Районнарны төзү, үзгәртеп төзү, бетерү «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән тәртиптә муниципаль районнарны тиешенчә үзгәртеп төзү шартлары булганда гамәлгә ашырыла.

5. Шәһәргә республика әһәмиятендәге шәһәр статусын бирү тиешле шәһәр җирлегенең статусын аңа шәһәр округы статусы бирелүгә бәйле рәвештә үзгәртү очрагында гамәлгә ашырыла. Шәһәрдән республика әһәмиятендәге шәһәр статусын алу тиешле шәһәр округының статусын үзгәртү һәм аны шәһәр җирлегенә үзгәртеп төзү очрагында гамәлгә ашырылырга мөмкин.

6. Шәһәрдәге районнарны төзү, үзгәртеп төзү, бетерү республика әһәмиятендәге шәһәрдә дәүләт идарәсенең нәтиҗәлелеген арттыру зарур булганда гамәлгә ашырыла. Күрсәтелгән карарларны кабул иткәндә республика әһәмиятендәге шәһәрнең тиешле территорияләрендәге халык саны, аларның социаль-икътисадый характеристикалары, шәһәр төзелеше һәм тарихи үзенчәлекләре, торак төзелешләре, җитештерү һәм социаль инфраструктура объектлары булу, шәһәр хуҗалыгы белән идарә итүне рациональ оештыруда, шәһәр халкына социаль-мәдәни һәм коммуналь-көнкүреш хезмәт күрсәтүләрдә кызыксынулар исәпкә алына.

7. Административ-территориаль берәмлекләрне төзү, үзгәр-теп төзү, бетерү, шәһәр җирлеге территориясе чикләрендә урнашкан шәһәрдәге районнардан тыш, территориясенә (территорияләренә) әлеге административ-территориаль төзелешне үзгәртү кагыла торган муниципаль районның (муниципаль районнарның), шәһәр округының вәкиллекле органы (вәкиллекле органнары) аша белдерелгән халык ризалыгы белән гамәлгә ашырыла. Шәһәр җирлеге территориясе чикләрендә урнашкан шәһәрдәге районнарны төзү, үзгәртеп төзү, бетерү шул җирлекнең вәкиллекле органы аша белдерелгән халык ризалыгы белән гамәлгә ашырыла.

8. Үзгәртеп төзү нәтиҗәсендә территорияләре яңа административ-территориаль берәмлекләрнең территорияләре составына тулысынча кертелә торган яисә гамәлдә булган административ-территориаль берәмлекләрнең территорияләренә кертелә торган административ-территориаль берәмлекләр үзләренең статусын (административ-территориаль берәмлек статусын) югалталар һәм аларның территорияләре башка административ-территориаль берәмлекләрнең состав өлешләре булалар.

16 статья. **Административ-территориаль берәмлекләрнең чикләрен билгеләү һәм үзгәртү**

1. Административ-территориаль берәмлекләрнең чикләрен билгеләү һәм үзгәртү түбәндәге таләпләр үтәлеп гамәлгә ашырыла:

1) район территориясе чиге тиешле муниципаль район территориясе чигенә туры килү;

2) республика әһәмиятендәге шәһәрләр территорияләреннән кала барлык шәһәр һәм авыл торак пунктларының территорияләре район территориясе составына кертелү;

3) республика әһәмиятендәге шәһәр территориясе район территориясе составына кермәү;

4) республика әһәмиятендәге шәһәр территориясе чиге, әгәр шәһәр шәһәр җирлеге составына керсә, шәһәр чигенә яисә, әгәр шәһәр шәһәр округы составына керсә, шәһәр округы чигенә туры килү;

5) районның һәм республика әһәмиятендәге шәһәрнең чиктәш чиге, районның һәм шәһәр округының чиктәш чиге, тиешенчә, республика әһәмиятендәге шәһәр, шәһәр округы чиге буйлап узу;

6) административ-территориаль бүленеше булган республика әһәмиятендәге шәһәр территориясе шәһәрдәге районнар арасында бүленү;

7) шәһәрдәге район территориясе республика әһәмиятендәге шәһәр территориясе составына тулысынча керергә тиеш булу;

8) шәһәрдәге район чигенең шәһәрдәге башка район чиге белән кисешмәве.

2. Район, республика әһәмиятендәге шәһәр чиген үзгәртү муниципаль район, шәһәр округы, республика әһәмиятендәге шәһәр статусы бирелгән шәһәр чикләренең федераль законда билгеләнгән тәртиптә үзгәртелүенә бәйле рәвештә гамәлгә ашырыла һәм аерым карар кабул итүне таләп итми.

3. Шәһәрдәге районнар чикләре, әлеге Законның 15 статьясындагы 6 өлешендә каралган таләпләрне исәпкә алып, Татарстан Республикасы законы белән билгеләнә һәм үзгәртелә.

17 статья. **Торак пунктлар төзү**

1. Яңа торак пункт төзү торак пунктларны кушу нәтиҗәсендә гамәлгә ашырыла, шулай ук түбәндәге рәвешләрдә гамәлгә ашырылырга мөмкин:

1) торак пункт булмаган территориядә торак пункт төзү;

2) булган торак пункт территориясе өлешен бүлү хисабына торак пункт төзү.

2. Торак пунктлар төзү шәһәр төзелеше законнары нигезендә муниципаль берәмлекләрнең территорияләрен планлаштыру документларында төзелә торган торак пунктларның чикләре билгеләнгәндә рөхсәт ителә.

3. Әлеге статьяның 1 өлешендәге 2 пунктында каралган очракта торак пунктлар төзү яңа торак пункт төзелә торган торак пунктның бер өлеше элек мөстәкыйль торак пункт булганда яисә территориясенең бер өлешендә яңа торак пункт төзелә торган торак пункт берничә территориаль аерымланган өлешләрдән гыйбарәт булса, шулай ук төзелә торган торак пунктның аның мөстәкыйль эшләве өчен җитәрлек социаль һәм коммуналь-көнкүреш инфраструктурасы булганда рөхсәт ителә.

4. Әлеге статьяның 1 өлешендәге 1 пунктында каралган очракта торак пункт төзү территориясе чикләрендә төзелә торган торак пункт урнашкан җирлекнең (шәһәр округының) вәкиллекле органы аша белдерелгән халык ризалыгы белән гамәлгә ашырыла. Әлеге статьяның 1 өлешендәге 2 пунктында каралган очракта торак пункт төзү төзелә торган торак пункт территориясендә яшәүче халыкның әлеге Законның 14 статьясындагы 2 өлешендә каралган тавыш бирү юлы аша (гражданнар җыенында) белдерелгән ризалыгы белән гамәлгә ашырыла.

5. Торак пункт төзелү турында карар кабул ителгәндә әлеге Законның 8 статьясындагы 5 – 9 өлешләрендә билгеләнгән критерийлар нигезендә торак пунктның төре (шәһәр, шәһәр тибындагы поселок, авыл (село, деревня), поселок) һәм кайсы административ-территориаль берәмлеккә керүе билгеләнә. Яңа төзелгән торак пунктка исем географик объектларның атамалары турында Россия Федерациясе законнары нигезендә бирелә.

6. Торак пункт төзегәндә түбәндәге таләпләр үтәлергә тиеш:

1) торак пункт территориясе тиешле административ-территориаль берәмлек территориясе составына керергә тиеш;

2) торак пункт чиге административ-территориаль берәмлек чиген кисеп чыга алмый;

3) торак пункт чиге башка торак пункт чиген кисеп чыга алмый;

4) торак пункт территориясе башка торак пункт территориясе эчендә була алмый.

7. Торак пункт төзү Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары белән гамәлгә ашырыла.

18 статья. **Торак пунктларны үзгәртеп төзү**

1. Торак пунктларны үзгәртеп төзү түбәндәге рәвешләрдә гамәлгә ашырыла:

1) торак пунктларны берләштерү (кушу, кертү);

2) торак пунктны торак пунктларның бүтән категориясенә кертеп карау;

3) торак пунктның төрен торак пунктларның бер категориясе кысаларында үзгәртү.

2. Торак пунктларны берләштерү берләштерелә торган торак пунктлар чынбарлыкта үзара кушылып беткәндә һәм аларның инженерлык, транспорт һәм социаль инфраструктуралары бердәм булганда гамәлгә ашырыла. Чиктәш чикләре булмаган торак пунктларны берләштерү рөхсәт ителми.

3. Авыл торак пунктын шәһәр торак пунктлары категориясенә кертү яисә шәһәр торак пунктын авыл торак пунктлары категориясенә кертү, шәһәр торак пунктының төрен үзгәртү үзгәртеп төзелә торган торак пунктның әлеге Законның 8 статьясындагы 5 һәм 6 өлешләрендә билгеләнгән критерийларга туры килгәндә (туры килмәгәндә) рөхсәт ителә. Бу вакытта торак пунктның үсеш перспективалары, аның тарихи һәм башка үзенчәлекләре исәпкә алынырга тиеш. Халык санының кимүе һәм торак пунктның халык санына карата булган таләпләргә туры килмәве үзләреннән-үзләре торак пунктның категориясен яисә төрен үзгәртү өчен нигез була алмыйлар.

4. Авыл торак пункты төрен үзгәртү, кагыйдә буларак, рөхсәт ителми. Күрсәтелгән үзгәртеп төзү торак пунктның тарихи үзенчәлекләрен исәпкә алу һәм (яисә) исәпкә алу белешмәләрендәге хатаны яисә төрлечә бирелүне төзәтү максатларында гамәлгә ашырыла.

5. Әлеге статьяның 4 өлешендә каралган очраклардан тыш, торак пунктны үзгәртеп төзү үзгәртеп төзелә торган торак пункт территориясендә яшәүче халыкның әлеге Законның 14 статьясындагы 2 өлешендә каралган тавыш бирү юлы аша (гражданнар җыенында) белдерелгән ризалыгы белән гамәлгә ашырыла.

6. Торак пунктларны кушып берләштерү Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары белән гамәлгә ашырыла.

7. Кушып берләштерелә торган торак пунктлар, торак пунктка кертеп үзгәртеп төзелә торган торак пункт үзләренең статусларын (торак пункт статусын) югалталар һәм аларның территорияләре җирлекнең (шәһәр округының) җирле үзидарә

органнары карары нигезендә башка (яңа) торак пунктның состав өлешен тәшкил итә.

19 статья. **Торак пунктларны бетерү**

1. Торак пунктны бетерү торак пунктларны берләштерү нәтиҗәсендә гамәлгә ашырыла, шулай ук торак пунктта яшәүче халык, торак йортлар һәм торак төзү өчен яисә торак төзү максатларында комплекслы үзләштерү өчен гражданнарга һәм юридик затларга бирелгән җир кишәрлекләре булмаган очракларда рөхсәт ителә.

2. Торак пунктны бетерү территориясе чикләрендә бетерелә торган торак пункт урнашкан җирлекнең (шәһәр округының) вәкиллекле органы аша белдерелгән халык ризалыгы белән гамәлгә ашырыла.

3. Аерым очракларда, торак пунктны бетерүнең нигезле булуын билгеләү өчен, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы тарафыннан комиссия төзелергә мөмкин.»;

15) 5 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5 бүлек. **Административ-территориаль төзелешне үзгәртү мәсьәләләре буенча тәкъдим ителә торган документлар**

20 статья. **Районны төзегәндә һәм үзгәртеп төзегәндә тапшырыла торган документлар**

Районны төзегәндә һәм үзгәртеп төзегәндә Татарстан Республикасы Дәүләт Советына, Татарстан Республикасы законнары проектларын кертү өчен Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Регламентында каралган документлар һәм материалларны кушып, районны төзү яисә үзгәртеп төзү турында һәм Татарстан Республикасы Конституциясенең 65 статьясындагы 2 өлешенә үзгәрешләр кертү хакында Татарстан Республикасы законы проекты, шулай ук Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан географик объектларга атамалар бирү яисә аларның исемнәрен алмаштыру турындагы тәкъдимнәрне карау хакындагы Татарстан Республикасы законында каралган документлар тапшырыла. Бу чакта әлеге Татарстан Республикасы законы проектына аңлатма язуында муниципаль районны (муниципаль районнарны) үзгәртеп төзү турында Татарстан Республикасы Дәүләт

Советына кертелгән (кертелә торган) Татарстан Республикасы законы проекты хакындагы белешмәләр күрсәтелгән булырга тиеш.

21 статья. **Шәһәргә республика әһәмиятендәге шәһәр статусын биргәндә яисә шәһәрдән шул статусны алганда тапшырыла торган документлар**

1. Шәһәргә республика әһәмиятендәге шәһәр статусын бирү өчен Татарстан Республикасы Дәүләт Советына түбәндәге документлар тапшырыла:

1) шәһәргә республика әһәмиятендәге шәһәр статусын бирү инициативасы белән чыгу турында карар күчермәсе (тәкъдим коллегиаль орган тарафыннан кертелгән очракта);

2) Татарстан Республикасы законнары проектларын кертү өчен Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Регламентында каралган документлар һәм материалларны кушып, шәһәргә республика әһәмиятендәге шәһәр статусын бирү турында һәм Татарстан Республикасы Конституциясенең 65 статьясындагы 2 өлешенә үзгәреш кертү хакында Татарстан Республикасы законы проекты. Мондый чакта аңлатма язуында түбәндәгеләр күрсәтелә:

а) тиешле шәһәр җирлегенә шәһәр округы статусын биргән Татарстан Республикасы законы турында белешмәләр;

б) шәһәргә республика әһәмиятендәге шәһәр статусын бирүнең максатка ярашлы булуын нигезләү;

в) территориясе чикләрендә республика әһәмиятендәге шәһәр статусын бирүгә тәкъдим ителә торган шәһәр урнашкан шәһәр округы халкы саны;

г) республика әһәмиятендәге шәһәр территориясе чикләрендә урнашкан яисә урнаштыру планлаштырылган дәүләт хакимияте органнары, аларның территориаль органнары турында белешмәләр;

3) Татарстан Республикасы Президенты бәяләмәсе (тәкъдим Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан кертелмәгән очракта);

4) шәһәр округының шәһәргә республика әһәмиятендәге шәһәр статусын бирүгә халык ризалыгын белдерә торган вәкиллекле органы карары күчермәсе;

5) шәһәргә республика әһәмиятендәге шәһәр статусын бирүгә бәйле Татарстан Республикасы бюджетыннан таләп ителгән чыгымнарны хисаплауны үз эченә алган финанс-икътисадый нигезләү;

6) Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан географик объектларга исем бирү яисә аларның исемнәрен алмаштыру турындагы тәкъдимнәрне карау хакында Татарстан Республикасы законында каралган башка документлар.

2. Шәһәрдән республика әһәмиятендәге шәһәр статусын алу өчен Татарстан Республикасы Дәүләт Советына түбәндәге документлар тапшырыла:

1) шәһәрдән республика әһәмиятендәге шәһәр статусын алу инициативасы белән чыгу турында карар күчермәсе (тәкъдим коллегиаль орган тарафыннан кертелгән очракта);

2) Татарстан Республикасы законнары проектларын кертү өчен Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Регламентында каралган документлар һәм материалларны кушып, шәһәрдән республика әһәмиятендәге шәһәр статусын алу турында һәм Татарстан Республикасы Конституциясенең 65 статьясындагы 2 өлешенә үзгәреш кертү хакында Татарстан Республикасы законы проекты. Мондый чакта аңлатма язуында түбәндәгеләр күрсәтелә:

а) тиешле шәһәр җирлегеннән шәһәр округы статусын алган Татарстан Республикасы законы турында белешмәләр;

б) шәһәрдән республика әһәмиятендәге шәһәр статусын алуның максатка ярашлы булуын нигезләү;

в) республика әһәмиятендәге шәһәр статусын алу тәкъдим ителгән шәһәр халкы саны;

г) республика әһәмиятендәге шәһәр территориясе чикләрендә урнашкан дәүләт хакимияте органнары, аларның территориаль органнары турында белешмәләр;

3) Татарстан Республикасы Президенты бәяләмәсе (тәкъдим Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан кертелмәгән очракта);

4) шәһәрдән республика әһәмиятендәге шәһәр статусын алуга халык фикерен белдерә торган муниципаль районның вәкиллекле органы карары күчермәсе.

22 статья. **Шәһәрдәге районнарны төзегәндә, үзгәртеп төзегәндә, аларның чикләрен билгеләгәндә һәм аларны бетергәндә тапшырыла торган документлар**

1. Шәһәрдәге районнарны төзегәндә һәм үзгәртеп төзегәндә, аларның чикләрен билгеләгәндә Татарстан Республикасы Дәүләт Советына түбәндәге документлар тапшырыла:

1) шәһәрдәге районнарны төзү яисә үзгәртеп төзү, аларның чикләрен билгеләү инициативасы белән чыгу турында карар

күчермәсе (тәкъдим коллегиаль орган тарафыннан кертелгән очракта);

2) шәһәрдәге районнарның чикләре карта-схемасын һәм аның республика әһәмиятендәге шәһәрнең планлаштыру структурасы, урам-юл челтәре структурасы нигезендә сүзләр белән бирелгән тасвирламасын кушып, шулай ук Татарстан Республикасы законнары проектларын кертү өчен Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Регламентында каралган документлар һәм материалларны кушып, шәһәрдәге районнарны төзү яисә үзгәртеп төзү, аларның чикләрен билгеләү һәм әлеге Законның 7 статьясындагы 4 өлешенә үзгәрешләр кертү турында Татарстан Республикасы законы проекты. Мондый чакта аңлатма язуында түбәндәгеләр күрсәтелә:

а) шәһәрдәге районнарны төзү яисә үзгәртеп төзүнең максатка ярашлы булуын нигезләү;

б) тәкъдим ителә торган чикләрдә шәһәрдәге районнарда халык саны, шәһәрдәге районнарның социаль-икътисадый характеристикалары, шәһәр төзелеше һәм тарихи үзенчәлекләре, торак төзелешләре, җитештерү һәм социаль инфраструктура объектлары булу;

в) шәһәрдәге районнарның тәкъдим ителә торган чикләрен нигезләү;

г) шәһәрдәге районнарның планлаштырыла торган чикләрендә урнашкан яисә урнаштыру планлаштырылган дәүләт хакимияте органнары, аларның территориаль органнары турында белешмәләр;

3) Татарстан Республикасы Президенты бәяләмәсе (тәкъдим Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан кертелмәгән очракта);

4) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты бәяләмәсе (тәкъдим муниципаль районның, шәһәр округының вәкиллекле органы тарафыннан кертелгән очракта);

5) шәһәрдәге районнарның тәкъдим ителә торган чикләре мәсьәләсе буенча халык фикерен белү нәтиҗәләре турында документлар күчермәләре (тавыш бирү, җыелышлар, конференцияләр, гражданнарны сораштырулар, гавами тыңлаулар яисә халык фикерен белүнең норматив хокукый актларда каралган башка формаларының нәтиҗәләре турында беркетмәләр);

6) территориясе чикләрендә республика әһәмиятендәге шәһәр урнашкан шәһәр җирлегенең (шәһәр округының) вәкиллекле органының шәһәрдәге районнарны төзүгә яисә үзгәртеп төзүгә халык ризалыгын белдерә торган карары күчермәсе;

7) шәһәрдәге районнарны төзү яисә үзгәртеп төзү, аларның чикләрен билгеләү белән бәйле Татарстан Республикасы бюджетыннан таләп ителгән чыгымнарны хисаплауны үз эченә алган финанс-икътисадый нигезләү;

8) Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан географик объектларга атамалар бирү турында яисә аларның исемнәрен алмаштыру хакында тәкъдимнәрне карау турында Татарстан Республикасы законында каралган башка документлар.

2. Шәһәрдәге районнарны бетергәндә Татарстан Республикасы Дәүләт Советына түбәндәге документлар тапшырыла:

1) шәһәрдәге районнарны бетерү инициативасы белән чыгу турында карар күчермәсе (тәкъдим коллегиаль орган тарафыннан кертелгән очракта);

2) Татарстан Республикасы законнары проектларын кертү өчен Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Регламентында каралган документлар һәм материалларны кушып, шәһәрдәге районнарны бетерү һәм әлеге Законның 7 статьясындагы 4 өлешенә үзгәрешләр кертү турында Татарстан Республикасы законы проекты. Мондый чакта аңлатма язуында түбәндәгеләр күрсәтелә:

а) шәһәрдәге районнарны бетерүнең максатка ярашлы булуын нигезләү;

б) шәһәрдәге районны бетерү тәкъдим ителә торган территория чикләрендә урнашкан дәүләт хакимияте органнары, аларның территориаль органнары турында белешмәләр;

3) Татарстан Республикасы Президенты бәяләмәсе (тәкъдим Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан кертелмәгән очракта);

4) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты бәяләмәсе (тәкъдим муниципаль районның, шәһәр округының вәкиллекле органы тарафыннан кертелгән очракта);

5) территориясе чикләрендә республика әһәмиятендәге шәһәр урнашкан шәһәр җирлегенең (шәһәр округының) шәһәрдәге районнарны бетерүгә халык ризалыгын белдерә торган вәкиллекле органы карары күчермәсе.

### 23 статья. **Шәһәрдәге районнарның чикләрен үзгәрткәндә тапшырыла торган документлар**

Шәһәрдәге районнарның чикләрен үзгәрткәндә Татарстан Республикасы Дәүләт Советына түбәндәге документлар тапшырыла:

1) шәһәрдәге районнарның чикләрен үзгәртү инициативасы белән чыгу турында карар күчермәсе (тәкъдим коллегиаль орган тарафыннан кертелгән очракта);

2) шәһәрдәге районнарның чикләре карта-схемасын һәм аның республика әһәмиятендәге шәһәрнең планлаштыру структурасы, урам-юл челтәре структурасы нигезендә сүзләр белән бирелгән тасвирламасын кушып, шулай ук Татарстан Республикасы законнары проектларын кертү өчен Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Регламентында каралган документлар һәм материалларны кушып, шәһәрдәге районнарның чикләрен үзгәртү турында Татарстан Республикасы законы проекты. Мондый чакта аңлатма язуында түбәндәгеләр күрсәтелә:

а) шәһәрдәге районнарның чикләрен үзгәртүнең максатка ярашлы булуын нигезләү;

б) тәкъдим ителгән үзгәрешләрне исәпкә алган чикләрдә шәһәрдәге районнар халкы саны;

3) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты бәяләмәсе (тәкъдим муниципаль районның, шәһәр округының вәкиллекле органы тарафыннан кертелгән очракта);

4) шәһәрдәге районнарның чикләрен үзгәртү мәсьәләсе буенча халык фикерен белү нәтиҗәләре турында документларның күчермәләре (тавыш бирү, җыелышлар, конференцияләр, гражданнарны сораштырулар, гавами тыңлаулар яисә халык фикерен белүнең норматив хокукый актларда каралган башка формаларының нәтиҗәләре турында беркетмәләр);

5) шәһәр җирлеге вәкиллекле органының шәһәрдәге районнарның чикләрен үзгәртү мәсьәләсе буенча шул органның фикерен белдерә торган карары күчермәсе (җирлек территориясе чикләрендә урнашкан шәһәрдәге районнарның чикләре үзгәртелгән очракта);

6) шәһәр округы вәкиллекле органының шәһәрдәге районнарның чикләрен үзгәртү мәсьәләсе буенча шул органның фикерен белдерә торган карары күчермәсе (шәһәр округы территориясе чикләрендә урнашкан шәһәрдәге районнарның чикләре үзгәртелгән һәм тәкъдим шәһәр округы вәкиллекле органы тарафыннан кертелмәгән очракта);

7) шәһәрдәге районнарны үзгәртү белән бәйле Татарстан Республикасы бюджетыннан таләп ителгән чыгымнарны хисаплауны үз эченә алган финанс-икътисадый нигезләү.

24 статья. **Торак пункт төзегәндә тапшырыла торган документлар**

1. Әлеге Законның 17 статьясындагы 1 өлешенең 1 пунктында каралган очракта торак пункт төзегәндә Татарстан Республикасы Дәүләт Советына түбәндәге документлар тапшырыла:

1) торак пункт төзү инициативасы белән чыгу турында карар күчермәсе (тәкъдим коллегиаль орган тарафыннан кертелгән очракта);

2) торак пункт төзү турында Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары проекты;

3) Татарстан Республикасы Президенты бәяләмәсе (шәһәр төзегәндә һәм тәкъдим Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан кертелмәгәндә);

4) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты бәяләмәсе (тәкъдим муниципаль районның, шәһәр округының вәкиллекле органы тарафыннан кертелгән очракта);

5) территориясе чикләрендә төзелә торган торак пункт урнашкан шәһәр җирлегенең (шәһәр округының) торак пунктны төзүгә халык ризалыгын белдерә торган вәкиллекле органы карары күчермәсе (торак пункт шәһәр округы территориясе чикләрендә төзелү һәм тәкъдим шәһәр округының вәкиллекле органы тарафыннан кертелү очрагыннан тыш), шулай ук составына территориясе чикләрендә төзелә торган торак пункт урнашкан җирлек кергән муниципаль районның вәкиллекле органының торак пунктны төзү мәсьәләсе буенча шул органның фикерен белдерә торган карары күчермәсе (торак пункт җирлек территориясе чикләрендә төзелү һәм тәкъдим муниципаль районның вәкиллекле органы тарафыннан кертелмәү очрагыннан тыш);

6) җирлек яисә шәһәр округы составындагы торак пунктлар чикләренең (төзелә торган торак пунктлар чикләренең) җирлек яисә шәһәр округы генераль планында булган картасы күчермәсе;

7) түбәндәгеләр күрсәтелгән аңлатма язуы:

а) территорияләре чикләрендә торак пункт төзү тәкъдим ителә торган муниципаль берәмлек һәм административ-территориаль берәмлек;

б) торак пункт төзүнең максатка ярашлы булуын нигезләү;

в) торак пункт барлыкка килү сәбәпләре турында белешмәләр;

г) төзелә торган торак пунктның хәзерге һәм (яисә) фаразлана торган халкы саны;

д) төзергә тәкъдим ителә торган торак пунктның тиешле җирлектәге торак пунктларга карата урнашуы;

е) торак пунктны билгеле бер төргә тәкъдим ителгәнчә кертү, шулай ук бу тәкъдимне әлеге Законның 8 статьясындагы 5 – 9 өлешләренә ярашлы рәвештә нигезләү;

8) шәһәрдәге районнарны үзгәртү белән бәйле Татарстан Республикасы бюджетыннан таләп ителгән чыгымнарны хисаплауны үз эченә алган финанс-икътисадый нигезләү;

9) Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан географик объектларга атамалар бирү яисә аларның исемнәрен алмаштыру турында тәкъдимнәрне карау хакында Татарстан Республикасы законында каралган башка документлар.

2. Әлеге Законның 17 статьясындагы 1 өлешенең 2 пунктында каралган очракта торак пунктны төзегәндә Татарстан Республикасы Дәүләт Советына түбәндәге документлар тапшырыла:

1) торак пункт төзү инициативасы белән чыгу турында карар күчермәсе (тәкъдим коллегиаль орган тарафыннан кертелгән очракта);

2) торак пункт төзү турында Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары проекты;

3) Татарстан Республикасы Президенты бәяләмәсе (шәһәр төзегәндә һәм тәкъдим Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан кертелмәгәндә);

4) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты бәяләмәсе (тәкъдим муниципаль районның, шәһәр округының вәкиллекле органы тарафыннан кертелгән очракта);

5) торак пункт төзү мәсьәләсе буенча уздырылган тавыш бирү нәтиҗәләре турында беркетмә (гражданнар җыены карары) күчермәсе;

6) территориясе чикләрендә торак пункт төзү тәкъдим ителгән җирлекнең, муниципаль районның (шәһәр округының) вәкиллекле органының торак пункт төзү мәсьәләсе буенча шул органның фикерен белдерә торган карары күчермәсе (торак пункт шәһәр округы территориясе чикләрендә төзелү һәм тәкъдим шәһәр округының вәкиллекле органы тарафыннан кертелү яисә торак пункт җирлек территориясе чикләрендә төзелү һәм тәкъдим муниципаль районның вәкиллекле органы тарафыннан кертелмәү очракларыннан тыш);

7) җирлек яисә шәһәр округы составындагы торак пунктлар чикләренең (төзелә торган торак пунктлар чикләренең) җирлек яисә шәһәр округы генераль планында булган картасы күчермәсе;

8) әлеге Законның 17 статьясындагы 3 өлешендә каралган таләпләрнең үтәлүен раслый торган документларның күчермәләре;

9) түбәндәгеләр күрсәтелгән аңлатма язуы:

а) территорияләре чикләрендә торак пункт төзү тәкъдим ителә торган муниципаль берәмлек һәм административ-территориаль берәмлек;

б) торак пункт төзүнең максатка ярашлы булуын нигезләү;

в) төзелә торган торак пункт халкы саны;

г) төзүгә тәкъдим ителә торган торак пунктның тиешле җирлектәге торак пунктларга карата урнашуы;

д) торак пунктны билгеле бер төргә тәкъдим ителгәнчә кертү, шулай ук бу тәкъдимне әлеге Законның 8 статьясындагы 5 – 9 өлешләренә ярашлы рәвештә нигезләү;

10) торак пунктлар төзү белән бәйле Татарстан Республикасы бюджетыннан таләп ителгән чыгымнарны хисаплауны үз эченә алган финанс-икътисадый нигезләү;

11) Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан географик объектларга атамалар бирү яисә аларның исемнәрен алмаштыру турында тәкъдимнәрне карау хакында Татарстан Республикасы законында каралган башка документлар.

25 статья. **Торак пунктны үзгәртеп төзегәндә тапшырыла торган документлар**

1. Торак пунктларны кушып берләштергәндә Татарстан Республикасы Дәүләт Советына түбәндәге документлар тапшырыла:

1) торак пунктларны кушып берләштерү инициативасы белән чыгу турында карар күчермәсе (тәкъдим коллегиаль орган тарафыннан кертелгән очракта);

2) торак пунктларны кушып берләштерү турында Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары проекты;

3) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты бәяләмәсе (тәкъдим муниципаль районның, шәһәр округының вәкиллекле органы тарафыннан кертелгән очракта);

4) берләштерелә торган торак пунктларның һәрберсендә торак пунктларны кушып берләштерү мәсьәләсе буенча уздырылган тавыш бирүләрнең нәтиҗәләре турында беркетмәләрнең (гражданнар җыеннары карарларының) күчермәләре;

5) территориясе чикләрендә торак пунктларны берләштерү тәкъдим ителә торган җирлекнең, муниципаль районның (шәһәр округының) вәкиллекле органының торак пунктларны кушып

берләштерүгә шул органның ризалыгын белдерә торган карары күчермәсе (торак пунктлар шәһәр округы территориясе чикләрендә берләштерелү һәм тәкъдим шәһәр округының вәкиллекле органы тарафыннан кертелү яисә торак пунктлар җирлек территориясе чикләрендә берләштерелү һәм тәкъдим муниципаль районның вәкиллекле органы тарафыннан кертелмәү очракларыннан тыш);

6) җирлек яисә шәһәр округы составындагы торак пунктлар чикләренең (төзелә торган торак пунктлар чикләренең) җирлек яисә шәһәр округы генераль планында булган картасы күчермәсе;

7) түбәндәгеләр күрсәтелгән аңлатма язуы:

а) территорияләре чикләрендә торак пунктларны кушып берләштерү тәкъдим ителә торган муниципаль берәмлек һәм административ-территориаль берәмлек;

б) торак пунктларны кушып берләштерүнең максатка ярашлы булуын нигезләү;

в) әлеге Законның 18 статьясындагы 2 өлешендә каралган таләпләрнең үтәлүен раслый торган белешмәләр;

г) кушып берләштерелә торган торак пунктларның һәркайсының халкы саны;

д) кушып берләштерү юлы белән төзергә тәкъдим ителә торган торак пунктның тиешле җирлектә башка торак пунктларга карата урнашуы;

е) торак пунктны билгеле бер төргә тәкъдим ителгәнчә кертү, шулай ук бу тәкъдимне әлеге Законның 8 статьясындагы 5 – 9 өлешләренә ярашлы рәвештә нигезләү;

8) торак пунктларны кушып берләштерү белән бәйле Татарстан Республикасы бюджетыннан таләп ителгән чыгымнарны хисаплауны үз эченә алган финанс-икътисадый нигезләү;

9) Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан географик объектларга атамалар бирү яисә аларның исемнәрен алмаштыру турында тәкъдимнәрне карау хакында Татарстан Республикасы законында каралган башка документлар.

2. Торак пунктларны кертеп берләштергәндә Татарстан Республикасы Дәүләт Советына түбәндәге документлар тапшырыла:

1) торак пунктларны кертеп берләштерү инициативасы белән чыгу турында карар күчермәсе (тәкъдим коллегиаль орган тарафыннан кертелгән очракта);

2) Татарстан Республикасы законнары проектларын кертү өчен Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Регламентында каралган документлар һәм материалларны кушып, торак пунктларны кертеп берләштерү турында Татарстан Республикасы законы проекты. Мондый чакта аңлатма язуында түбәндәгеләр күрсәтелә:

а) территорияләре чикләрендә торак пунктларны кертеп берләштерү тәкъдим итешә торган муниципаль берәмлек һәм административ-территориаль берәмлек;

б) торак пунктларны кертеп берләштерүнең максатка ярашлы булуын нигезләү;

в) әлеге Законның 18 статьясындагы 2 өлешендә каралган таләпләрнең үтәлүен раслый торган белешмәләр;

г) кертеп берләштерелә торган торак пунктларның һәркайсының халкы саны;

д) берләштерелгән торак пунктның тиешле җирлектәге башка торак пунктларга карата урнашуы;

3) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты бәяләмәсе (тәкъдим муниципаль районның, шәһәр округының вәкиллекле органы тарафыннан кертелгән очракта);

4) кертелә торган торак пунктта торак пунктларны кертеп берләштерү мәсьәләсе буенча уздырылган тавыш бирүнең нәтиҗәләре турында беркетмәнең (гражданнар җыены карарының) күчермәсе;

5) торак пунктларны кертеп берләштерү мәсьәләсе буенча башка торак пунктны кертү тәкъдим итәлә торган торак пункт халкының фикерен белү нәтиҗәләре турында документларның күчермәләре (тавыш бирү, җыелышлар, конференцияләр, гражданнарны сораштырулар, гавами тыңлаулар яисә халык фикерен белүнең норматив хокукый актларда каралган башка формаларының нәтиҗәләре турында беркетмәләр);

6) территориясе чикләрендә торак пунктларны кертеп берләштерү тәкъдим итәлә торган җирлекнең, муниципаль районның (шәһәр округының) вәкиллекле органының торак пунктларны кертеп берләштерүгә шул органның ризалыгын белдерә торган карары күчермәсе (торак пунктлар шәһәр округы территориясе чикләрендә берләштерелү һәм тәкъдим шәһәр округының вәкиллекле органы тарафыннан кертелү яисә торак пунктлар җирлек территориясе чикләрендә берләштерелү һәм тәкъдим муниципаль районның вәкиллекле органы тарафыннан кертелмәү очракларыннан тыш);

7) җирлек яисә шәһәр округы составындагы торак пунктлар чикләренең (төзелә торган торак пунктлар чикләренең) җирлек яисә шәһәр округы генераль планында булган картасы күчермәсе.

3. Торак пунктны торак пунктларның башка категориясенә кертеп караганда Татарстан Республикасы Дәүләт Советына түбәндәге документлар тапшырыла:

1) торак пунктны башка категориягә кертеп карау инициативасы белән чыгу турында карар күчермәсе (тәкъдим коллегиаль орган тарафыннан кертелгән очракта);

2) Татарстан Республикасы законнары проектларын кертү өчен Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Регламентында каралган документлар һәм материалларны кушып, торак пунктны башка категориягә кертеп карау турында Татарстан Республикасы законы проекты. Мондый чакта аңлатма язуында түбәндәгеләр күрсәтелә:

а) территорияләре чикләрендә торак пункт урнашкан муниципаль берәмлек һәм административ-территориаль берәмлек;

б) торак пунктның әлеге Законның 8 статьясындагы 5 – 9 өлешләрендә билгеләнгән критерийларга туры килүе (туры килмәве) турында белешмәләрне дә кертеп, торак пунктны башка категориягә кертеп карауның максатка ярашлы булуын нигезләү;

3) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты бәяләмәсе (тәкъдим муниципаль районның, шәһәр округының вәкиллекле органы тарафыннан кертелгән очракта);

4) торак пунктны башка категориягә кертеп карау мәсьәләсе буенча уздырылган тавыш бирүнең нәтиҗәләре турында беркетмәнең (гражданнар җыены карарының) күчермәсе;

5) территориясе чикләрендә категориясен үзгәртү тәкъдим ителә торган торак пункт урнашкан җирлекнең, муниципаль районның (шәһәр округының) вәкиллекле органының торак пунктны башка категориягә кертеп карау мәсьәләсе буенча шул органның ризалыгын белдерә торган карары күчермәсе (шәһәр округы территориясе чикләрендә урнашкан торак пункт башка категориягә кертеп каралу һәм тәкъдим шәһәр округының вәкиллекле органы тарафыннан кертелү яисә җирлек территориясе чикләрендә урнашкан торак пункт башка категориягә кертеп каралу һәм тәкъдим муниципаль районның вәкиллекле органы тарафыннан кертелмәү очракларыннан тыш).

4. Торак пунктның төрен торак пунктларның бер категориясе кысаларында үзгәрткәндә Татарстан Республикасы Дәүләт Советына түбәндәге документлар тапшырыла:

1) торак пунктның төрен үзгәртү инициативасы белән чыгу турында карар күчермәсе (тәкъдим коллегиаль орган тарафыннан кертелгән очракта);

2) Татарстан Республикасы законнары проектларын кертү өчен Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Регламентында каралган документлар һәм материалларны кушып, торак пунктның

төрен үзгәртү турында Татарстан Республикасы законы проекты. Мондый чакта аңлатма язуында түбәндәгеләр күрсәтелә:

а) территорияләре чикләрендә торак пункт урнашкан муниципаль берәмлек һәм административ-территориаль берәмлек;

б) шәһәр торак пунктын үзгәртеп төзегәндә – торак пунктның төрен үзгәртүнең максатка ярашлы булуын нигезләү, шул исәптән торак пунктның әлеге Законның 8 статьясындагы 5 һәм 6 өлешләрендә билгеләнгән критерийларга туры килүе (туры килмәве) турында белешмәләр; авыл торак пунктын үзгәртеп төзегәндә – дәлил булып торган документларның күчермәләрен кушып, исәпкә алу белешмәләрендә торак пунктның төренә кагылышлы хаталар йә төрлечә бирелешләр (булган очракта) турында белешмәләр, торак пунктның әлеге Законның 8 статьясындагы 7 – 9 өлешләрендә билгеләнгән критерийларга туры килүе (туры килмәве) турында белешмәләр;

3) Татарстан Республикасы Президенты бәяләмәсе (торак пунктны шәһәргә үзгәртеп төзегәндә һәм тәкъдим Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан кертелмәгәндә);

4) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты бәяләмәсе (тәкъдим муниципаль районның, шәһәр округының вәкиллекле органы тарафыннан кертелгән очракта);

5) торак пунктның төрен үзгәртү мәсьәләсе буенча уздырылган тавыш бирүнең нәтиҗәләре турында беркетмәнең (гражданнар җыены карарының) күчермәсе (авыл торак пунктының төрен үзгәртү очракларыннан тыш);

6) территориясе чикләрендә төрен үзгәртү тәкъдим ителә торган торак пункт урнашкан җирлекнең, муниципаль районның (шәһәр округының) вәкиллекле органының торак пунктның төрен үзгәртү мәсьәләсе буенча шул органның ризалыгын белдерә торган карары күчермәсе (шәһәр округы территориясе чикләрендә урнашкан торак пунктның төре үзгәртелү һәм тәкъдим шәһәр округының вәкиллекле органы тарафыннан кертелү яисә җирлек территориясе чикләрендә урнашкан торак пунктның төре үзгәртелү һәм тәкъдим муниципаль районның вәкиллекле органы тарафыннан кертелмәү очракларыннан тыш).

26 статья. **Торак пунктны бетергәндә тапшырыла торган документлар**

Торак пунктны бетергәндә, торак пунктларны берләштерү очрагыннан тыш, Татарстан Республикасы Дәүләт Советына түбәндәге документлар тапшырыла:

1) торак пунктны бетерү инициативасы белән чыгу турында карар күчермәсе (тәкъдим коллегиаль орган тарафыннан кертелгән очракта);

2) Татарстан Республикасы законнары проектларын кертү өчен Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Регламентында каралган документлар һәм материалларны кушып, торак пунктны бетерү турында Татарстан Республикасы законы проекты. Мондый чакта аңлатма язуында түбәндәгеләр күрсәтелә:

а) территорияләре чикләрендә торак пунктны бетерү тәкъдим ителә торган муниципаль берәмлек һәм административ-территориаль берәмлек;

б) торак пунктны бетерүнең максатка ярашлы булуын нигезләү;

в) бетерү тәкъдим ителә торган торак пункт территориясендә халыкның, торак йортларның һәм торак төзү өчен яисә торак төзү максатларында комплекслы үзләштерү өчен гражданнарга һәм юридик затларга бирелгән җир кишәрлекләренең булмавы турында белешмәләр;

г) бетерү тәкъдим ителә торган торак пунктта кешеләрнең даими яисә күбесенчә яшәвен һәм тормыш итүен торгызу өчен нигезләрнең булмавы турында сәбәпләре күрсәтелгән нәтиҗә;

3) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты бәяләмәсе (тәкъдим муниципаль районның, шәһәр округының вәкиллекле органы тарафыннан кертелгән очракта);

4) гражданнарны булу һәм яшәү урыны буенча теркәү исәбенә алуны гамәлгә ашыра торган органның бетерү тәкъдим ителә торган торак пункт территориясендә булу яисә яшәү урыны буенча теркәлгән гражданнарның булмавы турында белешмә язуы;

5) торак урыннарны техник исәпкә алуны (дәүләт кадастр исәбенә алуны) гамәлгә ашыра торган органның бетерү тәкъдим ителә торган торак пункт территориясендә торак урыннарның булмавы турында белешмә язуы;

6) җир кишәрлекләрен кадастр исәбенә алуны (дәүләт кадастр исәбенә алуны) гамәлгә ашыра торган органның бетерү тәкъдим ителә торган торак пункт территориясендә торак төзү өчен яисә торак төзү максатларында комплекслы үзләштерү өчен гражданнарга һәм юридик затларга бирелгән җир кишәрлекләренең булмавы турында белешмә язуы;

7) территориясе чикләрендә бетерү тәкъдим ителә торган торак пункт урнашкан җирлекнең, муниципаль районның (шәһәр округының) вәкиллекле органының торак пунктны

бетерү мәсьәләсе буенча шул органның ризалыгын белдерә торган карары күчермәсе (шәһәр округы территориясе чикләрендә урнашкан торак пункт бетерелү һәм тәкъдим шәһәр округының вәкиллекле органы тарафыннан кертелү яисә җирлек территориясе чикләрендә урнашкан торак пункт бетерелү һәм тәкъдим муниципаль районның вәкиллекле органы тарафыннан кертелмәү очракларыннан тыш);

8) бетерү тәкъдим ителә торган торак пункт чикләренең җирлек яисә шәһәр округы генераль планында булган картасы күчермәсе, ә генераль план булмаганда – бетерү тәкъдим ителә торган торак пунктның җирлек, шәһәр округы чикләрендә урнашу урыны күрсәтелгән карта-схемасы.

27 статья. **Административ-территориаль төзелеш мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советына тапшырыла торган документларга карата таләпләр**

1. Административ-территориаль төзелеш мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советына тапшырыла торган документлар вәкаләтле вазыйфаи зат тарафыннан имзалана һәм тиешле тәкъдимне Татарстан Республикасы Дәүләт Советына керткән органның мөһере белән раслана.

2. Картографик материаллар (торак пунктларның чикләре карта-схемалары, карталары), масштабы һәм шартлы билгеләре күрсәтелеп, А3 форматында төсле вариантта тапшырыла.»;

16) 6 бүлекнең исемендә «Татарстан Республикасының административ-территориаль берәмлекләрен» сүзләрен «Административ-территориаль берәмлекләрне һәм торак пунктларны» сүзләренә алмаштырырга;

17) 28 һәм 29 статьяларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«28 статья. **Административ-территориаль берәмлекләрне һәм торак пунктларны исәпкә алу һәм теркәү**

1. Административ-территориаль берәмлекләр һәм торак пунктлар Татарстан Республикасында административ-территориаль берәмлекләр һәм торак пунктлар реестрында исәпкә алынырга һәм теркәлергә тиеш.

2. Татарстан Республикасында административ-территориаль берәмлекләр һәм торак пунктлар реестрының эчтәлеген һәм алып бару тәртибен Татарстан Республикасы Президенты билгели.

3. Татарстан Республикасында административ-территориаль берәмлекләр һәм торак пунктлар реестрын алып баруны Татарстан Республикасы Президенты вәкаләтләр биргән орган гамәлгә ашыра.

29 статья. **Татарстан Республикасының административ-территориаль төзелеше белешмәлеге**

Татарстан Республикасының административ-территориаль төзелеше белешмәлеге 10 елга кимендә бер тапкыр нәшер ителә, анда Татарстан Республикасының административ-территориаль берәмлекләренең һәм торак пунктларының рәсми исемнәре татар һәм рус телләрендә бирелә.».

**2 статья**

1. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

1) район территориясе чиге тиешле муниципаль район территориясе чигенә туры килә;

2) республика әһәмиятендәге шәһәр территориясе чиге, әгәр шәһәр шәһәр җирлеге составына керсә, шәһәр чигенә яисә, әгәр шәһәр шәһәр округы составына керсә, шәһәр округы чигенә туры килә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты 2014 елның 1 маена кадәр, Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең вәкаләтле органы белән килештереп, Казан шәһәрендәге районнарның чикләре тасвирламасы турында Татарстан Республикасы законы проектын билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Дәүләт Советына кертергә тиеш.

**3 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 елның 17 июле
№ 63-ТРЗ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

## 973. Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексын кабул итүгә бәйле рәвештә «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 26 статьясына үзгәреш кертү һәм Татарстан Республикасы аерым закон актларының (закон актлары нигезләмәләренең) үз көчләрен югалтуын тану хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2013 елның 28 июнендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 26 статьясындагы 3 өлешен (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 7 (II өлеш); 2005, № 2, № 4 (I өлеш), № 6 (II өлеш), № 11; 2006, № 4, № 7 (I өлеш); 2007, № 7 (I өлеш), № 8; 2008, № 1; 2009, № 1, № 12 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш), № 12 (II өлеш); 2011, № 3, № 11 (I өлеш); 2012, № 7 (I өлеш), № 11 (I өлеш); Ватаным Татарстан, 2013, 20 март) түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Контракт буенча билгеләнеп куела торган җирле администрация башлыгы вазыйфасына кандидатлар «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законда, Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексында, муниципаль хокукый актларда билгеләнгән квалификация таләпләренә туры килергә тиеш. Контракт буенча билгеләнеп куела торган муниципаль районның (шәһәр округының) җирле администрация башлыгы вазыйфасына кандидатларга өстәмә таләпләр Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы белән билгеләнә һәм муниципаль район (шәһәр округы) уставы белән билгеләнергә мөмкин. Контракт буенча билгеләнеп куела торган җирлек җирле администрациясе башлыгы вазыйфасына кандидатларга өстәмә таләпләр җирлек уставы белән билгеләнергә мөмкин.».

**2 статья**

Түбәндәгеләрне үз көчләрен югалткан дип танырга:

1) «Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт турында» 2008 елның 17 гыйнварындагы 5-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2008, № 1);

2) «Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2008 елның 23 июлендәге 29-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2008, № 7 (I өлеш);

3) «Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт вазыйфалары реестры турында» 2008 елның 22 ноябрендәге 114-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2008, № 11 (III өлеш);

4) «Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын, Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын, Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче (биләгән) затларны пенсия белән тәэмин итү мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2008 елның 18 декабрендәге 120-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 3 статьясын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2008, № 12 (I өлеш);

5) «Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт вазыйфалары һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары нисбәте турында» 2008 елның 26 декабрендәге 135-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2008, № 12 (V өлеш);

6) «Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт турында» Татарстан Республикасы Законының 13 һәм 19 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 2008 елның 26 декабрендәге 136-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2008, № 12 (VI өлеш);

7) «Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2009 елның 9 февралендәге 13-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 2);

8) «Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт турында» Татарстан Республикасы Законының 32 һәм 34 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 2009 елның 27 июлендәге 28-ТРЗ но-

мерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 7 – 8 (I өлеш);

9) «Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын яисә муниципаль, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын яисә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче (биләгән) затларны пенсия белән тәэмин итү өлешендә Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2010 елның 13 гыйнварындагы 5-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 3 статьясын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2010, № 1 – 2);

10) «Җирле үзидарә органнары эшчәнлеген камилләштерүгә бәйле рәвештә Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2010 елның 30 июлендәге 58-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 2 статьясын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2010, № 7 (II өлеш);

11) «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2011 елның 19 маендагы 24-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 3 статьясын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2011, № 5);

12) «Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт вазыйфалары реестры турында» Татарстан Республикасы Законына һәм «Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт вазыйфалары һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары нисбәте турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2011 елның 24 сентябрендәге 62-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2011, № 9);

13) «Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт вазыйфалары реестры турында» Татарстан Республикасы Законына һәм «Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт вазыйфалары һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары нисбәте турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2012 елның 14 июлендәге 51-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2012, № 7 (I өлеш);

14) «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законына һәм «Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2012 елның 14 июлендәге 52-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 2 статьясын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2012, № 7 (I өлеш);

15) «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2013 елның 25 февралендәге 13-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 3 статьясын (Ватаным Татарстан, 2013, 2 март);

16) «Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына үзгәреш кертү хакында» 2013 елның 11 мартындагы 21-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (Ватаным Татарстан, 2013, 19 март);

17) «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында» Федераль закон кабул ителүгә бәйле рәвештә Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2013 елның 29 мартындагы Татарстан Республикасы Законының 5 статьясын (Ватаным Татарстан, 2013, 30 март).

**3 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы үз көченә кергән көннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 елның 17 июле
№ 64-ТРЗ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

## 974. «Вөждан иреге турында һәм дини берләшмәләр турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2013 елның 28 июнендә
кабул ителде

**1 статья**

«Вөждан иреге турында һәм дини берләшмәләр турында» 1999 елның 14 июлендәге 2279 номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1999, № 8 (II өлеш); 2001, № 12; 2004, № 2 (I өлеш); 2008, № 6; 2010, № 3; 2011, № 6 (I өлеш); 2012, № 8) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 5 статьяның 7 пунктындагы икенче абзацында «үз билгеләүләре нигезендә» сүзләрен «тиешле шартлар, таләпләр нигезендә һәм үзенең эчке билгеләүләре белән карала торган тәртиптә» сүзләренә алмаштырырга;

2) 17 статьяның 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Дини оешмалар үзләренең эчке билгеләүләре нигезендә дин әһелләре һәм дини персонал эшчәнлегенең шартларын, шулай ук аларга карата таләпләр, шул исәптән дин белеме өлешендә, билгеләргә хокуклы.»;

3) 27 статьяда:

а) 1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Дини оешмалар үз уставларында каралган очракларда хезмәткәрләр белән хезмәт шартнамәләре төзиләр.»;

б) 2 пунктта «(контракт)» сүзен төшереп калдырырга;

в) 3 пунктта «(контрактлары)» сүзен төшереп калдырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 елның 17 июле
№ 65-ТРЗ

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

### 975. «Татарстан Республикасы Әгерҗе суд районы буенча Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларының суд участоклары чикләре турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2013 елның 28 июнендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасы Әгерҗе суд районы буенча Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларының суд участоклары чикләре турында» 2010 елның 31 декабрендәге 131-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2010, № 12 (II өлеш); Ватаным Татарстан, 2013, 25 июнь), кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«Татарстан Республикасы Әгерҗе суд
районы буенча Татарстан Республикасы
җәмәгать судьяларының суд участоклары
чикләре турында» Татарстан
Республикасы Законына кушымта

## Татарстан Республикасы Әгерҗе суд районы буенча Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларының суд участоклары чикләре тасвирламасы

### 1 нче суд участогы

1 нче суд участогы чигенә «Әгерҗе шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясенең көнчыгыш өлеше керә, аның чиге шәһәрнең Татарстан Республикасының Удмурт Республикасы белән административ чиге уза торган төньяк чигендә К.Маркс урамы һәм Әгерҗе – Кече Пурга автомобиль юлы күчәр сызыклары киселешендә урнашкан ноктадан алып К.Маркс урамының күчәр сызыгы буйлап көньякка таба, так якта урнашкан йортларны кертеп, Әгерҗе – Иж-Бубый автомобиль юлына кадәр уза, аннары шул ук юнәлештә Әгерҗе – Иж- Бубый автомобиль юлының күчәр сызыгы буйлап «Әгерҗе шәһәре» муниципаль берәмлегенең көньяк чигенә кадәр бара, шуннан соң сулга борыла һәм Иж- Бубый авыл җирлеге белән «Әгерҗе шәһәре» муниципаль берәмлеге чиге буйлап көнчыгышка таба Татарстан Республикасы административ чиге белән кисешү ноктасына кадәр үтә, аннары төньяк юнәлештә Татарстан Республикасының Удмурт Республикасы белән административ чиге буйлап К.Маркс урамы һәм Әгерҗе – Кече Пурга автомобиль юлы күчәр сызыклары киселешендә урнашкан башлангыч ноктага кадәр бара.

1 нче суд участогы чигенә түбәндәге муниципаль берәмлекләрнең территорияләре керә: Әгерҗе муниципаль районының Азево, Бима, Девәтернә, Исәнбай, Кадыбаш, Кичкетаң, Красный Бор, Күләгәш, Салагыш, Иске Эсләк, Иске Чекалда һәм Тәбәрле авыл җирлекләре.

### 2 нче суд участогы

2 нче суд участогы чигенә «Әгерҗе шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясенең көнбатыш өлеше керә, аның чиге шәһәрнең Татарстан Республикасының Удмурт Республикасы белән административ чиге уза торган төньяк чигендә К.Маркс урамы һәм Әгерҗе – Кече Пурга автомобиль юлы күчәр сызыклары

киселешендә урнашкан ноктадан алып К.Маркс урамының күчәр сызыгы буйлап көньякка таба, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Әгерҗе – Иж-Бубый автомобиль юлына кадәр уза, аннары шул ук юнәлештә Әгерҗе – Иж-Бубый автомобиль юлының күчәр сызыгы буйлап «Әгерҗе шәһәре» муниципаль берәмлегенең көньяк чигенә кадәр бара, шуннан соң уңга борыла һәм Иж-Бубый авыл җирлеге белән «Әгерҗе шәһәре» муниципаль берәмлеге чиге буйлап көнбатышка таба Татарстан Республикасының административ чиге белән кисешү ноктасына кадәр уза, аннары Татарстан Республикасының Удмурт Республикасы белән административ чиге буйлап төньяк юнәлештә К.Маркс урамы һәм Әгерҗе – Кече Пурга автомобиль юлы күчәр сызыклары киселешендә урнашкан башлангыч ноктага кадәр бара.

2 нче суд участогы чигенә түбәндәге муниципаль берәмлекләрнең территорияләре керә: Әгерҗе муниципаль районының Иж-Бубый, Кадрәк, Кырынды, Кодаш, Көчек, Яңа Бәзәкә, Сарсак-Умга, Тирсә һәм Шаршады авыл җирлекләре.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 елның 17 июле
№ 66-ТРЗ

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

### 976. «Кеше һәм гражданның хокукларын һәм ирекләрен яклау мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы законнарын һәм башка норматив хокукый актларын бастырып чыгару һәм аларның үз көчләренә керү тәртибе турында» Татарстан Республикасы Законының 5 статьясына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2013 елның 28 июнендә
кабул ителде

**1 статья**

«Кеше һәм гражданның хокукларын һәм ирекләрен яклау мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы законнарын һәм башка норматив хокукый актларын бастырып чыгару һәм аларның үз көчләренә керү тәртибе турында» Татарстан Республикасы Законының 5 статьясындагы беренче өлешенә (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2002, № 11; 2003, № 1; 2009, № 7 – 8 (I өлеш), түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәп, үзгәреш кертергә: «Әлеге Законның 3 статьясындагы икенче өлешенең алтынчы абзацында санап үтелгән норматив хокукый актларның рәсми басылып чыккан көне дип күрсәтелгән актларны «Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы хокукый мәгълүматының рәсми сайты»нда (PRAVO.TATARSTAN.RU) беренче тапкыр рус һәм татар телләрендә урнаштыру (бастырып чыгару) да санала.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 елның 17 июле
№ 67-ТРЗ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

## 977. Мәгариф турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2013 елның 28 июнендә
кабул ителде

1 бүлек. **Гомуми нигезләмәләр**

1 статья. **Әлеге Законның җайга салу предметы**

Әлеге Закон Татарстан Республикасында мәгариф өлкәсендәге мөнәсәбәтләрне федераль законнар белән Россия Федерациясе субъектлары вәкаләтләренә кертелгән вәкаләтләр чикләрендә Татарстан Республикасы үзенчәлекләренә яраклаштырып җайга сала.

2 статья. **Татарстан Республикасында мәгариф өлкәсендәге мөнәсәбәтләрне хокукый җайга салу**

1. Татарстан Республикасында мәгариф өлкәсендәге законнар Россия Федерациясе Конституциясенә, Татарстан Республикасы Конституциясенә нигезләнә һәм «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законнан (алга таба – Федераль закон), аның нигезендә кабул ителә торган башка федераль законнардан, Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актларыннан, әлеге Законнан, Татарстан Республикасының башка законнарыннан һәм Татарстан Республикасының бүтән норматив хокукый актларыннан гыйбарәт.

2. Мәгариф өлкәсендәге мөнәсәбәтләрне җайга сала торган һәм Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының, Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарының норматив хокукый актларындагы нормалар әлеге Закон, Татарстан Республикасының башка законнары нормаларына туры килергә тиеш һәм мәгариф өлкәсендә хокукларны чикли яисә, Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән гарантияләр белән чагыштырганда, гарантияләр бирү дәрәҗәсен төшерә алмый.

3. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтен педагог һәм фәнни-педагог хезмәткәрләр вазыйфаларында узучы

гражданнарга, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтен узучы һәм белем алучы гражданнарга мәгариф турында законнарның гамәлдә булуы дәүләт хезмәте турында Россия Федерациясе законнарында каралган үзенчәлекләрне исәпкә алып кагыла.

4. Әлеге Законда кулланыла торган төшенчәләр Федераль законда билгеләнгән мәгънәләрендә кулланыла.

3 статья. **Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының мәгариф өлкәсендәге вәкаләтләре**

1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының мәгариф өлкәсендәге вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) мәгариф өлкәсендәге мөнәсәбәтләрне законнар белән җайга салу;

2) мәгариф өлкәсендә Татарстан Республикасы законнарын саклау һәм үтәүне тикшереп торуны гамәлгә ашыру;

3) федераль законнарда һәм Татарстан Республикасы законнарында каралган бүтән вәкаләтләрне гамәлгә ашыру.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының мәгариф өлкәсендәге вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) Татарстан Республикасында мәгарифне үстерү программаларын эшләү һәм гамәлгә ашыру;

2) Татарстан Республикасы мәгариф оешмаларын (шул исәптән югары белем бирү оешмаларын) төзү, үзгәртеп төзү, бетерү, Татарстан Республикасы мәгариф оешмаларын гамәлгә куючылар функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыру;

3) муниципаль мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә белем алуга, муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем алуга хокукларын гамәлгә ашыруның дәүләт гарантияләрен тәэмин итү, муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында балаларга өстәмә белем бирүне, хезмәт өчен түләүгә, дәреслекләр һәм уку-укыту ярдәмлекләре, укыту чаралары, уеннар, уенчыклар сатып алуга чыгымнарны (биналарны тәртиптә тоту һәм коммуналь хезмәт күрсәтүләр өчен түләүгә чыгымнардан тыш) кертеп, җирле бюджетларга субвенцияләр бүлеп бирү юлы белән Татарстан Республикасы законнары белән билгеләнә торган нормативлар нигезендә тәэмин итү;

4) Татарстан Республикасы дәүләт мәгариф оешмаларында гомуми белем бирүне оештыру;

5) Татарстан Республикасы дәүләт мәгариф оешмаларында балаларны карап тору һәм карау өчен, балаларны тоту өчен шартлар тудыру;

6) хосусый мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында мәктәпкәчә белем алуны, дәүләт аккредитациясе булган төп гомуми белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган хосусый гомуми белем бирү оешмаларында мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем алуны шул мәгариф оешмаларына, хезмәт өчен түләүгә, дәреслекләр һәм уку-укыту ярдәмлекләре, укыту чаралары, уеннар, уенчыклар сатып алуга чыгымнарны (биналарны тәртиптә тоту һәм коммуналь хезмәт күрсәтүләр өчен түләүгә чыгымнардан тыш) кертеп, чыгымнарын түләүгә субсидияләр бирү юлы белән бу өлешнең 3 пунктында күрсәтелгән нормативлар нигезендә финанс белән тәэмин итү;

7) һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез урта һөнәри белем алуга хокукны гамәлгә ашыруның дәүләт гарантияләрен тәэмин итүне кертеп, урта һөнәри белем бирүне оештыру;

8) Татарстан Республикасы дәүләт мәгариф оешмаларында балаларга өстәмә белем бирүне оештыру;

9) Татарстан Республикасы дәүләт мәгариф оешмаларында өстәмә һөнәри белем бирүне оештыру;

10) муниципаль мәгариф оешмаларын һәм Татарстан Республикасы мәгариф оешмаларын башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белемнең дәүләт аккредитациясе булган уку-укыту программаларын белем бирү эшчәнлеген башкара торган оешмалар тарафыннан гамәлгә ашырганда куллану өчен тәкъдим ителгән дәреслекләрнең федераль исемлеге нигезендә дәреслекләр һәм күрсәтелгән уку-укыту программаларын гамәлгә ашырганда куллану рөхсәт ителгән уку-укыту ярдәмлекләре белән тәэмин итүне оештыру, шул исәптән аның тәртибен билгеләү;

11) белем бирү системасында мониторингны гамәлгә ашыруны Татарстан Республикасы дәрәҗәсендә тәэмин итү;

12) төп гомуми белем бирү программаларын үзләштерүдә, үз үсешендә һәм социаль яраклашуында кыенлыклар кичерүче белем алучыларга психологик-педагогик, медицина һәм социаль ярдәм күрсәтүне оештыру;

13) дәүләт һәм муниципаль мәгариф оешмалары һәм озак дәвалануга мохтаҗ белем алучыларның, шулай ук инвалид балаларның ата-аналары (законлы вәкилләре) арасында мөнәсәбәтләрне төп гомуми белем бирү программалары буенча

өйдә яисә медицина оешмаларында укытуны оештыру өлешендә регламентлаштыру һәм рәсмиләштерү тәртибен билгеләү;

14) белем алучыларны Татарстан Республикасы бюджетларының бюджет ассигнованиеләре исәбеннән туклану белән тәэмин итү очракларын һәм тәртибен билгеләү;

15) белем алучыларны Татарстан Республикасы бюджетларының бюджет ассигнованиеләре исәбеннән әйберләтә мөлкәт (кием-салым), шул исәптән форма киеме белән тәэмин итү очракларын һәм тәртибен билгеләү;

16) федераль законнарда һәм Татарстан Республикасы законнарында каралган башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыру.

3. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары муниципаль мәгариф оешмаларында белем алучыларның һәм хосусый гомуми белем бирү оешмаларында дәүләт аккредитациясе булган төп гомуми белем бирү программалары буенча белем алучыларның туклануын оештыру чараларын өстәмә финанс белән тәэмин итәргә, шулай ук муниципаль мәгариф оешмаларында балаларга өстәмә белем бирүгә дәүләт ярдәмен күрсәтергә хокуклы.

4. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары Татарстан Республикасының югары белем мәгариф оешмаларында югары белемне конкурс нигезендә бирүне оештыруны тәэмин итәргә хокуклы.

5. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары Россия Федерациясе законнары нигезендә мәгариф оешмаларына ярдәм күрсәтә алалар.

### 4 статья. **Мәгариф өлкәсендә идарә итү**

1. Татарстан Республикасында мәгариф өлкәсендә дәүләт идарәсен үз вәкаләтләре чикләрендә федераль дәүләт хакимияте органнары һәм Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы гамәлгә ашыра. Муниципаль районнарда һәм шәһәр округларында мәгариф өлкәсендә идарәне тиешле җирле үзидарә органнары гамәлгә ашыра.

2. Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мәгариф өлкәсендә дәүләт идарәсен гамәлгә ашыра торган органы үз вәкаләтләре чикләрендә:

1) якынча төп гомуми белем бирү программаларына экспертизаны (региональ, милли һәм этномәдәни үзенчәлекләрне исәпкә алу өлешендә) аларның баскычын һәм юнәлешен исәпкә алып уздыруда катнаша;

2) Татарстан Республикасының региональ һәм этномәдәни үзенчәлекләрен исәпкә алуны тәэмин итү, гражданнарның Россия Федерациясе халыклары телләреннән булган туган телдә белем алуга һәм Россия Федерациясе халыклары телләреннән булган туган телне һәм Россия халыклары әдәбиятын туган телдә өйрәнүгә хокукларын гамәлгә ашыру максатларында дәреслекләргә экспертиза уздыруда катнаша;

3) Россия Федерациясе халыклары телләреннән булган туган тел һәм Россия халыклары әдәбияты буенча уку-укыту ярдәмлекләрен туган телдә чыгаруны гамәлгә ашыра торган оешмаларны сайлап алуда катнаша;

4) белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган һәм Татарстан Республикасы карамагында булган оешмаларның педагог хезмәткәрләрнең, белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган муниципаль һәм хосусый оешмаларның педагог хезмәткәрләрнең квалификация категорияләрен билгеләү максатларында аттестация уздыруны гамәлгә ашыра торган аттестация комиссияләрен төзи;

5) Татарстан Республикасы территориясендә төп гомуми һәм урта гомуми белемнең уку-укыту программалары буенча йомгак дәүләт аттестациясен уздыруны тәэмин итә;

6) төп гомуми һәм урта гомуми белемнең уку-укыту программалары буенча белем алучылар, Россия Федерациясе халыклары телләреннән булган туган телне һәм Россия халыклары әдәбиятын Россия Федерациясе халыклары телләреннән булган туган телдә өйрәнгән һәм йомгак дәүләт аттестациясен узу өчен Россия Федерациясе халыклары телләреннән булган туган телдән һәм Россия халыклары әдәбиятыннан имтиханны Россия Федерациясе халыклары телләреннән булган туган телдә сайлаучылар өчен урта гомуми белемнең уку-укыту программалары буенча йомгак дәүләт аттестациясен уздыру рәвешләрен һәм тәртибен билгели;

7) Татарстан Республикасы территориясендә төп гомуми яисә урта гомуми белемнең уку-укыту программалары буенча йомгак дәүләт аттестациясен уздырганда җәмәгатьчелек күзәтүчеләре буларак гражданнарны аккредитацияләүне гамәлгә ашыра;

8) төп гомуми һәм урта гомуми белемнең төп уку-укыту программаларын үзләштергән белем алучыларга йомгак дәүләт аттестациясен уздыруны тәэмин итүнең региональ мәгълүмат системаларын булдыруны һәм алып баруны оештыруны гамәлгә ашыра;

9) төп гомуми һәм урта гомуми белемне аерым уку предметларын тирәнтен өйрәнеп алу өчен яисә профильле белем алу өчен дәүләт һәм муниципаль мәгариф оешмаларына кабул иткәндә йә күчергәндә индивидуаль (конкурс нигезендә) сайлап алу очракларын һәм тәртибен билгели;

10) федераль башкарма хакимиятнең мәгариф өлкәсендә тикшереп тору һәм күзәтү функцияләрен гамәлгә ашыра торган органына белем турында һәм (яисә) квалификация турында бирелгән документлар хакында, белем алу турында бирелгән документлар хакында белешмәләрне бу белешмәләрне «Белем турында һәм (яисә) квалификация турында документлар, белем алу турында документлар хакында белешмәләрнең федераль реестры» федераль мәгълүмат системасына кертү юлы белән тапшыра;

11) балаларының мәктәпкәчә белемне гаиләдә белем алу рәвешендә алуын тәэмин итүче балигъ булмаган белем алучыларның ата-аналарына (законлы вәкилләренә) бушлай методик, психологик-педагогик, диагностик һәм консультатив ярдәм күрсәтүне тәэмин итә;

12) Татарстан Республикасы территориясендә йомгак дәүләт аттестациясен уздырганда төп гомуми һәм урта гомуми белемнең уку-укыту программалары буенча йомгак дәүләт аттестациясен уздыру өчен дәүләт имтихан комиссияләрен төзи;

13) ел саен «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә (алга таба – «Интернет» челтәре) рәсми сайтка Татарстан Республикасында мәгарифнең торышына һәм перспективаларына анализ турында йомгак (еллык) хисап урнаштыра;

14) федераль законнарда һәм Татарстан Республикасы законнарында каралган башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.

### 5 статья. **Муниципаль районнар һәм шәһәр округлары җирле үзидарә органнарының мәгариф өлкәсендәге вәкаләтләре**

1. Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнары Федераль закон нигезендә мәгариф өлкәсендә җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.

2. «Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында» 1999 елның 6 октябрендәге 184-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасының

мәгариф өлкәсендәге аерым дәүләт вәкаләтләре, гамәлгә ашыру өчен, җирле үзидарә органнарына тапшырылырга мөмкин.

## 2 бүлек. **Татарстан Республикасында мәгариф системасы нигезләре**

### 6 статья. **Мәгариф системасы структурасы**

1. Татарстан Республикасында мәгариф системасына түбәндәгеләр керә:

1) федераль дәүләт мәгариф стандартлары һәм федераль дәүләт таләпләре, мәгариф стандартлары, төрле төрнең, баскычның һәм (яисә) юнәлешнең уку-укыту программалары;

2) белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган оешмалар, педагог хезмәткәрләр, белем алучылар һәм балигъ булмаган белем алучыларның ата-аналары (законлы вәкилләре);

3) федераль дәүләт органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең мәгариф өлкәсендә дәүләт идарәсен гамәлгә ашыра торган органы, мәгариф өлкәсендә идарәне гамәлгә ашыра торган җирле үзидарә органнары, алар тарафыннан төзелгән консультатив, киңәшмә һәм бүтән органнар;

4) белем бирү эшчәнлеген тәэмин итүне, белем сыйфатына бәя бирүне гамәлгә ашыра торган оешмалар;

5) мәгариф өлкәсендә эшчәнлек башкаручы юридик затларның, эш бирүчеләрнең берләшмәләре һәм аларның берләшмәләре, иҗтимагый берләшмәләр.

2. Мәгариф белемгә хокукны бөтен яшәү дәверендә гамәлгә ашыру мөмкинлеген (өзлексез белем алуны) тәэмин итә торган гомуми белемгә, һөнәри белемгә, өстәмә белемгә һәм һөнәргә өйрәнүгә бүленә.

3. Гомуми белем бирү һәм һөнәри белем бирү белем баскычлары буенча гамәлгә ашырыла.

4. Татарстан Республикасында түбәндәге баскычлар гамәлгә ашырыла:

1) гомуми белем бирүнең:

а) мәктәпкәчә белем;

б) башлангыч гомуми белем;

в) төп гомуми белем;

г) урта гомуми белем;

2) һөнәри белем бирүнең:

а) урта һөнәри белем;

б) югары белем – бакалавриат;

в) югары белем – белгечлекләр, магистратура;
г) югары белем – югары квалификацияле кадрлар әзерләү.

5. Өстәмә белем бирүнең балаларга һәм олыларга өстәмә белем бирү һәм өстәмә һөнәри белем бирү кебек төрләре бар.

6. Мәгариф системасы төп уку-укыту программаларын һәм төрле өстәмә уку-укыту программаларын гамәлгә ашыру, берничә уку-укыту программасын берьюлы үзләштерү мөмкинлеген бирү аркылы өзлексез белем бирү өчен, шулай ук белем алганда белеме, квалификациясе, практик эшчәнлеге тәҗрибәсе булуны исәпкә алу өчен шартлар тудыра.

7 статья. **Татарстан Республикасында мәгарифне үстерү программалары**

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, Татарстан Республикасының социаль-икътисадый, экологик, демографик, этномәдәни һәм башка үзенчәлекләрен исәпкә алып, Татарстан Республикасында мәгарифне үстерү программаларын эшли һәм раслый.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты ел саен Татарстан Республикасы Дәүләт Советына Татарстан Республикасында мәгарифне үстерү программаларын гамәлгә ашыру барышы турында доклад тапшыра һәм аны «Интернет» челтәрендәге рәсми сайтка урнаштыра.

8 статья. **Белем бирү теле**

1. Татарстан Республикасында гражданнар мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белемне мәгариф турында законнарда билгеләнгән тәртиптә Россия Федерациясе халыклары телләреннән булган туган телдә алырга хокуклы, шулай ук Россия Федерациясе халыклары телләреннән булган туган телне мәгариф системасы бирә торган мөмкинлекләрдән чыгып өйрәнергә хокуклы. Шушы хокукларны гамәлгә ашыру тиешле мәгариф оешмаларын, сыйныфларны, төркемнәрне таләп ителгән санда булдырып, шулай ук аларның эшләве өчен шартлар тудырып тәэмин ителә.

2. Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан дәүләт һәм муниципаль мәгариф оешмаларында татар теле «Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр турында» 1992 елның 8 июлендәге 1560-XII

номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә укытыла һәм өйрәнелә.

3. Татар һәм рус телләре, Татарстан Республикасы дәүләт телләре буларак, гомуми белем бирүнең тиешле баскычының федераль дәүләт мәгариф стандартлары кысаларында тигез күләмдә өйрәнелә. Татар телен укыту һәм өйрәнү белем алучыларның төрле дәрәҗәдәге әзерлеген исәпкә алып эшләнгән, дәүләт аккредитациясе булган уку-укыту программалары нигезендә гамәлгә ашырыла.

4. Һөнәри белем мәгариф оешмаларында татар һәм рус телләре кадрлар әзерләүнең тиешле юнәлешләренә караган федераль дәүләт мәгариф стандартлары кысаларында өйрәнелә.

5. Татарстан Республикасы урта һөнәри һәм югары белем мәгариф оешмаларында һөнәри белем бирү программалары татар телендә гамәлгә ашырыла ала.

6. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Россия Федерациясе законнары, Татарстан Республикасы Конституциясе, халыкара килешүләр һәм Россия Федерациясе субъектлары белән килешүләр нигезендә Татарстан Республикасыннан читтә яшәүче татарларга кирәкле белемне туган телдә алуга булышлык күрсәтә.

9 статья. **Белем алучыларның киеменә карата таләпләр**

1. Төп гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыра торган Татарстан Республикасы дәүләт мәгариф оешмаларында һәм Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең муниципаль мәгариф оешмаларында белем алучыларның киеменә карата төп таләпләр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана.

2. Мәгариф оешмалары, әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән таләпләргә нигезләнеп, тиешле мәгариф оешмасында белем алучыларның киеменә карата таләпләрне регламентлаштыра торган локаль норматив актлар чыгара ала.

3. Мәгариф оешмасы, белем алучыларның киеменә карата таләпләрне регламентлаштыра торган локаль норматив акт кабул иткәндә, белем алучыларның һәм аларның ата-аналарының (законлы вәкилләренең) фикерләрен исәпкә ала.

10 статья. **Укыту-методика берләшмәләре**

1. Федераль дәүләт мәгариф стандартларын, якынча уку-укыту программаларын эшләүдә педагогларны, фәнни хезмәткәрләрне, эш бирүчеләрнең вәкилләрен катнаштыру, белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган оешмаларның мәгариф системасында белем бирүнең сыйфатын һәм эчке үсешен тәэмин итү гамәлләрен координацияләү максатларында, укыту-методика берләшмәләре төзелергә мөмкин.

2. Мәгариф системасында укыту-методика берләшмәләре федераль башкарма хакимият органнары һәм Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мәгариф өлкәсендә дәүләт идарәсен гамәлгә ашыра торган органы тарафыннан төзелә һәм үз эшчәнлекләрен бу органнар раслаган нигезләмәләргә таянып гамәлгә ашыра.

3. Укыту-методика берләшмәләре составына, үзләре теләп, педагог хезмәткәрләр, фәнни хезмәткәрләр һәм белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган башка оешмаларның һәм мәгариф системасында эшли торган бүтән оешмаларның хезмәткәрләре, шул исәптән эш бирүчеләрнең вәкилләре керә.

11 статья. **Мәгариф өлкәсендә инновацион эшчәнлек**

1. Инновацион эшчәнлек мәгариф системасын фәнни-педагогик, укыту-методик, оештыру, хокукый, финанс-икътисадый, кадрлар белән, матди-техник яктан тәэмин итүне камилләштерүгә юнәлдерелгән һәм белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган оешмалар һәм мәгариф өлкәсендә эшли торган бүтән оешмалар, шулай ук аларның берләшмәләре тарафыннан инновацион проектларны һәм программаларны гамәлгә ашыру рәвешендә башкарыла. Инновацион проектны, программаны гамәлгә ашырганда, белем бирү мөнәсәбәтләрендә катнашучыларның хокуклары һәм законлы мәнфәгатьләрен саклау, федераль дәүләт мәгариф стандарты, федераль дәүләт таләпләре, мәгариф стандарты белән билгеләнгән таләпләрдән дәрәҗәсе һәм сыйфаты түбән була алмаган белем бирү һәм алу тәэмин ителгән булырга тиеш.

2. Мәгариф системасын үстерүне тәэмин итү өчен зур әһәмияткә ия инновацион проектларны һәм программаларны гамәлгә ашыру өчен шартлар тудыру максатларында, әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән һәм шул инновацион проектларны һәм программаларны гамәлгә ашыра торган оешмалар

федераль яисә региональ инновацион мәйданнар дип танылa һәм мәгариф системасында инновацион инфраструктураны тәшкил итә. Оешмаларны региональ инновацион мәйданнар дип тану тәртибен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгели.

3. Федераль дәүләт органнары һәм Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мәгариф өлкәсендә дәүләт идарәсен гамәлгә ашыра торган органы үз вәкаләтләре чикләрендә инновацион белем бирү проектларын, программаларын гамәлгә ашыру һәм аларның нәтиҗәләрен практикага кертү өчен шартлар тудыра.

12 статья. **Мәгариф өлкәсендә дәүләт-хосусый партнерлыгы**

Дәүләт-хосусый партнерлыгы турында Россия Федерациясе законнары нигезендә, Татарстан Республикасында, конкуренциягә сәләтле мәгариф системасын булдыру, халыкка күрсәтелә торган белем бирү хезмәтләренең һәркем алырлык булуын һәм сыйфатын арттыру максатларында, Татарстан Республикасы һәм хосусый партнерлар арасында ике як өчен дә файдалы хезмәттәшлек гамәлгә ашырылырга мөмкин.

13 статья. **Мәгариф оешмаларын төзү, үзгәртеп төзү, бетерү**

1. Мәгариф оешмасы граждан законнарында коммерциячел булмаган оешмалар өчен билгеләнгән рәвештә төзелә.

2. Мәгариф оешмасы, мәгариф турында законнарда каралган үзенчәлекне исәпкә алып, граждан законнарында билгеләнгән тәртиптә үзгәртеп төзелә яисә бетерелә.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының яисә Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекнең җирле үзидарә органының тиешенчә Татарстан Республикасы карамагында булган мәгариф оешмасын һәм (яисә) муниципаль мәгариф оешмасын үзгәртеп төзү яисә бетерү турында карар кабул итүе мондый карарның нәтиҗәләренә бәя бирү комиссиясенең уңай бәяләмәсе нигезендә рөхсәт ителә.

4. Авыл җирлегендә урнашкан муниципаль гомуми белем бирү оешмасын үзгәртеп төзү яисә бетерү турында карарны бу авыл җирлеге халкының фикерен исәпкә алмыйча кабул итү рөхсәт ителми.

5. Татарстан Республикасы карамагында булган мәгариф оешмасын, муниципаль мәгариф оешмасын үзгәртеп төзү яисә

бетерү турында карар кабул итүнең нәтиҗәләренә бәя бирүне уздыру тәртибен, бу бәя бирүнең критерийларын да кертеп (әлеге мәгариф оешмаларының типлары буенча), мондый карарның нәтиҗәләренә бәя бирү комиссиясен төзү һәм аның тарафыннан бәяләмәләр әзерләү тәртибен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгели.

6. Мәгариф оешмасының филиалы, әлеге Законда каралган үзенчәлекләрне исәпкә алып, граждан законнарында билгеләнгән тәртиптә төзелә һәм бетерелә. Дәүләт һәм (яисә) муниципаль мәктәпкәчә белем бирү оешмасын йә гомуми белем бирү оешмасын бетерү турында карар кабул итү әлеге статьяның 3 һәм 4 өлешләрендә билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

14 статья. **Төп гомуми белем бирү программалары буенча укырга кабул итүне оештыру**

1. Мәгариф оешмаларында мәктәпкәчә белем алу балаларга ике ай тулгач башланырга мөмкин. Мәгариф оешмаларында башлангыч гомуми белем алу, сәламәтлегенә зыян китерә торган шартлар булмаганда, балаларга алты яшь тә алты ай тулгач башлана, әмма аларга сигез яшь тулганнан да соңрак түгел. Мәгариф оешмасын гамәлгә куючы балаларның ата-аналары (законлы вәкилләре) гаризасы буенча мәгариф оешмасына балаларны башлангыч гомуми белемнең уку-укыту программалары буенча белем бирү өчен иртәрәк яисә соңрак яшьтә дә кабул итүгә рөхсәт бирергә хокуклы.

2. Төп гомуми белем бирү программалары буенча белем бирү өчен дәүләт һәм муниципаль мәгариф оешмаларына кабул итү кагыйдәләре тиешле баскычтагы гомуми белемне алырга хокуклы һәм шул мәгариф оешмасы беркетелгән территориядә яшәүче гражданнарны мәгариф оешмасына кабул итүне тәэмин итәргә тиеш.

3. Дәүләт һәм муниципаль мәгариф оешмалары, Федераль законда һәм Татарстан Республикасы законнарында каралган очраклардан тыш, төп гомуми белем бирү программалары буенча белем бирү өчен кабул иткәндә конкурс яисә индивидуаль сайлап алу оештырырга хокуксыз.

4. Төп гомуми һәм урта гомуми белемне аерым уку предметларын тирәнтен өйрәнеп алу өчен яисә профильле белем алу өчен Татарстан Республикасында дәүләт һәм муниципаль мәгариф оешмаларына кабул иткәндә йә күчергәндә индивидуаль сайлап алуны оештыру Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең

мәгариф өлкәсендә дәүләт идарәсен гамәлгә ашыра торган органы билгеләгән очракларда һәм тәртиптә рөхсәт ителә.

5. Татарстан Республикасында дәүләт яисә муниципаль мәгариф оешмасына кабул итүдән, Федераль законда каралган очраклардан тыш, бары тик анда буш урыннар булмау сәбәпле баш тартылырга мөмкин.

6. Дәүләт яисә муниципаль гомуми белем бирү оешмасында буш урыннар булмаган очракта, баланың ата-анасы (законлы вәкилләре) аны башка гомуми белем бирү оешмасына урнаштыру турындагы мәсьәләне хәл итү өчен турыдан-туры Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мәгариф өлкәсендә дәүләт идарәсен гамәлгә ашыра торган органына яисә мәгариф өлкәсендә идарәне гамәлгә ашыра торган җирле үзидарә органына мөрәҗәгать итә.

15 статья. **Сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикле белем алучыларның белем алуын оештыру**

1. Сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикле белем алучыларга белем бирү эчтәлеге һәм аларны укытуны һәм тәрбияләүне оештыру шартлары җайлаштырылган уку-укыту программасы, ә инвалидлар өчен шулай ук инвалидны индивидуаль тернәкләндерү программасы нигезендә билгеләнә.

2. Сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикле белем алучыларга гомуми белем бирү җайлаштырылган төп гомуми белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган оешмаларда башкарыла. Мондый оешмаларда күрсәтелгән белем алучыларның белем алуы өчен махсус шартлар тудырыла.

3. Әлеге Законда сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикле белем алучыларның белем алуы өчен махсус шартлар дигәндә, мондый белем алучыларны укыту, тәрбияләү һәм үстерү шартлары, моңа махсус уку-укыту программаларын, укыту һәм тәрбияләү ысулларын, махсус дәреслекләрне, укыту ярдәмлекләрен һәм дидактик материалларны, күмәк һәм индивидуаль кулланылыштагы махсус техник укыту чараларын куллану, белем алучыларга кирәкле техник ярдәм күрсәтүче ассистент (ярдәмче) хезмәтләрен күрсәтү, төркемләп һәм индивидуаль коррекция дәресләре үткәрү, белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган оешмалар бинасына кереп йөрүне тәэмин итү керә, һәм сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикле белем алучыларның алардан башка уку-укыту программаларын үзләштерүе мөмкин булмаган яисә кыенлаша торган башка шартлар күздә тотыла.

4. Сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикле белем алучыларны укыту башка белем алучылар белән бергә, шулай ук аерым сыйныфларда, төркемнәрдә яисә белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган аерым оешмаларда оештырылырга мөмкин.

5. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты ишетмәүче, начар ишетүче, соңрак ишетми башлаган, сукыр, начар күрүче, сөйләме нык бозылган, терәк-хәрәкәт аппараты бозылган, психик үсешендә тоткарлык булган, акылга зәгыйфь, аутистик спектр бозылышлары, катлаулы дефектлары булган һәм сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикле башка белем алучылар өчен җайлаштырылган төп гомуми белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган аерым оешмалар төзи.

6. Белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган оешмада яшәүче сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикле белем алучылар дәүләтнең тулы тәэминатында була һәм туклану, кием-салым, аяк киеме, йомшак һәм каты инвентарь белән тәэмин ителә. Сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикле башка белем алучылар ике тапкыр түләүсез туклану белән тәэмин ителә.

7. Сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикле белем алучыларны һөнәргә өйрәтү һәм аларга һөнәри белем бирү шул белем алучыларны укыту өчен, кирәк булган очракта, җайлаштырылган уку-укыту программаларына нигезләнеп алып барыла.

8. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты төп гомуми яисә урта гомуми белеме булмаган сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикле (акылга зәгыйфьлекнең төрле рәвешләрендә) белем алучыларның һөнәри белем алуын тәэмин итә.

9. Һөнәри белем бирү оешмалары һәм югары белем мәгариф оешмалары, шулай ук һөнәри белем бирүнең төп программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган оешмалар сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикле белем алучыларның белем алуы өчен махсус шартлар тудырырга тиеш.

10. Татарстан Республикасы бюджеты ассигнованиеләре исәбеннән белем алучы сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикле белем алучыларга түләүсез махсус дәреслекләр һәм укыту ярдәмлекләре, башка уку әдәбияты бирелә, шулай ук сурдотәрҗемәче һәм тифлосурдотәрҗемәче хезмәтләре күрсәтелә.

11. Дәүләт, үзе вәкаләтләр биргән Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары рәвешендә, сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикле белем алучыларны укытуның һәм тәрбияләүнең махсус педагогик юлларын һәм ысулларын белгән педагог хезмәткәрләр

әзерләүне тәэмин итә һәм белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган оешмага мондый хезмәткәрләрне җәлеп итәргә булыша.

12. Төп гомуми белем бирү программаларын үзләштерүче һәм озак дәвалануга мохтаҗ белем алучылар өчен мәгариф оешмалары, шул исәптән шифаханә тибындагылар төзелә, аларда мондый белем алучылар өчен кирәкле дәвалау, тернәкләндерү һәм савыктыру чаралары үткәрелә. Мондый балаларны, шулай ук сәламәтлеге буенча мәгариф оешмаларына килеп йөри алмаган инвалид балаларны укыту белем бирү оешмалары тарафыннан шулай ук өйдә яисә медицина оешмаларында оештырылырга мөмкин. Белем бирүне өйдә яисә медицина оешмасында оештыру өчен нигез медицина оешмасы бәяләмәсе һәм ата-ананың (законлы вәкилләрнең) язмача мөрәҗәгате була.

13. Дәүләт һәм муниципаль мәгариф оешмасы һәм озак дәвалануга мохтаҗ белем алучыларның, шулай ук инвалид балаларның ата-анасы (законлы вәкилләре) арасындагы мөнәсәбәтләрне төп гомуми белем бирү программалары буенча өйдә яисә медицина оешмаларында укытуны оештыру өлешендә регламентлаштыру һәм рәсмиләштерү тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының норматив хокукый акты белән билгеләнә.

16 статья. **Мәгариф системасының мәгълүмати ачыклыгы. Мәгариф системасында мониторинг**

1. Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнары, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары һәм белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган оешмалар мәгариф системасы турындагы мәгълүматның ачыклыгын һәм һәркем алырлык булуын тәэмин итә.

2. Мәгариф системасы турындагы мәгълүмат мәгариф системасына кагылышлы рәсми статистика исәбенә алу белешмәләрен, мәгариф системасына мониторинг белешмәләрен һәм федераль дәүләт органнары һәм Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мәгариф өлкәсендә дәүләт идарәсен гамәлгә ашыра торган органы, мәгариф өлкәсендә идарәне гамәлгә ашыра торган җирле үзидарә органнары, белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган оешмалар, шулай ук мәгариф өлкәсендә эшли торган башка оешмалар үз функцияләрен башкарганда ала торган бүтән белешмәләрне үз эченә ала.

3. Мәгариф системасына мониторинг белем бирү торышын һәм аның нәтиҗәләре үзгәрү динамикасын, белем бирү

эшчәнлеген гамәлгә ашыру шартларын, белем алучылар контингентын, белем алучыларның уку һәм укудан тыш казанышларын, белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган оешмаларны тәмамлаучыларның һөнәри казанышларын, белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган оешмалар челтәре торышын стандартлаштырылган системалы күзәтүдән гыйбарәт.

4. Мәгариф системасына мониторингны оештыру федераль дәүләт органнары һәм Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мәгариф өлкәсендә дәүләт идарәсен гамәлгә ашыра торган органы, мәгариф өлкәсендә идарәне гамәлгә ашыра торган җирле үзидарә органнары тарафыннан башкарыла.

5. Мәгариф системасына мониторинг үткәрү тәртибе, шулай ук мониторинг үткәрелергә тиешле мәҗбүри мәгълүмат исемлеге Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә.

6. Татарстан Республикасында мәгарифнең торышына һәм үсеш перспективаларына анализ йомгаклау хисабы (еллык хисап) рәвешендә ел саен «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мәгариф өлкәсендә дәүләт идарәсен гамәлгә ашыра торган органының рәсми сайтына урнаштырыла.

17 статья. **Мәгариф системасын мәгълүмати тәэмин итү**

1. Мәгариф системасында идарә итүне мәгълүмати тәэмин итү һәм белем бирү эшчәнлеген дәүләт регламентлавы максатларында Россия Федерациясе дәүләт хакимиятенең вәкаләтле органнары һәм Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мәгариф өлкәсендә дәүләт идарәсен гамәлгә ашыра торган органы тарафыннан дәүләт мәгълүмат системалары, шул исәптән әлеге статьяда каралган дәүләт мәгълүмат системалары төзелә, булдырыла һәм алып барыла. Дәүләт мәгълүмат системаларын алып бару әлеге мәгълүмат системаларының башка дәүләт мәгълүмат системалары һәм мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләре белән, моңа дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен файдаланыла торган мәгълүмат-технология һәм коммуникация инфраструктуралары да керә, яраклашуын һәм хезмәттәшлеген тәэмин итә торган бердәм оештыру, ысулый һәм программ-техник принциплар нигезендә, алардагы персональ белешмәләрнең конфиденциальлеген һәм иминлеген тәэмин итеп һәм дәүләт сере яисә законнар белән саклана торган башка сер турында Россия Федерациясе законнары таләпләрен үтәп гамәлгә ашырыла.

2. Төп гомуми һәм урта гомуми белемнең төп уку-укыту программаларын үзләштергән белем алучыларга дәүләт йомгак-

лау аттестациясе үткәрүне һәм урта һөнәри һәм югары белем алу өчен мәгариф оешмаларына кабул итүне мәгълүмати тәэмин итү максатларында түбәндәгеләр төзелә:

1) төп гомуми һәм урта гомуми белемнең төп уку-укыту программаларын үзләштергән белем алучыларга дәүләт йомгаклау аттестациясе үткәрүне һәм урта һөнәри һәм югары белем алу өчен гражданнарны белем бирү оешмаларына кабул итүне тәэмин итүнең федераль мәгълүмат системасы (алга таба – федераль мәгълүмат системасы);

2) төп гомуми һәм урта гомуми белемнең төп уку-укыту программаларын үзләштергән белем алучыларга дәүләт йомгаклау аттестациясен үткәрүне тәэмин итүнең региональ мәгълүмат системалары (алга таба – региональ мәгълүмат системалары).

3. Федераль мәгълүмат системасын һәм региональ мәгълүмат системасын төзүне һәм алып баруны оештыру тиешенчә федераль башкарма хакимиятнең мәгариф өлкәсендә тикшерү һәм күзәтчелек итү функцияләрен башкара торган органы һәм Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мәгариф өлкәсендә дәүләт идарәсен гамәлгә ашыра торган органы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

18 статья. **Мәгариф өлкәсендә дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне финанс белән тәэмин итү үзенчәлекләре**

1. Россия Федерациясендә мәгариф өлкәсендә дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне финанс белән тәэмин итү Россия Федерациясе законнары нигезендә һәм Федераль законда билгеләнгән үзенчәлекләрне исәпкә алып гамәлгә ашырыла.

2. Әлеге Законның 3 статьясындагы 2 өлешенең 3 пункты нигезендә Татарстан Республикасы законында билгеләнә торган нормативлар, мәгариф өлкәсендә дәүләт яисә муниципаль хезмәтләр күрсәтүгә норматив чыгымнар федераль дәүләт мәгариф стандартлары нигезендә һәрбер белем баскычы буенча, белем бирү рәвешләрен, федераль дәүләт таләпләрен (алар булса), мәгариф оешмасы тибын, уку-укыту программаларын гамәлгә ашыру челтәрен, белем бирү технологияләрен, сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикле белем алучыларның белем алуы өчен махсус шартларны, педагог хезмәткәрләрне өстәмә һөнәри белем белән тәэмин итүне, укытуның һәм тәрбияләүнең имин шартларын, белем алучыларның сәламәтлеген саклауны тәэмин итүне исәпкә алып, шулай ук белем бирү эшчәнлеген оештыруның һәм гамәлгә ашыруның федераль законда каралган үзенчәлекләрен исәпкә

алып (белем алучыларның төрле категорияләре өчен), уку-укыту программаларының һәрбер төре һәм юнәлеше (профиле) буенча билгеләнә, моңа, әгәр әлеге статьяда башкасы билгеләнмәгән булса, мәгариф стандартлары нигезендә бер белем алучыга исәпләнеп гамәлгә ашырыла торган белем бирү эшчәнлеге керми.

3. Мәгариф өлкәсендә дәүләт яисә муниципаль хезмәтләр күрсәтүгә норматив чыгымнарга, педагог хезмәткәрләрнең алар башкарган укыту (мөгаллимлек) эше һәм Россия Федерациясе Президенты, Россия Федерациясе Хөкүмәте, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, җирле үзидарә органнары карарлары нигезендә билгеләнә торган башка эш өчен уртача хезмәт хакы дәрәҗәсен тәэмин итүне исәпкә алып, педагог хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләү чыгымнары керә. Муниципаль гомуми белем бирү оешмаларының педагог хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләүнең әлеге Законның 3 статьясындагы 2 өлешенең 3 пункты нигезендә билгеләнә торган нормативларга кертелгән чыгымнары Татарстан Республикасында уртача хезмәт хакы дәрәҗәсеннән түбән була алмый.

4. Азкомплектлы мәгариф оешмалары һәм авыл торак пунктларында урнашкан, төп гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмалары өчен мәгариф өлкәсендә дәүләт яисә муниципаль хезмәтләр күрсәтүгә норматив чыгымнар шул исәптән белем алучыларның санына бәйле булмаган белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыруга чыгымнарны да күздә тотарга тиеш. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты азкомплектлы мәгариф оешмаларына төп гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыра торган мәгариф оешмаларын бу мәгариф оешмаларының башка мәгариф оешмаларыннан еракта урнашуына, транспортка якынлыгына һәм (яисә) белем алучыларның санына бәйле рәвештә кертә.

5. Төп гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыру буенча белем бирү эшчәнлеген башкара торган, Татарстан Республикасы бюджетының бюджет ассигнованиеләре исәбеннән финанс белән тәэмин ителә торган хосусый оешмаларның чыгымнарын каплауга субсидияләр әлеге Законның 3 статьясындагы 2 өлешенең 3 пункты нигезендә билгеләнә торган нормативларны исәпкә алып санала. Һөнәри белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган, Татарстан Республикасы бюджетының, җирле бюджетларның бюджет ассигнованиеләре исәбеннән финанс белән тәэмин ителә торган хосусый оешмаларның чыгымнарын каплауга субсидияләр

мәгариф өлкәсендә тиешле дәүләт яисә муниципаль хезмәтләр күрсәтүгә норматив чыгымнарны исәпкә алып санала.

19 статья. **Татарстан Республикасы бюджетының бюджет ассигнованиеләре исәбеннән укырга кабул итүнең контроль саннары**

1. Урта һөнәри һәм югары белемнең дәүләт аккредитациясе булган уку-укыту программалары буенча Татарстан Республикасы бюджетының бюджет ассигнованиеләре исәбеннән белем алучылар саны Татарстан Республикасы бюджетының бюджет ассигнованиеләре исәбеннән һөнәрләр, белгечлекләр һәм юнәлешләр буенча укырга кабул итүнең Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан булдырылган кадрларга ихтыяҗны фаразлау нигезендә контроль саннарына (алга таба – кабул итүнең контроль саннары) нигезләнеп билгеләнә.

2. Кабул итүнең контроль саннары гавами конкурс нәтиҗәләре буенча бүленә һәм урта һөнәри һәм югары белемнең дәүләт аккредитациясе булган уку-укыту программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган оешмаларга билгеләнә.

3. Урта һөнәри һәм югары белемнең дәүләт аккредитациясе булган уку-укыту программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетының бюджет ассигнованиеләре исәбеннән кабул итүнең контроль саннарын билгеләү тәртибен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты раслый.

4. Төп һөнәри белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган оешмалар, үзләренә билгеләнгән контроль саннар белән чикләнеп, әлеге Законның 20 статьясы нигезендә расланган тәртиптә максатчан кабул итүне гамәлгә ашырырга хокуклы.

20 статья. **Максатчан кабул итү. Максатчан кабул итү турында шартнамә һәм максатчан укыту турында шартнамә**

1. Югары белемнең уку-укыту программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган оешмалар гражданнарны федераль бюджетның, Татарстан Республикасы бюджетының һәм җирле бюджетларның бюджет ассигнованиеләре исәбеннән укуга кабул итүнең үзләренә Федераль закон һәм әлеге Законның 19 ста-

тьясы нигезендә билгеләнгән контроль саннары чикләрендә максатчан кабул итүне уздырырга хокуклы.

2. Гражданнарны федераль бюджетның, Татарстан Республикасы бюджетының һәм җирле бюджетларның бюджет ассигнованиеләре исәбеннән укырга кабул итүнең киләсе финанс елына билгеләнгән контроль саннары күләмендә югары белем алу өчен максатчан кабул итүнең югары белемнең һәр баскычы, һәр белгечлек һәм әзерлекнең һәр юнәлеше буенча квота ел саен югары белемнең уку-укыту программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган оешмаларны гамәлгә куючылар тарафыннан билгеләнә.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, дәүләт һәм муниципаль оешмаларның тиешле квалификация белгечләренә ихтыяҗын канәгатьләндерү максатларында, мәгариф оешмаларында дәүләт аккредитациясе булган урта һөнәри һәм югары белем бирү программалары буенча гамәлгә ашырыла торган әзерлекнең өстенлекле юнәлешләренең (белгечлекләренең) бишьеллык чорга төзелгән исемлеген билгели һәм «Интернет» челтәрендә рәсми сайтка урнаштыра.

4. Максатчан кабул итү белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган тиешле оешма тарафыннан максатчан укыту хакында граждан белән шартнамә төзегән федераль дәүләт органы, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органы, җирле үзидарә органы, дәүләт (муниципаль) учреждениесе, унитар предприятие, дәүләт корпорациясе, дәүләт компаниясе яисә устав капиталында Россия Федерациясе, Россия Федерациясе субъекты яисә муниципаль берәмлек өлеше булган хуҗалык җәмгыяте белән максатчан кабул итү хакында төзелә торган шартнамәгә нигезләнеп, билгеләнгән квоталар кысаларында башкарыла.

5. Әлеге статьяның 4 өлешендә күрсәтелгән орган яисә оешма белән максатчан уку турында шартнамә төзегән һәм Федераль законда билгеләнгән кабул итү тәртибе нигезендә максатчан кабул итү квотасы кысаларында үткәрелә торган конкурс буенча максатчан урыннарга кабул ителгән гражданнар югары белем алу өчен максатчан кабул итү шартларында белем алу хокукына ия.

6. Максатчан кабул итү турында шартнамәнең аеруча мөһим шартлары түбәндәгеләр:

1) белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган оешманың максатчан уку турында шартнамә төзегән гражданны максатчан кабул итүне оештыру йөкләмәләре;

2) әлеге статьяның 4 өлешендә күрсәтелгән органның яисә оешманың максатчан укыту турында шартнамә төзегән гражданның уку һәм хезмәт практикасын оештыру йөкләмәләре.

7. Максатчан укыту турында шартнамәнең мөһим шартлары түбәндәгеләр:

1) әлеге статьяның 4 өлешендә күрсәтелгән һәм максатчан укыту турында шартнамә төзегән орган яисә оешманың гражданга уку чорында күрсәтә торган социаль ярдәм чаралары (күрсәтелгән чараларга матди стимуллаштыру чаралары, түләүле белем бирү хезмәтләре өчен түләү, уку чорында файдалануга торак урын бирү һәм (яисә) аның өчен түләү һәм башка социаль ярдәм чаралары керергә мөмкин);

2) әлеге статьяның 4 өлешендә күрсәтелгән органның яисә оешманың һәм гражданның тиешенчә уку, хезмәт һәм диплом алды практикасын оештыру буенча, шулай ук аны максатчан укыту турында шартнамәдә күрсәтелгән оешмага алган квалификациясе буенча эшкә урнаштыру буенча йөкләмәләре;

3) гражданны эшкә урнашу йөкләмәләрен үтәүдән азат итү нигезләре.

8. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органы, Татарстан Республикасында җирле үзидарә органы, дәүләт (муниципаль) учреждениесе, унитар предприятие, дәүләт компаниясе яисә устав капиталында Татарстан Республикасы яки Татарстан Республикасында муниципаль берәмлек өлеше булган хуҗалык җәмгыяте белән максатчан уку турында шартнамә төзегән граждан Татарстан Республикасы законнары нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән квота кысаларында һәм тәртиптә социаль ипотекада катнашу хокукына ия.

9. Эшкә урнашу йөкләмәләрен үтәмәгән граждан, максатчан укыту турында шартнамәдә билгеләнгән очраклардан тыш, әлеге статьяның 4 өлешендә күрсәтелгән органга яисә оешмага аңа социаль ярдәм чаралары күрсәтүгә бәйле чыгымнарны тулы күләмдә кире кайтарырга, шулай ук шул чыгымнарның икеләтелгән күләмендә штраф түләргә тиеш. Әлеге статьяның 4 өлешендә күрсәтелгән орган яисә оешма, гражданны эшкә урнаштыру йөкләмәләрен үтәмәгән очракта, аңа социаль ярдәм чаралары күрсәтүгә бәйле чыгымнарның икеләтелгән күләмендә компенсация түли.

10. Максатчан кабул итү турында шартнамәне һәм максатчан укыту турында шартнамәне төзү һәм өзү тәртибе, шулай ук аларның үрнәк формалары Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә.

11. Федераль дәүләт органнары, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары һәм оешмалар урта һөнәри яисә югары белемнең уку-укыту программалары буенча максатчан булмаган кабул итү шартларында укырга кабул ителгән белем алучылар белән максатчан укыту турында шартнамәләр төзергә хокуклы.

12. Федераль дәүләт органы, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органы яисә җирле үзидарә органы һәм гражданан арасында соңыннан дәүләт хезмәте яисә муниципаль хезмәт узу йөкләмәләре булган максатчан укыту турында шартнамә төзү Россия Федерациясе законнарында, муниципаль хезмәт турындагы законнарда билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

13. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты чираттагы уку елы йомгаклары буенча Татарстан Республикасы бюджетының һәм Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле бюджетларының бюджет ассигнованиеләре исәбеннән максатчан уку турында шартнамә буенча һөнәри белем алган гражданнарның эшкә урнашуына мониторинг үткәрә һәм аны 1 сентябрьдән дә соңга калмыйча «Интернет» челтәрендә рәсми сайтка урнаштыра.

21 статья. **Белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган оешмаларда мәктәпкәчә белемнең уку-укыту программаларын үзләштерүче балаларны карап торган һәм караган өчен ата-анадан (законлы вәкилләрдән) алына торган түләү**

1. Мәктәпкәчә мәгариф оешмалары балаларны карап торуны һәм карауны гамәлгә ашыра. Мәктәпкәчә белемнең уку-укыту программаларын гамәлгә ашыру буенча белем бирү эшчәнлеген башкара торган башка оешмалар балаларны карап торуны һәм карауны гамәлгә ашырырга хокуклы.

2. Белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган оешманы гамәлгә куючы баланы карап торган һәм караган өчен ата-анадан (законлы вәкилләрдән) алына торган түләү (алга таба – ата-ана түләве) һәм, әлеге законда башкасы билгеләнмәгән булса, аның күләмен билгеләргә хокуклы. Гамәлгә куючы үзе билгеләгән очракларда һәм тәртиптә ата-ана түләвенең күләмен киметергә яисә ата-аналарның (законлы вәкилләрнең) аерым категорияләреннән аны түләттермәскә хокуклы.

3. Мәктәпкәчә белемнең уку-укыту программасын гамәлгә ашыра торган дәүләт һәм муниципаль мәгариф оешмаларында белем алучы инвалид балаларны, ятим балаларны һәм ата-ана

тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны, шулай ук туберкулез интоксикациясе булган балаларны карап торган һәм караган өчен ата-ана түләве алынмый.

4. Мәктәпкәчә белемнең уку-укыту программасын гамәлгә ашыру чыгымнарын, шулай ук мәктәпкәчә белемнең уку-укыту программасын гамәлгә ашыра торган дәүләт һәм муниципаль мәгариф оешмаларының күчемсез мөлкәтен карап тоту чыгымнарын мондый оешмаларда баланы карап торган һәм караган өчен ата-ана түләвенә кертү рөхсәт ителми.

5. Мәктәпкәчә белемнең уку-укыту программаларын гамәлгә ашыра торган мәгариф оешмаларына йөрүче балаларны тәрбияләүгә һәм укытуга матди ярдәм итү максатларында ата-анага (законлы вәкилләргә) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән күләмдә компенсация түләнә. Беренче балага компенсация күләме Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан дәүләт һәм муниципаль мәгариф оешмаларында балаларны карап торган һәм караган өчен ата-ана түләвенең уртача күләменең егерме процентыннан ким була алмый, икенче балага – мондый түләү күләменең илле процентыннан ким, өченче һәм аннан соңгы балаларга – мондый түләү күләменең җитмеш процентыннан ким була алмый һәм, гаиләнең җан башына уртача кеременә карап, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан арттырылырга мөмкин. Дәүләт һәм муниципаль мәгариф оешмаларында балаларны карап торган һәм караган өчен ата-ана түләвенең уртача күләме Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә. Компенсация алу хокукына тиешле мәгариф оешмасында балаларны карап торган һәм караган өчен ата-ана түләвен керткән ата-ананың (законлы вәкилләрнең) берсе ия.

6. Әлеге статьяның 5 өлешендә күрсәтелгән компенсация алу өчен мөрәҗәгать итү тәртибе һәм аны түләү тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә.

7. Әлеге статьяның 5 өлешендә күрсәтелгән компенсацияне түләүгә бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү Татарстан Республикасының чыгым йөкләмәсе булып санала.

## 3 бүлек. **Белем алучылар һәм педагог хезмәткәрләр**

### 22 статья. **Белем алучыларга социаль ярдәм һәм стимуллаштыру чаралары**

1. Белем алучыларга социаль ярдәм һәм стимуллаштыруның түбәндәге чаралары күрсәтелә:

1) федераль законнарда, Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән очракларда һәм тәртиптә дәүләт тарафыннан тулысынча тәэмин итү, шул исәптән кием-салым, аяк киемнәре, каты һәм йомшак инвентарь белән тәэмин итү;

2) федераль законнарда, Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән очракларда һәм тәртиптә туклану белән тәэмин итү;

3) интернатларда урыннар белән тәэмин итү, шулай ук Федераль закон һәм торак законнары нигезендә тулай торакларда торак урыннар бирү;

4) әлеге Законның 14 статьясы нигезендә транспорт белән тәэмин итү;

5) стипендияләр, матди ярдәмнәр һәм мәгариф турында законнарда каралган башка акчалата түләүләр алу;

6) Федераль закон һәм Россия Федерациясе законнары нигезендә билгеләнгән тәртиптә белем алуга кредитлар бирү;

7) Россия Федерациясе норматив хокукый актларында һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында, җирле үзидарә органнарының хокукый актларында, локаль норматив актларда каралган бүтән социаль ярдәм чаралары.

2. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары аеруча сәләтле булуларын күрсәткән затларга махсус акчалата кызыксындырулар һәм күрсәтелгән затларны стимуллаштыруның башка чараларын билгеләргә хокуклы.

### 23 статья. **Стипендияләр һәм акчалата башка түләүләр**

1. Белем алучыларга аларның тиешле уку-укыту программаларын үзләштерүләрен стимуллаштыру һәм (яисә) ярдәм итү максатларында билгеләнә торган акчалата түләү стипендия була.

2. Стипендия төрләре Федераль законда билгеләнә.

3. Татарстан Республикасы бюджетының бюджет ассигнованиеләре исәбеннән көндезге бүлектә белем алучы студентларга дәүләт академик стипендиясен, студентларга дәүләт социаль стипендиясен, аспирантларга, ординаторларга, ассистент-стажерларга дәүләт стипендияләрен билгеләү тәртибен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгели.

4. Студентларга дәүләт академик стипендиясе, студентларга дәүләт социаль стипендиясе, аспирантларга, ординатор-

ларга, ассистент-стажерларга дәүләт стипендияләре, белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган оешмага белем алучыларны стипендия белән тәэмин итүгә бүлеп бирелә торган акчалар (стипендия фонды) чикләрендә, белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган оешма тарафыннан бу оешмада белем алучылар советы һәм беренчел һөнәр берлеге оешмасының сайланулы органы (мондый орган булган очракта) фикерләрен исәпкә алып билгеләнә торган күләмнәрдә түләнә.

5. Студентларга дәүләт академик стипендиясенең, студентларга дәүләт социаль стипендиясенең, аспирантларга, ординаторларга, ассистент-стажерларга дәүләт стипендияләренең белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган оешма тарафыннан билгеләнә торган күләмнәре әлеге статьяның 6 өлеше нигезендә билгеләнгән нормативлардан ким була алмый.

6. Стипендия фонды күләме, инфляцияне исәпкә алып, федераль бюджетның бюджет ассигнованиеләре исәбеннән көндезге уку бүлегендә белем алучыларның гомуми санынннан һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан һөнәри белемнең һәр баскычы һәм белем алучыларның категорияләре буенча билгеләнгән нормативлардан чыгып билгеләнә. Стипендия фондын Татарстан Республикасы бюджетының бюджет ассигнованиеләре исәбеннән булдыру өчен нормативларны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгели.

7. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары исемле стипендияләр бирә, аларны түләү күләмнәрен һәм шартларын билгели ала.

### 24 статья. **Транспорт белән тәэмин итү**

1. Белем алучыларны транспорт белән тәэмин итү аларны белем бирү оешмасына кадәр түләүсез алып бару һәм кирегә алып кайтуны әлеге статьяның 2 өлешендә билгеләнгән очракларда оештыруны, шулай ук җәмәгать транспортында барганда социаль ярдәм чараларын Россия Федерациясе законнары нигезендә күрсәтүне үз эченә ала.

2. Төп гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыра торган дәүләт һәм муниципаль мәгариф оешмаларында белем алучыларны балалар йөртү өчен каралган транспортта җирлекләр арасында түләүсез йөртүне оештыру тиешле мәгариф оешмасын гамәлгә куючы тарафыннан башкарыла.

25 статья. **Педагог хезмәткәрләрнең хокукый статусы. Педагог хезмәткәрләргә социаль ярдәм чаралары**

1. Педагог хезмәткәрләрнең хокукый статусы дигәндә Россия Федерациясе законнарында һәм Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән хокуклар һәм ирекләр (шул исәптән академик хокуклар һәм ирекләр), хезмәт хокуклары, социаль гарантияләр һәм компенсацияләр, чикләүләр, бурычлар һәм җаваплылык җыелмасы аңлашыла.

2. Педагог хезмәткәрләрнең хокукый статусы, хокуклары, ирекләре, аларны тормышка ашыру гарантияләре, социаль гарантияләр Федераль законда билгеләнгән.

3. Авыл торак пунктларында, эшчеләр поселокларында (шәһәр тибындагы поселокларда) яшәүче һәм эшләүче педагог хезмәткәрләр торак урын, җылылык һәм ут яндыру өчен түләү чыгымнарына компенсация бирелүгә хокуклы. Татарстан Республикасы мәгариф оешмаларының, муниципаль мәгариф оешмаларының педагог хезмәткәрләренә шул социаль ярдәм чараларын күрсәтүгә бәйле чыгымнарны түләү күләме, шартлары һәм тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә һәм Татарстан Республикасы бюджетының бюджет ассигнованиеләре исәбеннән тәэмин ителә.

4. Белем бирү оешмаларының бердәм дәүләт имтиханын уздыруда башкарма хакимиятнең вәкаләтле органнары карары буенча эш вакытында катнашучы һәм бердәм дәүләт имтиханын уздыру чорына төп эшеннән азат ителгән педагог хезмәткәрләргә хезмәт законнары һәм хезмәт хокукы нормаларын үз эченә алган башка актлар белән гарантияләр һәм компенсацияләр бирелә. Бердәм дәүләт имтиханын уздыруда катнашучы педагог хезмәткәрләргә бердәм дәүләт имтиханын әзерләү һәм уздыру эше өчен компенсация түләнә. Компенсация түләү күләме һәм тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан Татарстан Республикасы бюджетыннан бердәм дәүләт имтиханын уздыруга бүлеп бирелә торган акчалар кысаларында билгеләнә.

5. Һөнәри белем бирү оешмаларын һәм югары белем мәгариф оешмаларын тәмамлаучыларны педагогик эшчәнлеккә җәлеп итү өчен Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары өстәмә дәүләт ярдәме чараларын билгеләргә хокуклы.

6. Татарстан Республикасында педагог хезмәткәрләргә өстәмә социаль ярдәм чараларын Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгели.

Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнары муниципаль мәгариф оешмаларының педагог хезмәткәрләргә тиешле бюджетлар акчалары исәбеннән өстәмә социаль ярдәм чаралары билгели ала.

4 бүлек. **Йомгаклау нигезләмәләре**

26 статья. **Йомгаклау нигезләмәләре**

1. 2014 елның 1 гыйнварына кадәр:

1) Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары мәгариф өлкәсендә түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

а) «2013 елга Татарстан Республикасы гомуми белем бирү учреждениеләрендә һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта (тулы) гомуми белем, шулай ук өстәмә белем алуга гражданнарның хокук-ларына дәүләт гарантияләрен финанс белән тәэмин итү нормативларын раслау турында» 2012 елның 19 октябрендәге 69-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законында билгеләнгән нормативлар нигезендә гомуми белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү чыгымнарын, дәреслекләргә һәм уку-укыту, укыту-күрсәтмә ярдәмлекләренә, укытуның техник чараларына, куллану материалларына һәм хуҗалык ихтыяҗларына чыгымнарны (җирле бюджетлар акчалары исәбеннән гамәлгә ашырыла торган биналарны тәртиптә тоту һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләү чыгымнарыннан тыш) финанслау өлешендә төп гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыру өчен кирәкле күләмдә җирле бюджетларга субвенцияләр бүлеп бирү юлы белән гомуми белем бирү оешмаларында гражданнарның һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем, шулай ук өстәмә белем алуга хокукларына дәүләт гарантияләрен тәэмин итүне;

б) Татарстан Республикасы дәүләт мәгариф оешмалары һәм муниципаль мәгариф оешмаларының белем бирү эшчәнлеген финанс белән тәэмин итү нормативлары нигезендә педагог хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләү чыгымнарын, дәреслекләр һәм уку-укыту, укыту-күрсәтмә ярдәмлекләре, укытуның техник чаралары, уеннар, уенчыклар, куллану материаллары чыгымнарын финанслау өлешендә төп гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыру өчен кирәк булган күләмдә хосусый гомуми белем бирү оешмаларының дәүләт аккредитациясе булган тиешле

төп гомуми белем бирү программалары буенча гражданнарның мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем алуын финанс белән тәэмин итүне;

2) Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнары мәгариф өлкәсендә җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү кысаларында түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

а) төп гомуми белем программалары буенча һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирүне оештыруны, моңа әлеге статьяның 1 пунктында күрсәтелгән һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары вәкаләтләренә кертелгән белем бирү процессын финанс белән тәэмин итү вәкаләтләре керми;

б) мәктәпкәчә хосусый белем бирү оешмаларында балаларның мәктәпкәчә белем алуын мәктәпкәчә белемнең төп гомуми белем бирү программасын педагог хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләү чыгымнарын, укыту-күрсәтмә ярдәмлекләре, укытуның техник чаралары, уеннар, уенчыклар, куллану материаллары өчен чыгымнарны муниципаль мәгариф оешмалары өчен билгеләнгән нормативлар нигезендә финанслау өлешендә гамәлгә ашыру өчен кирәкле күләмдә финанслауны.

2. 2014 елның 1 гыйнварына кадәр ата-ана түләвенең бер өлешен компенсацияләү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә торган күләмдә һәм тәртиптә түләнә, һәм Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан дәүләт һәм муниципаль мәгариф оешмаларында балаларны карап торган һәм караган өчен беренче балага уртача ата-ана түләвенең кимендә егерме проценты күләменнән, икенче балага – мондый түләүнең кимендә илле проценты, өченче һәм аннан соңгы балаларга – мондый түләүнең кимендә җитмеш проценты күләменнән ким була алмый.

27 статья. **Татарстан Республикасы аерым закон актларының (закон актлары нигезләмәләренең) үз көчләрен югалтуын тану**

Түбәндәгеләрне үз көчләрен югалткан дип танырга:

1) «Мәгариф турында» 1993 елның 19 октябрендәге 1982-XII номерлы Татарстан Республикасы Законы;

2) «Мәгариф турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында» 1997 елның 2 июлендәге 1247 номерлы Татарстан Республикасы Законы;

3) «Мәгариф турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2002 елның 17 гыйнварындагы 1286 номерлы Татарстан Республикасы Законы;

4) «Мәгариф турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында» 2004 елның 29 маендагы 36-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы;

5) «Мәгариф турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында» 2006 елның 19 июнендәге 41-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы;

6) «Мәгариф турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2009 елның 3 июлендәге 26-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы;

7) «Мәгариф турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2010 елның 11 гыйнварындагы 1-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы;

8) «Мәгариф турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2010 елның 14 октябрендәге 67-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы;

9) «Мәгариф турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2011 елның 30 июнендәге 40-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы;

10) «Мәгариф турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2011 елның 18 ноябрендәге 92-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы;

11) «Мәгариф турында» Татарстан Республикасы Законына һәм «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2012 елның 11 июнендәге 36-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясы;

12) «Мәгариф турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2012 елның 9 июлендәге 43-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы.

28 статья. **Әлеге Законның үз көченә керү тәртибе**

1. Әлеге Закон, 2014 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә торган әлеге Законның 3 статьясындагы 2 өлешенең 3 һәм 6 пунктларыннан, 21 статьясындагы 5 өлешеннән тыш, 2013 елның 1 сентябреннән үз көченә керә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына үз норматив хокукый актларын әлеге Законга туры китерергә, шулай

ук әлеге Законда каралган Татарстан Республикасы норматив хокукый актларын кабул итүне тәэмин итәргә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 елның 22 июле
№ 68-ТРЗ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

## 978. Аерым муниципаль берәмлекләрне үзгәртеп кору һәм «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2013 елның 28 июнендә
кабул ителде

**1 статья**

Зеленодольск муниципаль районы составындагы «Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогы», «Олы Ходяш авыл җирлеге» һәм «Мизиново авыл җирлеге» муниципаль берәмлекләрен әлеге җирлекләрдәге халыкның аларның вәкиллекле органнары аша белдерелгән ризалыгы белән күрсәтелгән җирлекләрне административ үзәге Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогы булган «Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегенә (алга таба – яңа төзелгән муниципаль берәмлек) берләштерү юлы белән үзгәртеп корырга.

**2 статья**

1. Яңа төзелгән муниципаль берәмлекнең беренче чакырылыш вәкиллекле органы депутатларының һәм беренче башлыгының вәкаләтләре чорын ике ел дип билгеләргә.

2. Яңа төзелгән муниципаль берәмлекнең беренче чакырылыш вәкиллекле органы депутатлары санын ун кеше тәшкил итә дип билгеләргә.

3. Яңа төзелгән муниципаль берәмлекнең җирле үзидарә органнарына сайлауларны билгеләү, сайлауларны әзерләү һәм үткәрү законнарда билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда гамәлгә ашырыла.

**3 статья**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 34 статьясындагы 5 өлешендә каралган тәртиптә җирле референдумда кабул ителә торган яңа төзелгән муниципаль берәмлекнең җирле үзидарә органнары структурасы турындагы карарда башкасы билгеләнмәгән булса, түбәндәгеләрне билгеләргә:

1) яңа төзелгән муниципаль берәмлекнең беренче башлыгы әлеге муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы тарафыннан яшерен тавыш бирү юлы белән үз составыннан сайлап куела.

Яңа төзелгән муниципаль берәмлекнең беренче чакырылыш вәкиллекле органы депутаты, вәкиллекле орган депутатларының билгеләнгән саныннан яртысыннан артыграгы аны хуплап тавыш бирсә, бу муниципаль берәмлекнең сайлап куелган башлыгы дип санала.

Яңа төзелгән муниципаль берәмлек башлыгын сайлап куйганчы, бу муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы утырышын вәкиллекле органның яше буенча иң өлкән депутаты ача һәм алып бара;

2) яңа төзелгән муниципаль берәмлекнең сайлап куелган башлыгы бу муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы рәисе вәкаләтләрен башкара.

**4 статья**

«Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» 2005 елның 31 гыйнварындагы 24-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 1 (II өлеш); 2008, № 12 (VII өлеш); 2010, № 12 (I өлеш); 2012, № 1) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 статьяда өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:


«Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге составына керүче һәм Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогыннан һәм, Олы Ходяш, Бритвин, Мизиново, Исак, Кече Йорт, Протопоповка, Рус Шырданы, Улитино авыллары, Ходяш тимер юлы разъезды поселогы, Луговой, Кече Ходяш поселоклары территорияләрен кертеп, аның янәшәсендәге территорияләрдән торучы «Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге территориясе чикләрен карта-схема (әлеге Законга 1 нче кушымта) һәм чикнең картографик тасвирламасы (әлеге Законга 5 нче кушымта) нигезендә билгеләргә, аңа шәһәр җирлеге статусын бирергә.»;

2) 4 статьяда сигезенче һәм ундүртенче абзацларны үз көчләрен югалткан дип танырга;

# 3) 1 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына
1 нче кушымта

«Зеленодольск муниципаль районы»
муниципаль берәмлеге составына керүче
муниципаль берәмлекләрнең чикләре
<u>карта-схемасы</u>




Шартлы билгеләр

- республика чиге
- муниципаль район чиге
- тоташу ноктасының тәртип саны
- җирлекләрнең чикләре һәм аларның сан белән билгеләнеше
- торак пунктлар
- муниципаль районның административ үзәге
- җирлекнең административ үзәге

Муниципаль районның
чиктәш чикләре тасвирламасы

| | |
|---|---|
| 41(9) - 4(10) | - Чуваш Республикасы, Марий Эл Республикасы |
| 4(10) - 9(43) | - Биектау муниципаль районы |
| 9(43) - 11(40) | - Казан шәһәре муниципаль берәмлеге |
| 11(40) - 34(39) | - Югары Ослан муниципаль районы |
| 34(39) - 41(9) | - Кайбыч муниципальрайоны |

«Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге составына керүче шәһәр һәм авыл җирлекләре

| Карта-схемадагы № | Муниципаль берәмлек |
|---|---|
| 1 | Зеленодольск шәһәре |
| 2 | Васильево шәһәр тибындагы поселогы |
| 3 | Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогы |
| 4 | Әйшә авыл җирлеге |
| 5 | Акъегет авыл җирлеге |
| 6 | Бишнә авыл җирлеге |
| 7 | Олы Ачасыр авыл җирлеге |
| 8 | Большие Ключи авыл җирлеге |
| 9 | Олы Карагуҗа авыл җирлеге |
| 10 | Олы Шырдан авыл җирлеге |
| 11 | Олы Җәке авыл җирлеге |
| 12 | Күгәй авыл җирлеге |
| 13 | Күгеш авыл җирлеге |
| 14 | Мамадыш-Әкил авыл җирлеге |
| 15 | Мулла Иле авыл җирлеге |
| 16 | Түбән Урысбага авыл җирлеге |
| 17 | Новопольский авыл җирлеге |
| 18 | Норлат авыл җирлеге |
| 19 | Октябрь авыл җирлеге |
| 20 | Осиново авыл җирлеге |
| 21 | Раифа авыл җирлеге |
| 22 | Рус Әҗиле авыл җирлеге |
| 23 | Свияжск (Зөя) авыл җирлеге |
| 24 | Өтәшкә авыл җирлеге |

»;

4) 3 нче кушымтада:

а) дүртенче абзацта «Куйбышев сусаклагычы акваториясендә урнашкан X=479922,3, Y=1264090,55» сүзләрен «Улитино авылыннан 1,6 км төньяк-көнчыгышта Куйбышев сусаклагычы акваториясендә урнашкан X=479922,31, Y=1264090,55» сүзләренә алмаштырырга;

б) бишенче абзацта «Куйбышев сусаклагычы акваториясендә урнашкан X=479365,96, Y=1271527,3» сүзләрен «Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогыннан 3,2 км төньяк-көнчыгышта Куйбышев сусаклагычы акваториясендә урнашкан X=479365,96, Y=1271527,30» сүзләренә алмаштырырга;

в) алтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге чиге «Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге белән чиктәш җирдә 23 нче тоташу ноктасыннан алып Куйбышев сусаклагычы акваториясе буйлап 7,4 км көнбатышка таба, 350 м төньякка таба 53 нче тоташу ноктасына кадәр уза.»;

5) 5 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Зеленодольск муниципаль районы»
муниципаль берәмлегенең һәм аның
составындагы муниципаль
берәмлекләрнең территорияләре чикләрен
билгеләү һәм аларның статусы турында»
Татарстан Республикасы Законына
5 нче кушымта

**Зеленодольск муниципаль районының «Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы**

Әлеге картографик тасвирлама «Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

«Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге, Олы Ачасыр, Олы Шырдан, Свияжск (Зөя) авыл җирлекләре, Югары Ослан муниципаль районы, Марий Эл Республикасы һәм Чуваш Республикасы белән чиктәш.

**Зеленодольск муниципаль районының «Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге территориясе чиге**

«Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге чиге Чуваш Республикасы белән чиктәш җирдә «Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге, Олы Шырдан авыл җирлеге һәм Чуваш Республикасы чикләре тоташкан урында Рус Шырданы авылыннан 2,3 км көнбатышта урнашкан 52 нче тоташу ноктасыннан алып Татарстан Республикасы административ чиге буйлап «Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге, Чуваш Республикасы һәм Марий Эл Республикасы чикләре тоташкан җирдә Улитино авылыннан 3,3 км төньяк-көнбатышта Куйбышев сусаклагычы акваториясендә урнашкан X=480029,73, Y=1260116,97 координаталы 37 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

«Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге чиге Марий Эл Республикасы белән чиктәш җирдә 37 нче тоташу ноктасыннан алып Татарстан Республикасы административ чиге буйлап «Зеленодольск шәһәре», «Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлекләре һәм Марий Эл Республикасы чикләре тоташкан урында Улитино авылыннан 1,6 км төньяк-көнчыгышта Куйбышев сусаклагычы акваториясендә урнашкан X=479922,31, Y=1264090,55 координаталы 53 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

«Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге чиге «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге белән чиктәш җирдә «Зеленодольск шәһәре», «Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлекләре, Әйшә һәм Свияжск (Зөя) авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогыннан 3,2 км төньяк-көнчыгышта Куйбышев сусаклагычы акваториясендә урнашкан X=479365,96, Y=1271527,30 координаталы 23 нче тоташу ноктасыннан алып Куйбышев сусаклагычы акваториясе буйлап 7,4 км көнбатышка таба, 350 м төньякка таба 53 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

«Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге чиге Свияжск (Зөя) авыл җирлеге белән чиктәш җирдә «Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге, Свияжск (Зөя) авыл җирлеге һәм Югары Ослан муниципаль районы чикләре тоташкан урында Свияжск (Зөя) авылыннан 1,1 км көньяк-көнчыгышта Куйбышев сусаклагычы

акваториясендә урнашкан X=472689,99, Y=1277303,41 координаталы 21 нче тоташу ноктасыннан алып Куйбышев сусаклагычы акваториясе буйлап 7,3 км, сынык сызык ясап, төньяк-көнбатышка таба, утрауларны кисеп үтеп, 5,6 км, сынык сызык ясап, Куйбышев сусаклагычының уң як яры буенча уза, алга таба Куйбышев сусаклагычы акваториясе буйлап 3,2 км төньяк-көнчыгышка таба, утрауларны кисеп үтеп, 23 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

«Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге чиге Югары Ослан муниципаль районы белән чиктәш җирдә 21 нче тоташу ноктасыннан алып Зеленодольск муниципаль районы чиге буйлап «Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге, Олы Ачасыр авыл җирлеге һәм Югары Ослан муниципаль районы чикләре тоташкан урында Бритвин авылыннан 1,4 км көньякта Куйбышев сусаклагычы акваториясендә урнашкан X=461867,44, Y=1266525,73 координаталы 25 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

«Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге чиге Олы Ачасыр авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 25 нче тоташу ноктасыннан алып 400 м төньяк-көнбатышка таба Куйбышев сусаклагычы акваториясе буйлап утрауны кисеп уза, аннары исемсез утрауның төньяк яры буенча 5,1 км төньяк-көнчыгышка таба һәм 650 м көньяк-көнбатышка таба бара, Куйбышев сусаклагычы акваториясе буйлап 150 м аның уң як ярына кадәр уза, шушы яр буенча 200 м кибеп баручы инешнең тамагына кадәр бара, 850 м шушы инеш агымы буенча өскә таба сазлыкка кадәр уза, сазлык буйлап 1,3 км төньяк-көнчыгышка таба, 1,1 км сазлыкның төньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, алга таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 950 м төньяк-көнбатышка таба, урман полосасын кисеп үтеп, 150 м Горький тимер юлына бүлеп бирелгән полоса буйлап, аны һәм Карамалы Тау – Албаба тимер юл разъезды поселогы автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 350 м күмәк бакчалар буйлап һәм, чокырны кисеп, 50 м көньяк-көнбатышка таба уза, 200 м күмәк бакчаларның төньяк-көнчыгыш чиге буйлап һәм 100 м төньяк-көнбатышка таба бара, 300 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, 400 м күмәк бакчаларның төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, аннары чокырның көнчыгыш чиге буенча 300 м төньякка таба уза, аннары 50 м төньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 300 м урман полосасының көньяк чиге буйлап, 50 м, текә ярны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, аннары 700 м төньяк-көнбатышка таба чокыр төбе буйлап, 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап ур-

ман полосасына кадәр уза, аннары төньякка таба 800 м урман полосасының көнчыгыш чиге буйлап, 550 м, чокырны һәм Мәскәү – Уфа федераль автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, аннары 2,1 км төньяк-көнбатышка таба урман полосасының көньяк чиге буйлап, 800 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап текә ярга кадәр уза, 300 м төньякка таба текә ярның көнчыгыш чиге буйлап бара, аннары 40 м төньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап «Кайбыч урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Күгәй участок урманчылыгындагы 19 нчы урман кварталына кадәр уза, аннары шушы урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 100 м көнчыгышка таба һәм төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 800 м төньяк-көнбатышка таба бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 400 м төньяк-көнбатышка таба, 350 м төньяк-көнчыгышка таба урман полосасына кадәр уза, 100 м урман полосасы буйлап, 250 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап «Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге, Олы Ачасыр һәм Олы Шырдан авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Кече Шырдан авылыннан 1,4 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 26 нчы тоташу ноктасына кадәр бара.

«Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге чиге Олы Шырдан авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 26 нчы тоташу ноктасыннан алып агачлык-куаклык массивының төньяк чиге буйлап 30 м көнчыгышка таба, 50 м урман массивы буйлап, 200 м урман полосасының көньяк чиге буйлап, 400 м урман полосасы буйлап, 250 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м урман полосасы буйлап, 200 м урман полосасының көньяк чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары 100 м төньяк-көнчыгышка таба «Кайбыч урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Күгәй участок урманчылыгындагы 21 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, 40 м чокыр буйлап һәм 50 м көньяк-көнчыгышка таба уза, аннары, чокырны кисеп үтеп, 350 м көньяк-көнчыгышка таба һәм 900 м төньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап урман полосасына кадәр бара, 250 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 150 м урман полосасы буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 450 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 500 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, алга таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м төньяк-көнчыгышка таба һәм 250 м көньяк-көнчыгышка таба бара, 600 м урман полосасының көньяк-көнбатыш

чиге буйлап, 300 м, чокырны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 100 м һәм көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 1,3 км төньяк-көнчыгышка таба бара, 30 м «Карамалы Тау – Албаба тимер юл разъезды поселогы» – Олы Шырдан автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп уза, аннары 850 м төньяк-көнбатышка таба шушы автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның төньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 550 м төньяк-көнчыгышка таба, 1,6 км, сынык сызык ясап, күмәк бакчаларның көньяк-көнчыгыш чиге буйлап инешкә кадәр уза, аның агымы буйлап аска таба 950 м бара, аннары 1,8 км төньяк-көнчыгышка таба Горький тимер юлына бүлеп бирелгән полосаның көнбатыш чиге буйлап Сәкел елгасын, ике тапкыр инешне һәм аның текә ярын, күлләрне һәм профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп уза, аннары 350 м көнбатышка таба профильле автомобиль юлы буйлап, 2,1 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап күмәк бакчаларга кадәр бара, аннары күмәк бакчаларның көньяк-көнчыгыш чиге буйлап көньяк-көнбатышка таба, 500 м, сынык сызык ясап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап инешкә кадәр уза, 4,3 км шушы инеш агымы буйлап өскә таба, дамбаны һәм Горький тимер юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 52 нче тоташу ноктасына кадәр бара.»;

6) 9 нчы кушымтада:

а) икенче абзацта «Олы Ходяш, Олы Шырдан» сүзләрен «Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге, Олы Шырдан» сүзләренә алмаштырырга;

б) бишенче абзацта «Олы Ачасыр, Олы Ходяш» сүзләрен «Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге, Олы Ачасыр» сүзләренә алмаштырырга;

в) алтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Олы Ачасыр авыл җирлеге чиге «Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге белән чиктәш җирдә «Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге, Олы Ачасыр авыл җирлеге һәм Югары Ослан муниципаль районы чикләре тоташкан урында Бритвин авылыннан 1,4 км көньякта Куйбышев сусаклагычы акваториясендә урнашкан X=461867,44, Y=1266525,73 координаталы 25 нче тоташу ноктасыннан алып 400 м төньяк-көнбатышка таба Куйбышев сусаклагычы акваториясе буйлап утрауны кисеп уза, аннары исемсез утрауның төньяк яры буенча 5,1 км төньяк-көнчыгышка таба һәм 650 м көньяк-көнбатышка таба бара, 150 м Куйбышев сусаклагычы акваториясе буйлап аның уң як ярына кадәр уза, шушы яр

буйлап 200 м кибеп баручы инешнең тамагына кадәр бара, 850 м шушы инеш агымы буйлап өскә таба сазлыкка кадәр уза, 1,3 км сазлык буйлап төньяк-көнчыгышка таба, 1,1 км сазлыкның төньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, алга таба 950 м төньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, урман полосасын кисеп үтеп, 150 м Горький тимер юлына бүлеп бирелгән полоса буенча, аны һәм Карамалы Тау – Албаба тимер юл разъезды поселогы автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 350 м күмәк бакчалар буйлап һәм 50 м көньяк-көнбатышка таба чокырны кисеп уза, 200 м күмәк бакчаларның төньяк-көнчыгыш чиге буйлап һәм 100 м төньяк-көнбатышка таба бара, 300 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, 400 м күмәк бакчаларның төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, аннары 300 м төньякка таба чокырның көнчыгыш чиге буйлап уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 50 м төньяк-көнчыгышка таба, 300 м урман полосасының көньяк чиге буйлап, 50 м, текә ярны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, аннары 700 м төньяк-көнбатышка таба чокыр төбе буйлап, 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап урман полосасына кадәр уза, аннары 800 м төньякка таба урман полосасының көнчыгыш чиге буйлап, 550 м, чокырны һәм Мәскәү – Уфа федераль автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, аннары 2,1 км төньяк-көнбатышка таба урман полосасының көньяк чиге буйлап, 800 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап текә ярга кадәр уза, 300 м төньякка таба текә ярның көнчыгыш чиге буйлап бара, аннары 40 м төньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап «Кайбыч урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Күгәй участок урманчылыгындагы 19 нчы урман кварталына кадәр уза, аннары шушы урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 100 м көнчыгышка таба һәм төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 800 м төньяк-көнбатышка таба бара, алга таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 400 м төньяк-көнбатышка таба, 350 м төньяк-көнчыгышка таба урман полосасына кадәр уза, 100 м урман полосасы буйлап, 250 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 26 нчы тоташу ноктасына кадәр бара.»;

7) 12 нче кушымтаны үз көчен югалткан дип танырга;

8) 13 нче кушымтада:
а) икенче абзацта «, Олы Ходяш, Мизиново авыл җирлекләре» сүзләрен «авыл җирлеге» сүзләренә алмаштырырга;

б) бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Олы Шырдан авыл җирлеге чиге «Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге белән чиктәш җирдә «Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге, Олы Ачасыр, Олы Шырдан авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Кече Шырдан авылыннан 1,4 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 26 нчы тоташу ноктасыннан алып агачлык-куаклык массивының төньяк чиге буйлап 30 м көнчыгышка таба, 50 м урман массивы буйлап, 200 м урман полосасының көньяк чиге буйлап, 400 м урман полосасы буйлап, 250 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м урман полосасы буйлап, 200 м урман полосасының көньяк чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары 100 м төньяк-көнчыгышка таба «Кайбыч урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Күгәй участок урманчылыгындагы 21 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, 40 м чокыр буйлап һәм 50 м көньяк-көнчыгышка таба уза, аннары, чокырны кисеп үтеп, 350 м көньяк-көнчыгышка таба һәм 900 м төньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап урман полосасына кадәр бара, 250 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 150 м урман полосасы буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 450 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 500 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, алга таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м төньяк-көнчыгышка таба һәм 250 м көньяк-көнчыгышка таба бара, 600 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 300 м, чокырны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 100 м һәм көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 1,3 км төньяк-көнчыгышка таба бара, 30 м «Карамалы Тау – Албаба тимер юл разъезды поселогы» – Олы Шырдан автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп уза, аннары 850 м төньяк-көнбатышка таба шушы автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның төньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 550 м төньяк-көнчыгышка таба, 1,6 км, сынык сызык ясап, күмәк бакчаларның көньяк-көнчыгыш чиге буйлап инешкә кадәр уза, аның агымы буйлап аска таба 950 м бара, аннары 1,8 км төньяк-көнчыгышка таба Горький тимер юлына бүлеп бирелгән полосаның көнбатыш чиге буйлап Сәкел елгасын, ике тапкыр инешне һәм аның текә ярын, күлләрне һәм профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп уза, аннары 350 м көнбатышка таба профильле автомобиль юлы

буйлап, 2,1 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап күмәк бакчаларга кадәр бара, аннары күмәк бакчаларның көньяк-көнчыгыш чиге буйлап көньяк-көнбатышка таба, 500 м, сынык сызык ясап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап инешкә кадәр уза, 4,3 км шушы инеш агымы буйлап өскә таба, дамбаны һәм Горький тимер юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 52 нче тоташу ноктасына кадәр бара.»;

в) алтынчы һәм җиденче абзацларны үз көчләрен югалткан дип танырга;

9) 18 нче кушымтаны үз көчен югалткан дип танырга;

10) 27 нче кушымтада:

а) икенче абзацта «, Мизиново авыл җирлекләре» сүзләрен «авыл җирлеге» сүзләренә алмаштырырга;

б) дүртенче абзацта «Мизиново, Свияжск (Зөя) авыл җирлекләре һәм Югары Ослан муниципаль районы чикләре тоташкан урында Куйбышев сусаклагычы акваториясендә урнашкан X=472689,97, Y=1277303,42» сүзләрен «Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге, Свияжск (Зөя) авыл җирлеге һәм Югары Ослан муниципаль районы чикләре тоташкан урында Свияжск (Зөя) авылыннан 1,1 км көньяк-көнчыгышта Куйбышев сусаклагычы акваториясендә урнашкан X=472689,99, Y=1277303,41» сүзләренә алмаштырырга;

в) бишенче абзацны үз көчен югалткан дип танырга;

г) алтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Свияжск (Зөя) авыл җирлеге чиге «Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге белән чиктәш җирдә 21 нче тоташу ноктасыннан алып Куйбышев сусаклагычы акваториясе буйлап 7,3 км, сынык сызык ясап, төньяк-көнбатышка таба, утрауларны кисеп үтеп, 5,6 км, сынык сызык ясап, Куйбышев сусаклагычының уң як яры буенча уза, алга таба Куйбышев сусаклагычы акваториясе буйлап 3,2 км төньяк-көнчыгышка таба, утрауларны кисеп үтеп, «Зеленодольск шәһәре», «Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлекләре, Әйшә һәм Свияжск (Зөя) авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогыннан 3,2 км төньяк-көнчыгышта Куйбышев сусаклагычы акваториясендә урнашкан X=479365,96, Y=1271527,30 координаталы 23 нче тоташу ноктасына кадәр бара.».

**5 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 елның 22 июле
№ 69-ТРЗ

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

### 979. Татарстан Республикасы Бюджет кодексына һәм «Татарстан Республикасы Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2013 елның 28 июнендә
кабул ителде

**1 статья**

Татарстан Республикасы Бюджет кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 4 – 5; 2005, № 6 (II өлеш), № 10 (I өлеш), № 12 (IV өлеш); 2006, № 6 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2007, № 8, № 10; 2008, № 8 (III өлеш), № 10 (I өлеш); 2009, № 7 – 8 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш), № 12; 2011, № 8 (I өлеш), № 11 (I өлеш), № 11 (II өлеш); 2012, № 11 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 5 статьяның 3 пунктын үз көчен югалткан дип танырга;

2) $20^1$ статьяның 7 пунктындагы өченче абзацында «55 статьясы нигезендә» сүзләреннән соң «, шулай ук Россия Федерациясе Бюджет кодексы һәм әлеге Кодексның $55^3$ статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Инвестиция фондының бюджет ассигнованиеләре исәбеннән» сүзләрен өстәргә;

3) $23^1$ статьяга түбәндәге эчтәлекле $3^2$ пункт өстәргә:

«$3^2$. Муниципаль районның муниципаль районнардагы башкарма-боеру органнарының җирлекләрдәге башкарма-боеру органнары вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга бәйле чыгым йөкләмәләре,

Россия Федерациясе законнары нигезендә җирлекләрнең башкарма-боеру органнары төзелмәгән очракта, муниципаль районның җирле үзидарә органнары тарафыннан билгеләнә һәм муниципаль районның үз керемнәре һәм бюджет кытлыгын финанслау чыганаклары исәбеннән үтәлә.»;

4) 24 статьяның 1 пунктында «Чираттагы финанс елына (чираттагы финанс елына һәм план чорының һәр елына) Татарстан Республикасы бюджеты кытлыгы, җирле бюджет кытлыгы» сүзләрен «Чираттагы финанс елына һәм план чорының һәр елына Татарстан Республикасы бюджеты кытлыгы, чираттагы финанс елына (чираттагы финанс елына һәм план чорының һәр елына) җирле бюджет кытлыгы» сүзләренә алмаштырырга;

5) 25 статьяның 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Татарстан Республикасы бюджетының агымдагы финанс елы башына калган акчалары:

финанс хисабы елында Татарстан Республикасы Инвестиция фондының, Татарстан Республикасы Юллар фондының бюджет ассигнованиеләреннән тулысынча файдаланмаган күләмдә тиешенчә агымдагы финанс елында Татарстан Республикасы Инвестиция фонды акчалары исәбеннән проектларны гамәлгә ашыруга, агымдагы финанс елында Татарстан Республикасы Юллар фондының бюджет ассигнованиеләре күләмнәрен арттыруга юнәлдереләчәк;

бюджет кытлыгын финанслауның күрсәтелгән чыганагы буларак каралган акчалардан артыграк күләмдә агымдагы финанс елында вакытлыча касса өзеклекләрен каплауга җибәрелергә мөмкин.»;

6) 31 статьяда:

а) 1 пунктның беренче абзацында «Чираттагы финанс елына (чираттагы финанс елына һәм план чорының һәр елына) Татарстан Республикасы дәүләт бурычының, муниципаль бурычның» сүзләрен «Чираттагы финанс елына һәм план чорының һәр елына Татарстан Республикасы дәүләт бурычының, чираттагы финанс елына (чираттагы финанс елына һәм план чорының һәр елына) муниципаль бурычның» сүзләренә алмаштырырга;

б) 5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы белән Татарстан Республикасы дәүләт эчке

бурычының иң югары чиге, Татарстан Республикасы дәүләт тышкы бурычының (әгәр андый булса) иң югары чиге чираттагы финанс елыннан һәм план чорының һәр елыннан соң килә торган елның 1 гыйнварына булган торышта билгеләнә, ул, Татарстан Республикасы дәүләт гарантияләре буенча бурычның иң югары чиген күрсәтеп, исәп-хисап күрсәткеченнән гыйбарәт була.

Җирле бюджет турындагы карар белән муниципаль бурычның иң югары чиге чираттагы финанс елыннан (чираттагы финанс елыннан һәм план чорының һәр елыннан) соң килә торган елның 1 гыйнварына булган торышта билгеләнә, ул, муниципаль гарантияләр буенча бурычның иң югары чиген күрсәтеп, исәп-хисап күрсәткеченнән гыйбарәт була.»;

7) 32 статьяның 1 пунктында:

а) беренче абзацта «Чираттагы финанс елына (финанс елына һәм план чорына) Татарстан Республикасы дәүләт эчке бурыч алулары, муниципаль бурыч алулар» сүзләрен «Чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы дәүләт эчке бурыч алулары, чираттагы финанс елына (чираттагы финанс елына һәм план чорына) муниципаль бурыч алулар» сүзләренә алмаштырырга;

б) икенче абзацта «чираттагы финанс елына (чираттагы финанс елына һәм план чорына)» сүзләрен «чираттагы финанс елына һәм план чорына (чираттагы финанс елына йә чираттагы финанс елына һәм план чорына)» сүзләренә алмаштырырга;

8) 33 статьяның 1 пунктында «Чираттагы финанс елына (финанс елына һәм план чорына) Татарстан Республикасы дәүләт бурычына яисә муниципаль бурычка хезмәт күрсәтү чыгымнарының тиешле бюджет турындагы закон (карар) белән расланган иң чик күләме» сүзләрен «Чираттагы финанс елында һәм план чорында Татарстан Республикасы дәүләт бурычына яисә чираттагы финанс елында (чираттагы финанс елында һәм план чорында) муниципаль бурычка хезмәт күрсәтү чыгымнарының тиешле бюджет турындагы закон (карар) белән расланган күләме» сүзләренә алмаштырырга;

9) 36 статьяда «Татарстан Республикасы дәүләт кыйммәтле кәгазьләрен» сүзләреннән соң «чираттагы финанс елына һәм план чорының һәр елына» сүзләрен өстәргә;

10) 38 статьяның 1 пунктында «Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законында» сүзләре алдыннан «чираттагы финанс елына һәм план чорына» сүзләрен өстәргә;

11) 41 статьяда:

а) түбәндәге эчтәлекле яңа өченче һәм дүртенче абзацлар өстәргә:

«Россия Федерациясе территориясендә җитештерелә торган дизельле һәм (яисә) карбюраторлы (инжекторлы) двигательләр өчен автомобиль һәм турыдан-туры куыла торган бензинга, дизель ягулыгына, мотор майларына акцизлардан җирле бюджетларга түләүләрнең дифференциацияләнгән нормативлары күләмнәре, җирле бюджетларга Татарстан Республикасы берләштерелгән бюджеты салым керемнәренең күрсәтелгән салымнан 10 процентын күчерүдән чыгып, чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы белән тиешле муниципаль берәмлекләр милкендәге җирле әһәмияттәге автомобиль юллары озынлыгыннан чыгып билгеләнә.

Россия Федерациясе территориясендә җитештерелә торган дизельле һәм (яисә) карбюраторлы (инжекторлы) двигательләр өчен автомобиль һәм турыдан-туры куыла торган бензинга, дизель ягулыгына, мотор майларына акцизлардан җирле бюджетларга түләүләрнең дифференциацияләнгән нормативлары күләмнәре әлеге Кодексның $1^1$ кушымтасы нигезендә билгеләнә.»;

б) өченче – алтынчы абзацларны тиешенчә бишенче – сигезенче абзацлар дип санарга;

12) 44 статьяда:

а) 2 пунктта «Россия Федерациясе Инвестиция фонды» сүзләреннән соң «һәм Татарстан Республикасы Инвестиция фонды» сүзләрен өстәргә, «өстәмә норматив түләүләре буенча салым керемнәре өлеше» сүзләрен «түләүләрнең өстәмә нормативлары буенча салым керемнәре өлеше түләүләрнең өстәмә нормативларына алмаштырылган бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотациянең исәпләнгән күләменнән (дотациянең исәпләнгән күләме өлешеннән) артмаган күләмдә» сүзләренә алмаштырырга;

б) 3 пунктта «Россия Федерациясе Инвестиция фонды» сүзләреннән соң «һәм Татарстан Республикасы Инвестиция фонды» сүзләрен өстәргә, «өстәмә норматив түләүләре буенча салым керемнәре өлеше» сүзләрен «түләүләрнең өстәмә нормативлары

буенча салым керемнәре өлеше түләүләрнең өстәмә нормативларына алмаштырылган бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотациянең исәпләнгән күләменнән (дотациянең исәпләнгән күләме өлешеннән) артмаган күләмдә» сүзләренә алмаштырырга;

в) 4 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Татарстан Республикасының бюджет системасындагы башка бюджетлардан бюджетара трансфертлар өлеше (субвенцияләрдән, шулай ук төзелгән килешүләр нигезендә җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләр өлешен гамәлгә ашыруга Россия Федерациясе Инвестиция фонды һәм Татарстан Республикасы Инвестиция фонды акчалары исәбеннән муниципаль берәмлекләргә бирелә торган субсидияләрдән һәм бюджетара трансфертлардан гайре) һәм (яисә) түләүләрнең өстәмә нормативлары буенча салым керемнәре өлеше түләүләрнең өстәмә нормативларына алмаштырылган бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотациянең исәпләнгән күләменнән (дотациянең исәпләнгән күләме өлешеннән) артмаган күләмдә үз бюджетларында соңгы өч финанс хисабы елының икесе дәвамында җирле бюджетның үз керемнәреннән 70 процентка арткан, шулай ук соңгы өч финанс хисабы елының бер һәм күбрәк елында җирле бюджет үтәлеше турында еллык хисаплары булмаган муниципаль берәмлекләрдә, әлеге статьяның 3 пунктында билгеләнгәннәргә өстәп, түбәндәге өстәмә чаралар гамәлгә ашырыла:»;

г) 5 пунктта:

«(субвенцияләрдән гайре)» сүзләрен төшереп калдырырга;

түбәндәге эчтәлекле яңа абзацлар өстәргә:

«Татарстан Республикасы бюджетыннан җирле бюджетларга субвенцияләр бирү, җирлекләр бюджетларына дотацияләр исәпләү һәм бирү буенча Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга муниципаль районнар бюджетларына бирелә торган субвенцияләрдән тыш, туктатып торылырга (кыскартылырга) тиеш түгел.

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы, җирлекләр бюджетларына дотацияләр исәпләү һәм бирү буенча Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга җирле үзидарә органнары Татарстан Республикасы бюджетыннан бюджетара трансфертлар бирү шартларын үтәмәгән җирлекләр бюджетларына күчерелергә тиешле дотацияләр күләме чикләрендә муниципаль районнар бюджетларына субвенцияләр бирүне туктатып тору (кыскарту) турында карар кабул итәргә хокуклы.

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы, федераль бюджеттан тиешле бюджетара трансфертлар бирүне гамәлгә ашыручы федераль бюджет акчаларын баш бүлүчеләр белән килештереп, җирле бюджетларга бирү өчен федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына тапшырыла торган бюджетара трансфертлар (субвенцияләрдән тыш) бирүне туктатып тору (кыскарту) турында карар кабул итәргә хокуклы.

Әлеге статьяның 2 – 4 пунктларында күрсәтелгән муниципаль берәмлекләр исемлеге Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан агымдагы финанс елының 15 ноябреннән дә соңга калмыйча раслана.»;

д) 6 пунктта «субвенцияләрдән» сүзеннән соң «, шулай ук төзелгән килешүләр нигезендә җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләре өлешен гамәлгә ашыруга Россия Федерациясе Инвестиция фонды һәм Татарстан Республикасы Инвестиция фонды акчалары исәбеннән муниципаль берәмлекләргә бирелә торган субсидияләрдән һәм бюджетара трансфертлардан» сүзләрен өстәргә;

е) түбәндәге эчтәлекле 7 һәм 8 пунктлар өстәргә:

«7. Татарстан Республикасы бюджетыннан җирле бюджетларга, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 18[1] статьясы нигезендә билгеләнгән, җирле үзидарә органнары тарафыннан ирешелгән күрсәткечләр нәтиҗәләреннән чыгып, бюджетара трансфертлар бирү (иң яхшы күрсәткечләргә ирешүгә ярдәм итү һәм (яисә) ирешүне кызыксындыру максатларында бирелә торган бюджетара трансфертлардан тыш) рөхсәт ителми.

8. Муниципаль районнарның җирле үзидарә органнарына җирлекләр бюджетларына дотацияләр исәпләү һәм бирү буенча Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары вәкаләтләре бирелгән очракта, җирлекләр бюджетларына Татарстан Республикасы бюджеты исәбеннән бюджетара трансфертлар (субвенцияләрдән гайре) җирлекләренең тиешле җирле үзидарә органнары тарафыннан Татарстан Республикасы бюджетыннан җирле бюджетларга әлеге статьяда каралган бюджетара трансфертларны бирүнең төп шартлары үтәлгән килеш тапшырыла.»;

13) 44[1] статьяда:

а) 2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Җирлекләрнең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияләр күләме чираттагы финанс елына һәм план чорына

Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы белән раслана һәм җирлекләрнең җирле үзидарә органнары тарафыннан җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләрен гамәлгә ашыру буенча җирлекләрнең чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы белән билгеләнгән финанс мөмкинлекләрен тигезләү критериена ирешү зарурлыгыннан чыгып билгеләнә.

Чираттагы финанс елына һәм план чорына җирлекләрнең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияләр күләмен билгеләгәндә җирлекләрнең җирле үзидарә органнары тарафыннан җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләрен гамәлгә ашыру буенча җирлекләрнең финанс мөмкинлекләрен тигезләү критерие күрсәткечен чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы белән билгеләнгән күрсәтелгән критерий күрсәткеченнән киметүгә юл куелмый.

Җирлекләрнең финанс мөмкинлекләрен тигезләү критерием билгеләү тәртибе әлеге Кодексның 2 нче кушымтасында билгеләнә.»;

б) 4 пунктта:

өченче абзацта «җирлекләрнең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә исәп-хисап дотациясе күләменнән» сүзләрен «җирлекләрнең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотациянең исәпләнгән күләменнән» сүзләренә алмаштырырга;

дүртенче абзацта «җирлекләрнең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә исәп-хисап дотациясе күләменнән» сүзләрен «җирлекләрнең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотациянең исәпләнгән күләменнән» сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле яңа алтынчы һәм җиденче абзацлар өстәргә:

«Җирлекләр арасында җирлекләрнең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә бүлеп бирелмәгән дотацияләр күләмен күрсәтелгән дотацияләрнең план чорының беренче елына расланган гомуми күләменең 20 процентыннан һәм күрсәтелгән дотацияләрнең план чорының икенче елына расланган гомуми күләменең 20 процентыннан артык булмаган күләмдә раслау рөхсәт ителә.

Чираттагы финанс елына һәм план чорының беренче елына һәр җирлек бюджетына җирлекләрнең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотация күләме агымдагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджетында җирлекләрнең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә тиешенчә план чорының беренче

һәм план чорының икенче елына расланган дотация күләменнән кимрәк була алмый, моңа федераль законнар белән Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнарын арттыруга һәм (яисә) керемнәрен киметүгә китерә торган үзгәрешләр кертү очраклары керми.»;

алтынчы абзацны сигезенче абзац дип санарга;

14) $44^2$ статьяда:

а) 2 пунктның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Муниципаль районнарның (шәһәр округларының) исәпләнгән бюджет тәэмин ителешен тигезләү критериен билгеләү тәртибе әлеге Кодексның 5 нче кушымтасы нигезендә билгеләнә.»;

б) $3^1$ пунктта:

икенче абзацта «чираттагы финанс елына һәм план чорына» сүзләрен төшереп калдырырга, «исәпләнгән хисап күләменең» сүзләреннән соң «(дотациянең исәпләнгән күләме өлешенең)» сүзләрен өстәргә;

дүртенче абзацта «исәпләнгән дотациясе күләменнән» сүзләрен «муниципаль районнарның (шәһәр округларының) бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотациянең исәпләнгән күләменнән (дотациянең исәпләнгән күләме өлешеннән)» сүзләренә алмаштырырга;

бишенче абзацта «исәпләнгән дотациядән кимрәк күләмдә» сүзләрен «муниципаль районнарның (шәһәр округларының) бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотациянең исәпләнгән күләменнән (дотациянең исәпләнгән күләме өлешеннән) кимрәк итеп» сүзләренә алмаштырырга;

в) 4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Муниципаль районнарның (шәһәр округларының) бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияләр күләме чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы белән раслана һәм муниципаль районнарның (шәһәр округларының) чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы белән билгеләнгән исәпләнгән бюджет тәэмин ителешен тигезләү критериена ирешү зарурлыгыннан чыгып билгеләнә.

Чираттагы финанс елына һәм план чорына муниципаль районнарның (шәһәр округларының) бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияләр күләмен билгеләгәндә муници-

паль районнарның (шәһәр округларының) исәпләнгән бюджет тәэмин ителешен тигезләүнең әлеге пунктның беренче абзацында күрсәтелгән критериен чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы белән билгеләнгән күрсәтелгән критерий күрсәткеченнән киметүгә юл куелмый.

Муниципаль районнарның (шәһәр округларының) бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияләрне муниципаль районнар (шәһәр округлары) арасында бүлү һәм (яисә) аларны алмаштыручы муниципаль районнарның (шәһәр округларының) бюджетларына физик затлар керемнәренә салымнан түләүләрнең өстәмә нормативлары чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы белән раслана.

Муниципаль районнар (шәһәр округлары) арасында муниципаль районнарның (шәһәр округларының) бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә бүлеп бирелмәгән дотацияләр күләмен күрсәтелгән дотацияләрнең план чорының беренче елына расланган гомуми күләменең 20 процентыннан һәм күрсәтелгән дотацияләрнең план чорының икенче елына расланган гомуми күләменең 20 процентыннан артык булмаган күләмдә раслау рөхсәт ителә.

Чираттагы финанс елына һәм план чорының беренче елына муниципаль район (шәһәр округы) бюджетына муниципаль районнарның (шәһәр округларының) бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотация күләме агымдагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджетында муниципаль районнарның (шәһәр округларының) бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә тиешенчә план чорының беренче һәм план чорының икенче елына расланган дотация күләменнән кимрәк була алмый, моңа федераль законнар белән Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнарын арттыруга һәм (яисә) керемнәрен киметүгә китерә торган үзгәрешләр кертү очраклары керми.»;

15) $44^4$ статьяның 3 пунктында:

а) беренче абзацта «актлары белән» сүзләреннән соң «Россия Федерациясе Бюджет кодексы таләпләре нигезендә» сүзләрен өстәргә;

б) түбәндәге эчтәлекле яңа икенче абзац өстәргә:

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты кимендә өч елга муниципаль берәмлекләрнең җирле әһәмияттәге мәсьәләләр буенча аларны финанслашу максатларында, Татарстан

Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирелеп, җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләре исемлеген, субсидияләр бирүнең нәтиҗәлелеген һәм аларның күрсәткечләрен раслый.»;

в) икенче абзацны өченче абзац дип санарга;

16) 47 статьяда:

а) 1 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Муниципаль районның административ үзәге булып торган җирлектәге башкарма-боеру органының бюджет вәкаләтләрен, әгәр Россия Федерациясе законнары нигезендә җирлекнең башкарма-боеру органы төзелмәсә, составына күрсәтелгән җирлек кергән муниципаль районның башкарма-боеру органы гамәлгә ашырырга мөмкин.»;

б) 2 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Җирлектәге финанс органының аерым бюджет вәкаләтләре җирлекнең җирле администрациясе һәм муниципаль районның җирле администрациясе арасындагы килешү нигезендә муниципаль районның финанс органы тарафыннан гамәлгә ашырылырга мөмкин.»;

17) 49 статьяның утыз дүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«финанс тәэмин ителеше бюджетара субсидияләр, субвенцияләр һәм Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелә торган, максатчан билгеләнешкә ия башка бюджетара трансфертлар исәбеннән гамәлгә ашырыла торган бюджет чыгымнарының максатчан статьялары һәм (яисә) төрләре исемлеген һәм кодларын билгеләү тәртибен урнаштыра;»;

18) 52 статьяның 3 пунктында «(чираттагы финанс елына һәм план чорына)» сүзләрен « – чираттагы финанс елына һәм план чорына» сүзләренә алмаштырырга;

19) 53[1] статьяның 2 пунктында «Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы проекты» сүзләре алдыннан «Чираттагы финанс елына һәм план чорына» сүзләрен өстәргә;

20) 55[2] статьяның 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Татарстан Республикасы Юллар фондының бюджет ассигнованиеләре күләме чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы белән фаразланган күләмнән дә кимрәк булмаган түбәндәге күләмдә раслана:

Россия Федерациясе территориясендә җитештерелә торган дизельле һәм (яисә) карбюраторлы (инжекторлы) двигательләр өчен автомобиль бензинына, турыдан-туры куыла торган бензинга, дизель ягулыгына, мотор майларына Татарстан Республикасы бюджетына күчерелергә тиешле акцизлардан Татарстан Республикасы бюджеты керемнәре;

транспорт салымыннан Татарстан Республикасы бюджеты керемнәре;

юллар эшчәнлеген финанс белән тәэмин итүгә федераль бюджеттан субсидияләрдән Татарстан Республикасы бюджеты керемнәре;

региональ яисә муниципальара әһәмиятле гомуми файдаланудагы автомобиль юлларына карата юллар эшчәнлеген финанс белән тәэмин итүгә физик һәм юридик затлардан кире кайтарылмый торган кертемнәрдән, шул исәптән ихтыярый иганәләрдән, Татарстан Республикасы бюджеты керемнәре.»;

21) түбәндәге эчтәлекле $55^3$ статья өстәргә:

«$55^3$ статья. **Татарстан Республикасы Инвестиция фонды**

1. Татарстан Республикасы Инвестиция фонды – Татарстан Республикасы территориясендә дәүләт-хосусый партнерлык принципларында гамәлгә ашырыла торган инвестиция проектларын башкару максатларында файдаланырга тиешле Татарстан Республикасы бюджеты акчалары өлеше.

2. Татарстан Республикасы Инвестиция фондының бюджет ассигнованиеләре күләме чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы белән раслана.

3. Татарстан Республикасы Инвестиция фондының бюджет ассигнованиеләре агымдагы финанс елында һәм план чорында Татарстан Республикасы Инвестиция фондының финанс хисабы елында файдаланылмаган бюджет ассигнованиеләре суммасына, шулай ук, әлеге Кодексның 97 статьясындагы 4 пункты нигезләмәләрен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Инвестиция фонды акчаларының финанс хисабы елында файдаланылмаган

акчалары исәбеннән башка бюджетларга бирелгән субсидияләрне кире кайтарудан алынган керемнәр күләменә арттырылырга тиеш.

4. Татарстан Республикасы Инвестиция фондының бюджет ассигнованиеләрен формалаштыру һәм алардан файдалану тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә.»;

22) 61 статьяның 4 пунктындагы сигезенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы дәүләт эчке бурычының чираттагы финанс елыннан һәм план чорының һәр елыннан соң килүче елның 1 гыйнварына иң югары чиге һәм (яисә) Татарстан Республикасы дәүләт тышкы бурычының чираттагы финанс елыннан һәм план чорының һәр елыннан соң килүче елның 1 гыйнварына иң югары чиге;»;

23) түбәндәге эчтәлекле $1^1$ нче кушымта өстәргә:

«Татарстан Республикасы
Бюджет кодексына
$1^1$ нче кушымта

**Россия Федерациясе территориясендә җитештерелә торган дизельле һәм (яисә) карбюраторлы (инжекторлы) двигательләр өчен автомобиль һәм турыдан-туры куыла торган бензинга, дизель ягулыгына, мотор майларына акцизлардан җирле бюджетларга түләүләрнең дифференциацияләнгән нормативларын исәпләү тәртибе**

1. Россия Федерациясе территориясендә җитештерелә торган дизельле һәм (яисә) карбюраторлы (инжекторлы) двигательләр өчен автомобиль һәм турыдан-туры куыла торган бензинга, дизель ягулыгына, мотор майларына акцизлардан i-муниципаль районы (шәһәр округы) бюджетына түләүләрнең дифференциацияләнгән нормативын исәпләү түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$ДН^i = \frac{ПД^i}{ПД^{общ}} \times 100,$$

монда:

$ДН^i$ – Россия Федерациясе территориясендә җитештерелә торган дизельле һәм (яисә) карбюраторлы (инжекторлы)

двигательләр өчен автомобиль һәм турыдан-туры куыла торган бензинга, дизель ягулыгына, мотор майларына акцизлардан i-муниципаль районы (шәһәр округы) бюджетына әлеге Кодексның 41 статьясы нигезендә җирле бюджетларга күчерелергә тиешле түләүләрнең дифференциацияләнгән нормативы, процентларда;

$ПД^i$ – i-муниципаль районы территориясендә урнашкан җирлекләр милкендәге, i-муниципаль районы (шәһәр округы) милкендәге җирле әһәмияттәге автомобиль юлларының агымдагы елның 1 гыйнварына булган торышта статистика хисаплылыгы белешмәләре нигезендә билгеләнә торган озынлыгы, километрларда;

$ПД^{общ}$ – Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре милкендәге җирле әһәмияттәге автомобиль юлларының гомуми озынлыгы, километрларда.

2. Россия Федерациясе территориясендә җитештерелә торган дизельле һәм (яисә) карбюраторлы (инжекторлы) двигательләр өчен автомобиль һәм турыдан-туры куыла торган бензинга, дизель ягулыгына, мотор майларына акцизлардан i-муниципаль районы (шәһәр округы) бюджетына түләүләрнең дифференциацияләнгән нормативы өтердән соң дүртенче билгегә кадәр төгәллек белән исәпләнә.»;

24) 2 нче кушымтада:

а) 2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. ФФПП күләме ел саен чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты проектын төзегәндә җирлекләрнең җирле үзидарә органнары тарафыннан җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләрен гамәлгә ашыру буенча җирлекләрнең финанс мөмкинлекләрен тигезләү критериена ирешү зарурлыгыннан чыгып билгеләнә.

ФФПП күләме әлеге Кодексның $44^{10}$ статьясында билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы бюджетына җирлекләр бюджетларыннан күчерелә торган субсидияләр күләменнән кимрәк була алмый.»;

б) түбәндәге эчтәлекле $2^1$ пункт өстәргә:

«$2^1$. Җирлекләрнең җирле үзидарә органнары тарафыннан җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләрен гамәлгә ашыру буенча җирлекләрнең финанс мөмкинлекләрен тигезләү критерие ел саен чираттагы финанс елына һәм план чорына Та-

тарстан Республикасы бюджеты проектын төзегәндә Татарстан Республикасы бюджетыннан җирлекләрнең бюджет белән тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияләрне җирле бюджетларга һәм җирлекләрнең региональ финанс ярдәме фондыннан җирлекләргә дотацияләр исәпләү һәм бирү буенча дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга муниципаль районнар бюджетларына субвенцияләр бирү нәтиҗәсендә җирлекләр арасында (шәһәр округларын кертеп) минималь күрсәткечне бер кешегә исәпләгәндә шартлы салым потенциалы күләмен арттыру зарурлыгыннан чыгып билгеләнә.

Җирлекләрнең җирле үзидарә органнары тарафыннан җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләрен гамәлгә ашыру буенча җирлекләрнең финанс мөмкинлекләрен тигезләү критерие буларак билгеләнә торган дәрәҗә түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$К = ( УНП^{i} / Ч^{i})_{мин} \text{ х } Коэф_{ИПЦ} ,$$

монда:

К – җирлекләрнең җирле үзидарә органнары тарафыннан җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләрен гамәлгә ашыру буенча җирлекләрнең финанс мөмкинлекләрен тигезләү критерие;

$УНП^{i}$ – i-җирлегенең (шәһәр округларын кертеп) тигезләүгә кадәр әлеге Кодексның 7 нче кушымтасы нигезендә билгеләнгән тәртип буенча исәпләп чыгарыла торган шартлы салым потенциалы;

$Ч^{i}$ – i-җирлегенең (шәһәр округларын кертеп) халык саны;

$(УНП^{i} / Ч^{i})_{мин}$ – җирлекләр (шәһәр округларын кертеп) арасында тигезләүгә кадәр бер кешегә исәпләгәндә шартлы салым потенциалы күләменең минималь күрсәткече;

$Коэф_{ИПЦ}$ – Татарстан Республикасы социаль-икътисадый үсеше фаразы нигезендә куллану бәяләре индексы.»;

25) 5 нче кушымтаның 7 пунктына түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Муниципаль районнарның (шәһәр округларының) исәпләнгән бюджет тәэмин ителешен тигезләү критерие буларак билгеләнә торган дәрәҗә түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$К = 2 \times \sum_{i=1}^{n} БО^{i}_{расч} / n,$$

монда:

К – муниципаль районнарның (шәһәр округларының) исәпләнгән бюджет тәэмин ителешен тигезләү критерие;

$БО^{i}_{расч}$ – i-муниципаль районының (шәһәр округының) тигезләүгә кадәр исәпләнгән бюджет тәэмин ителеше дәрәҗәсе;

n – муниципаль районнар (шәһәр округлары) саны.

Муниципаль районнар (шәһәр округлары) өчен аларның муниципаль районнарның (шәһәр округларының) исәпләнгән бюджет тәэмин ителешен тигезләү критерие буларак билгеләнгән дәрәҗәгә ирешү зарурлыгыннан чыгып исәпләнгән бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияләрнең суммар күләме муниципаль районнарның (шәһәр округларының) суммар ихтыяҗларын һәм керем мөмкинлекләрен бәяләүдәге аермадан кимрәк күләмдә булган очракта, муниципаль районнарның (шәһәр округларының) исәпләнгән бюджет тәэмин ителешен тигезләү критерие арттырып билгеләнә.

Муниципаль районнарның (шәһәр округларының) исәпләнгән бюджет тәэмин ителешен тигезләүнең арттырылган критерие түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$К_п = К \times Коэф,$$

монда:

$К_п$ – муниципаль районнарның (шәһәр округларының) исәпләнгән бюджет тәэмин ителешен тигезләүнең арттырылган критерие;

К – муниципаль районнарның (шәһәр округларының) исәпләнгән бюджет тәэмин ителешен тигезләүнең әлеге пункт нигезендә исәпләнгән критерие;

Коэф – тигезләү критерие дәрәҗәсен арттыра торган коэффициент; Коэф > 1.

Тигезләү критерие дәрәҗәсен арттыра торган коэффициент күрсәткече ел саен чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты проектын төзегәндә билгеләнә һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана.».

**2 статья**

«Татарстан Республикасы Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү турында» 2007 елның 2 августындагы 38-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2007, № 8; 2009, № 1, № 7 – 8 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш); 2012, № 11 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 статьяда 4 пунктның «г» пунктчасын үз көчен югалткан дип танырга;

2) 3 статьяның 8 пунктындагы икенче абзацында «2008 – 2012 елларга» сүзләрен «2008 – 2013 елларга» сүзләренә алмаштырырга.

**3 статья**

1. Әлеге Закон, шушы статья белән үз көченә керүнең башка сроклары билгеләнгән нигезләмәләрдән тыш, рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

2. Әлеге Законның 1 статьясындагы 4, 6 – 11, 13 – 15, 18 – 20, 22 – 25 пунктлары 2014 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 елның 22 июле
№ 70-ТРЗ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

## 980. Аерым муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен үзгәртү һәм «Бөгелмә муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2013 елның 28 июнендә
кабул ителде

**1 статья**

Бөгелмә муниципаль районы составындагы «Бөгелмә шәһәре», «Березовка авыл җирлеге», «Зеленая Роща авыл җирлеге», «Кече Бөгелмә авыл җирлеге» муниципаль берәмлекләренең территорияләре чикләрен әлеге Законга кушымта нигезендә үзгәртергә.


**2 статья**

«Бөгелмә муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» 2005 елның 31 гыйнварындагы 18-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 1 (II өлеш); 2008, № 8 (IV өлеш); 2010, № 5 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

# 1) 1 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Бөгелмә муниципаль районы”
муниципаль берәмлегенең һәм аның
составындагы муниципаль
берәмлекләрнең территорияләре
чикләрен билгеләү һәм
аларның статусы турында” Татарстан
Республикасы Законына
1 нче кушымта

“Бөгелмә муниципаль районы”
муниципаль берәмлеге составына керүче
муниципаль берәмлекләрнең чикләре
**карта-схемасы**




Шартлы билгеләр

-Татарстан Республикасы чиге
- муниципаль район чиге
-тоташу ноктасының тәртип саны
10 -җирлекләрнең чикләре һәм аларның сан белән билгеләнеше
-торак пунктлар
-муниципаль районның административ үзәге
-җирлекнең административ үзәге

Муниципаль районың чиктәш чикләре тасвирламасы

40 (25) – 41 - Самара өлкәсе

32 (24) – 41 - Оренбург өлкәсе

40 (25) – 1 (76) - Лениногорск муниципаль районы

1 (76) – 3 (73) - Әлмәт муниципаль районы

3 (73) – 28 (74) - Азнакай муниципаль районы

28 (74) – 30 (75) - Ютазы муниципаль районы

30 (75) – 32 (24) - Баулы муниципаль районы

«Бөгелмә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге составына керүче шәһәр һәм авыл җирлекләре

| Карта-схемадагы № | Муниципаль берәмлек |
|---|---|
| 1 | Бөгелмә шәһәре |
| 2 | Карабаш шәһәр тибындагы поселогы |
| 3 | Акбаш авыл җирлеге |
| 4 | Березовка авыл җирлеге |
| 5 | Зур Федоровка авыл җирлеге |
| 6 | Восточный авыл җирлеге |
| 7 | Вязовка авыл җирлеге |
| 8 | Зеленая Роща авыл җирлеге |
| 9 | Ключи авыл җирлеге |
| 10 | Кодаш авыл җирлеге |
| 11 | Кече Бөгелмә авыл җирлеге |
| 12 | Наратлы авыл җирлеге |
| 13 | Яңа Александровка авыл җирлеге |
| 14 | Яңа Сумароков авыл җирлеге |
| 15 | Петровка авыл җирлеге |
| 16 | Подгорный авыл җирлеге |
| 17 | Спас авыл җирлеге |
| 18 | Иске Исаково авыл җирлеге |
| 19 | Татар Димескәе авыл җирлеге |

»;

2) 3 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Бөгелмә муниципаль районы»
муниципаль берәмлегенең һәм
аның составындагы муниципаль
берәмлекләрнең территорияләре
чикләрен билгеләү һәм аларның
статусы турында»
Татарстан Республикасы Законына
3 нче кушымта

## Бөгелмә муниципаль районының «Бөгелмә шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы

Әлеге картографик тасвирлама «Бөгелмә шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Бөгелмә муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

«Бөгелмә шәһәре» муниципаль берәмлеге Березовка, Вязовка, Зеленая Роща һәм Кече Бөгелмә авыл җирлекләре белән чиктәш.

## Бөгелмә муниципаль районының «Бөгелмә шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясе чиге

«Бөгелмә шәһәре» муниципаль берәмлеге чиге Березовка авыл җирлеге белән чиктәш җирдә «Бөгелмә шәһәре» муниципаль берәмлеге, Березовка һәм Кече Бөгелмә авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Кече Бөгелмә авылыннан 100 м төньяк-көнбатышта Бөгелмә елгасы үзәнендә урнашкан 45 нче тоташу ноктасыннан алып 6,5 км Бөгелмә елгасы агымы буенча өскә таба уза, алга таба, сынык сызык ясап, 750 м төньяк-көнбатышка таба күмәк бакчаларның төньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, аннары 200 м төньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, 100 м төньякка таба «Бөгелмә урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Бөгелмә участок урманчылыгындагы 88 нче урман кварталының көньяк чиге буйлап уза, алга таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, 450 м төньяк-көнбатышка таба һәм 1,0 км көньяк-көнбатышка таба уза, аннары, сынык сызык ясап, 700 м төньяк-көнчыгышка таба 80 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, сынык сызык ясап, көнбатышка таба 80 нче урман кварталы

буйлап 550 м уза, 79 нчы урман кварталының көньяк чиге буйлап 600 м бара, алга таба 79 нчы урман кварталы буйлап 300 м төньяк-көнчыгышка таба, 150 м төньяк-көнбатышка таба, 200 м көньяк-көнбатышка таба уза, аннары 150 м төньяк-көнбатышка таба 79 нчы урман кварталының көнбатыш чиге буйлап бара, сынык сызык ясап, 350 м төньякка таба 79 нчы урман кварталы буйлап уза, алга таба 550 м төньяк-көнчыгышка таба шушы урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап, 74 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап 1,4 км бара, аннары 54 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап 700 м төньякка таба уза, алга таба 50 м төньяк-көнбатышка таба, Бөгелмә – Азнакай автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары 34 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 200 м төньяк-көнбатышка таба, 200 м төньяк-көнчыгышка таба һәм 200 м төньяк-көнбатышка таба бара, алга таба 33 нче урман кварталының көньяк чиге буйлап 450 м көнбатышка таба, 900 м урман полосасы буйлап, 250 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары дамбаның төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 400 м төньяк-көнбатышка таба бара, шуннан соң 150 м көньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Соколка елгасына кадәр, 250 м шушы елга агымы буенча өскә таба Бөгелмә – Березовка – «Бөгелмә – Аэропорт» автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп уза, аннары 1,3 км көньякка таба шушы автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көнбатыш чиге буйлап уза, 50 м көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 50 м сәнәгать объектының төньяк чиге буйлап бара, сынык сызык ясап, 150 м көньяк-көнчыгышка таба сәнәгать объектының көнчыгыш һәм көньяк чикләре буйлап уза, алга таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 20 м көнчыгышка таба һәм 100 м көньякка таба уза, 2,4 км профильле автомобиль юлы буйлап Казан – Оренбург автомобиль юлына кадәр бара һәм аның буенча 100 м төньяк-көнбатышка таба уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 200 м көньяк-көнбатышка таба, урман массивын кисеп үтеп, һәм 150 м, дамбаны кисеп үтеп, көньяк-көнчыгышка таба бара, алга таба көньяк-көнбатышка таба 1,8 км Казан – Оренбург автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 250 м Бөгелмә – Лениногорск автомобиль юлы буйлап «Бөгелмә шәһәре» муниципаль берәмлеге, Березовка һәм Вязовка авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Таллы Бүләк авылыннан 2,6 км көньякта урнашкан 44 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

«Бөгелмә шәһәре» муниципаль берәмлеге чиге Вязовка авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 44 нче тоташу ноктасыннан алып 2,2 км көньяк-көнчыгышка таба Казан – Оренбург автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көнбатыш чиге буйлап Бөгелмә – Коногоровка автомобиль юлына кадәр уза, шушы автомобиль юлы буйлап 650 м төньяк-көнчыгышка таба бара, аннары 100 м көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап «Бөгелмә шәһәре» муниципаль берәмлеге, Вязовка һәм Зеленая Роща авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Забугоровка авылыннан 2,4 км төньяк-көнбатышта урнашкан 21 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

«Бөгелмә шәһәре» муниципаль берәмлеге чиге Зеленая Роща авыл җирлеге белән чиктәш җирдә «Бөгелмә шәһәре» муниципаль берәмлеге, Зеленая Роща һәм Кече Бөгелмә авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Забугоровка авылыннан 1,2 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 20 нче тоташу ноктасыннан алып 750 м көнбатышка таба, урман полосасын кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, алга таба урман полосасының көнбатыш чиге буйлап 250 м көньякка таба, 250 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, аннары 50 м көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, алга таба 500 м төньяк-көнбатышка таба буаның сул як яры буенча, 100 м Казачья елгасы агымы буенча өскә таба Казан – Оренбург автомобиль юлына кадәр бара, алга таба шушы автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 700 м, профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, төньяк-көнбатышка таба уза, аннары шушы автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көнбатыш чиге буйлап төньякка таба бара, аннары 650 м көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, алга таба 200 м көньяк-көнбатышка таба Бөгелмә – Уральск автомобиль юлы буйлап бара, аннары төньяк-көнбатышка таба 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м «Бөгелмә урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Бөгелмә участок урманчылыгындагы 94 нче урман кварталының аерымланган кишәрлеге буйлап, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап урман массивын, урман полосасын һәм Куйбышев тимер юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп уза, шуннан соң төньяк-көнчыгышка таба 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 250 м урман массивы чиге буйлап бара, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 94 нче урман кварталы аерымланган кишәрлегенең көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 50 м уза, аннары, сынык сызык

ясап, шушы урман кварталы аерымланган кишәрлегенең төньяк чиге буйлап 450 м көнбатышка таба, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 94 нче урман кварталы аерымланган кишәрлегенең төньяк чиге буйлап 100 м, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, алга таба, сынык сызык ясап, 550 м төньяк-көнбатышка таба 94 нче урман кварталы аерымланган кишәрлегенең төньяк чиге буйлап уза, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 94 нче урман кварталы аерымланган кишәрлегенең төньяк чиге буйлап 50 м бара, 750 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 21 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

«Бөгелмә шәһәре» муниципаль берәмлеге чиге Кече Бөгелмә авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 20 нче тоташу ноктасыннан алып, сынык сызык ясап, 350 м көнчыгышка таба күмәк бакчаларның төньяк чиге буйлап уза, шуннан соң 450 м төньяк-көнчыгышка таба урман массивы буйлап бара, аннары көньяк-көнчыгышка таба 450 м, Куйбышев тимер юлына бүлеп бирелгән полосаны һәм профильле автомобиль юлын кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, алга таба, сынык сызык ясап, 450 м көньяк-көнбатышка таба 96 нчы урман кварталының аерымланган кишәрлеге буйлап бара, аннары 100 м көньякка таба, буа плотинасын һәм Казачья елгасын кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, шуннан соң 500 м көньяк-көнбатышка таба, урман полосасын кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, 4,8 км көнчыгышка таба, урман массивын, агачлык-куаклык массивын, инешне, Зәй елгасын һәм яр буендагы агачлык-куаклык массивларын кисеп үтеп, Куйбышев тимер юлына бүлеп бирелгән полосаның төньяк чиге буйлап уза, шуннан соң 50 м төньякка таба бүлеп бирелгән полосаның көнчыгыш чиге буенча авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 900 м Куйбышев тимер юлына бүлеп бирелгән полосаның төньяк-көнбатыш чиге буйлап, текә ярны, инешне һәм урман массивын кисеп үтеп, Бөгелмә – Татар Димескәе автомобиль юлына кадәр бара, аннары 900 м төньяк-көнбатышка таба шушы автомобиль юлы буенча бара, алга таба 900 м көньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, инешне һәм аның текә ярларын, профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 50 м профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көньяк-көнчыгыш чиге буйлап буага кадәр уза, 400 м көньякка таба буаның уң як яры буйлап уза, 1,9 км төньяк-көнчыгышка таба буаның сул як яры буйлап, профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, буа плотинасына кадәр бара, аннары, сынык сызык ясап, 500 м

төньякка таба, Бөгелмә – Татар Димескәе автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, аннары 400 м төньяк-көнбатышка таба шушы автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның төньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, 700 м төньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, юл буендагы урман полосасын кисеп үтеп, профильле автомобиль юлына кадәр уза, алга таба 400 м төньяк-көнбатышка таба шушы автомобиль юлы буйлап бара, 1,0 км төньяк-көнчыгышка таба Бөгелмә – Ютазы автомобиль юлы буйлап уза, аннары 50 м төньякка таба күмәк бакчаларның көнбатыш чиге буйлап бара, 50 м төньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, тирән чокырны кисеп үтеп, 45 нче тоташу ноктасына кадәр уза.”;

3) 6 нчы кушымтада:

а) унынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Березовка авыл җирлеге чиге Кече Бөгелмә авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 17 нче тоташу ноктасыннан алып 1,9 км Зәй елгасы агымы буенча өскә таба Бөгелмә елгасы белән кушылган җиргә кадәр уза, аннары 1,1 км Бөгелмә елгасы агымы буенча өскә таба «Бөгелмә шәһәре» муниципаль берәмлеге, Березовка һәм Кече Бөгелмә авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Кече Бөгелмә авылыннан 100 м төньяк-көнбатышта Бөгелмә елгасы үзәнендә урнашкан 45 нче тоташу ноктасына кадәр бара.»;

б) уникенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Березовка авыл җирлеге чиге «Бөгелмә шәһәре» муниципаль берәмлеге белән чиктәш җирдә 45 нче тоташу ноктасыннан алып 6,5 км Бөгелмә елгасы агымы буенча өскә таба уза, алга таба, сынык сызык ясап, 750 м төньяк-көнбатышка таба күмәк бакчаларның төньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, аннары 200 м төньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, 100 м төньякка таба «Бөгелмә урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Бөгелмә участок урманчылыгындагы 88 нче урман кварталының көньяк чиге буйлап уза, алга таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, 450 м төньяк-көнбатышка таба һәм 1,0 км көньяк-көнбатышка таба уза, аннары, сынык сызык ясап, 80 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 700 м төньяк-көнчыгышка таба бара, сынык сызык ясап, 80 нче урман кварталы буйлап көнбатышка таба 550 м уза, 79 нчы урман кварталының көньяк чиге буйлап 600 м бара, алга таба 79 нчы урман кварталы буйлап 300 м төньяк-көнчыгышка таба, 150 м төньяк-көнбатышка таба, 200 м көньяк-көнбатышка таба уза, аннары 79 нчы урман

кварталының көнбатыш чиге буйлап 150 м төньяк-көнбатышка таба бара, сынык сызык ясап, 79 нчы урман кварталы буйлап 350 м төньякка таба уза, алга таба шушы урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап 550 м төньяк-көнчыгышка таба, 74 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап 1,4 км бара, аннары 54 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап 700 м төньякка таба уза, алга таба 50 м төньяк-көнбатышка таба, Бөгелмә – Азнакай автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары 34 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 200 м төньяк-көнбатышка таба, 200 м төньяк-көнчыгышка таба һәм 200 м төньяк-көнбатышка таба бара, алга таба 33 нче урман кварталының көньяк чиге буйлап 450 м көнбатышка таба, 900 м урман полосасы буйлап, 250 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары 400 м төньяк-көнбатышка таба дамбаның төньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, шуннан соң 150 м көньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Соколка елгасына кадәр, 250 м шушы елга агымы буенча өскә таба, Бөгелмә – Березовка – «Бөгелмә – Аэропорт» автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп уза, аннары 1,3 км көньякка таба шушы автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көнбатыш чиге буйлап уза, көнбатышка таба 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 50 м сәнәгать объектының төньяк чиге буйлап бара, сынык сызык ясап, 150 м көньяк-көнчыгышка таба сәнәгать объектының көнчыгыш һәм көньяк чикләре буйлап уза, алга таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 20 м көнчыгышка таба һәм 100 м көньякка таба уза, 2,4 км профильле автомобиль юлы буйлап Казан – Оренбург автомобиль юлына кадәр бара һәм аның буенча 100 м төньяк-көнбатышка таба уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 200 м көньяк-көнбатышка таба, урман массивын кисеп үтеп, һәм 150 м, дамбаны кисеп үтеп, көньяк-көнчыгышка таба бара, шуннан соң көньяк-көнбатышка таба 1,8 км Казан – Оренбург автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 250 м Бөгелмә – Лениногорск автомобиль юлы буйлап «Бөгелмә шәһәре» муниципаль берәмлеге, Березовка һәм Вязовка авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Таллы Бүләк авылыннан 2,6 км көньякта урнашкан 44 нче тоташу ноктасына кадәр уза.»;

4) 9 нчы кушымтада:

а) бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Вязовка авыл җирлеге чиге Березовка авыл җирлеге белән чиктәш җирдә «Бөгелмә шәһәре» муниципаль берәмлеге, Березовка һәм Вязовка авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Таллы

Бүләк авылыннан 2,6 км көньякта урнашкан 44 нче тоташу ноктасыннан алып 2,5 км көнбатышка таба Бөгелмә – Лениногорск автомобиль юлы буйлап 11 нче тоташу ноктасына кадәр уза.»;

б) алтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Вязовка авыл җирлеге чиге «Бөгелмә шәһәре» муниципаль берәмлеге белән чиктәш җирдә 44 нче тоташу ноктасыннан алып 2,2 км көньяк-көнчыгышка таба Казан – Оренбург автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көнбатыш чиге буйлап Бөгелмә – Коногоровка автомобиль юлына кадәр уза, шушы автомобиль юлы буйлап 650 м төньяк-көнчыгышка таба бара, аннары 100 м көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап «Бөгелмә шәһәре» муниципаль берәмлеге, Вязовка һәм Зеленая Роща авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Забугоровка авылыннан 2,4 км төньяк-көнбатышта урнашкан 21 нче тоташу ноктасына кадәр уза.»;

5) 10 нчы кушымтада:

а) җиденче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Зеленая Роща авыл җирлеге чиге Кече Бөгелмә авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 22 нче тоташу ноктасыннан алып 1,8 км төньяк-көнбатышка таба Бөгелмә шәһәренең әйләнеп үтә торган автомобиль юлы буйлап кибеп баручы инешкә кадәр уза, аннары 890 м шушы инеш агымы буенча аска таба инешнең Казачья елгасына койган урынына кадәр уза, 60 м Казачья елгасы агымы буенча аска таба бара, шуннан соң төньяк-көнбатышка таба 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап һәм 540 м урман массивының көнбатыш чиге буйлап бара, аннары төньякка таба 60 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап һәм 400 м җиләк-җимеш бакчасының көнбатыш чиге буйлап «Бөгелмә шәһәре» муниципаль берәмлеге, Зеленая Роща һәм Кече Бөгелмә авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Забугоровка авылыннан 1,2 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 20 нче тоташу ноктасына кадәр уза.»;

б) сигезенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Зеленая Роща авыл җирлеге чиге «Бөгелмә шәһәре» муниципаль берәмлеге белән чиктәш җирдә 20 нче тоташу ноктасыннан алып 750 м көнбатышка таба, урман полосасын кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, шуннан соң көньякка таба 250 м урман полосасының көнбатыш чиге буйлап, 250 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, аннары 50 м көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, шуннан соң 500 м төньяк-көнбатышка таба буаның сул як яры буенча, 100 м Казачья елгасы агымы буенча өскә таба Казан – Оренбург автомобиль юлына

кадәр бара, алга таба шушы автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 700 м төньяк-көнбатышка таба уза, аннары шушы автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көнбатыш чиге буйлап төньякка таба бара, аннары 650 м көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, шуннан соң 200 м көньяк-көнбатышка таба Бөгелмә – Уральск автомобиль юлы буйлап бара, аннары төньяк-көнбатышка таба 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м «Бөгелмә урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Бөгелмә участок урманчылыгындагы 94 нче урман кварталының аерымланган кишәрлеге буйлап, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап урман массивын, урман полосасын һәм Куйбышев тимер юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп уза, шуннан соң төньяк-көнчыгышка таба 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 250 м урман массивы чиге буйлап бара, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 94 нче урман кварталы аерымланган кишәрлегенең көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 50 м уза, аннары, сынык сызык ясап, шушы урман кварталы аерымланган кишәрлегенең төньяк чиге буйлап 450 м көнбатышка таба, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 94 нче урман кварталы аерымланган кишәрлегенең төньяк чиге буйлап 100 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 50 м бара, алга таба, сынык сызык ясап, 94 нче урман кварталы аерымланган кишәрлегенең төньяк чиге буйлап 550 м төньяк-көнбатышка таба уза, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 94 нче урман кварталы аерымланган кишәрлегенең төньяк чиге буйлап 50 м бара, 750 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, «Бөгелмә шәһәре» муниципаль берәмлеге, Вязовка һәм Зеленая Роща авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Забугоровка авылыннан 2,4 км төньяк-көнбатышта урнашкан 21 нче тоташу ноктасына кадәр уза.»;

6) 13 нче кушымтада:

а) дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Кече Бөгелмә авыл җирлеге чиге Березовка авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Березовка, Кече Бөгелмә һәм Яңа Александровка авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Кече Бөгелмә авылыннан 150 м төньяк-көнчыгышта Зәй елгасы үзәнендә урнашкан 17 нче тоташу ноктасыннан алып 1,9 км Зәй елгасы агымы буенча өскә таба Бөгелмә елгасы белән кушылган җиргә кадәр уза, аннары 1,1 км Бөгелмә елгасы агымы буенча өскә таба «Бөгелмә

шәһәре» муниципаль берәмлеге, Березовка һәм Keче Бөгелмә авыл җирлекләре чикләре тоташкан җирдә Кече Бөгелмә авылыннан 100 м төньяк-көнбатышта Бөгелмә елгасы үзәнендә урнашкан 45 нче тоташу ноктасына кадәр бара.»;

б) унынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Кече Бөгелмә авыл җирлеге чиге Зеленая Роща авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 22 нче тоташу ноктасыннан алып 1,8 км төньяк-көнбатышка таба Бөгелмә шәһәренең әйләнеп үтә торган автомобиль юлы буйлап кибеп баручы инешкә кадәр уза, аннары 890 м шушы инеш агымы буенча аска таба инешнең Казачья елгасына койган урынына кадәр уза, 60 м Казачья елгасы агымы буенча аска таба бара, шуннан соң төньяк-көнбатышка таба 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап һәм 540 м урман массивының көнбатыш чиге буйлап бара, аннары төньякка таба 60 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап һәм 400 м җиләк-җимеш бакчасының көнбатыш чиге буйлап «Бөгелмә шәһәре» муниципаль берәмлеге, Зеленая Роща һәм Кече Бөгелмә авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Забугоровка авылыннан 1,2 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 20 нче тоташу ноктасына кадәр уза.»;

в) унберенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Кече Бөгелмә авыл җирлеге чиге «Бөгелмә шәһәре» муниципаль берәмлеге белән чиктәш җирдә 20 нче тоташу ноктасыннан алып, сынык сызык ясап, 350 м көнчыгышка таба күмәк бакчаларның төньяк чиге буйлап уза, шуннан соң 450 м төньяк-көнчыгышка таба урман массивы буйлап бара, аннары көньяк-көнчыгышка таба 450 м, Куйбышев тимер юлына бүлеп бирелгән полосаны һәм профильле автомобиль юлын кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, алга таба, сынык сызык ясап, 450 м көньяк-көнбатышка таба 96 нчы урман кварталының аерымланган кишәрлеге буйлап бара, аннары 100 м көньякка таба, буа плотинасын һәм Казачья елгасын кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, шуннан соң 500 м көньяк-көнбатышка таба, урман полосасын кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, 4,8 км көнчыгышка таба, урман массивын, агачлык-куаклык массивын, инешне, Зәй елгасын һәм яр буендагы агачлык-куаклык массивларын кисеп үтеп, Куйбышев тимер юлына бүлеп бирелгән полосаның төньяк чиге буйлап уза, шуннан соң 50 м төньякка таба бүлеп бирелгән полосаның көнчыгыш чиге буенча авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 900 м Куйбышев тимер юлына бүлеп бирелгән полосаның төньяк-көнбатыш чиге буйлап, текә ярны, инешне һәм урман массивын кисеп үтеп, Бөгелмә – Татар Димескәе автомобиль юлына кадәр бара, аннары 900 м төньяк-

көнбатышка таба шушы автомобиль юлы буенча бара, алга таба 900 м көньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, инешне һәм аның текә ярларын, профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 50 м профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көньяк-көнчыгыш чиге буйлап буага кадәр уза, 400 м көньякка таба буаның уң як яры буйлап уза, 1,9 км төньяк-көнчыгышка таба буаның сул як яры буйлап, профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, буа плотинасына кадәр бара, аннары, сынык сызык ясап, 500 м төньякка таба, Бөгелмә – Татар Димескәе автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, аннары 400 м төньяк-көнбатышка таба шушы автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның төньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, 700 м төньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, юл буендагы урман полосасын кисеп үтеп, профильле автомобиль юлына кадәр уза, алга таба 400 м төньяк-көнбатышка таба шушы автомобиль юлы буйлап бара, 1,0 км төньяк-көнчыгышка таба Бөгелмә – Ютазы автомобиль юлы буйлап уза, аннары 50 м төньякка таба күмәк бакчаларның көнбатыш чиге буйлап бара, 50 м төньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, тирән чокырны кисеп үтеп, 45 нче тоташу ноктасына кадәр уза.».

**3 статья**


Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 елның 22 июле
№ 71-ТРЗ

“Аерым муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен үзгәртү һәм “Бөгелмә муниципаль районы” муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында” Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында” Татарстан Республикасы Законына кушымта

Муниципаль берәмлекләр чикләренең үзгәрешләр исәпкә алынган
**карта-схемасы**




**Шартлы билгеләр**

-муниципаль берәмлекләрнең чикләре

- җирлекнең административ үзәге

-торак пунктлар

А-Б - Зеленая Роща авыл җирлеге һәм “Бөгелмә шәһәре” муниципаль берәмлеге чиктәш чиге

Б-В - Кече Бөгелмә авыл җирлеге һәм “Бөгелмә шәһәре” муниципаль берәмлеге чиктәш чиге

В-Г - Березовка авыл җирлеге һәм “Бөгелмә шәһәре” муниципаль берәмлеге чиктәш чиге

-Бөгелмә муниципаль районы Зеленая Роща авыл җирлегенең Бөгелмә муниципаль районы “Бөгелмә шәһәре” муниципаль берәмлеге составына кертелә торган территориясе

-Бөгелмә муниципаль районы Кече Бөгелмә авыл җирлегенең Бөгелмә муниципаль районы “Бөгелмә шәһәре” муниципаль берәмлеге составына кертелә торган территориясе

-Бөгелмә муниципаль районы “Бөгелмә шәһәре” муниципаль берәмлегенең Бөгелмә муниципаль районы Кече Бөгелмә авыл җирлеге составына кертелә торган территориясе

-Бөгелмә муниципаль районы Березовка авыл җирлегенең Бөгелмә муниципаль районы “Бөгелмә шәһәре” муниципаль берәмлеге составына кертелә торган территориясе

# III
# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ РӘИСЕ КҮРСӘТМӘЛӘРЕ

## 981. ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ РӘИСЕ КҮРСӘТМӘСЕ

### В.Х. Вәлиеваны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында

Әлмәт муниципаль районының социаль-икътисадый үсешенә зур өлеш керткән өчен Әлмәт муниципаль районының «Әлмәт монтаж һәм наладка идарәсе» ябык акционер җәмгыятенең генераль директоры Винера Хәмзә кызы Вәлиеваны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2013 елның 1 июле
№ 429-РК

## 982. ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ РӘИСЕ КҮРСӘТМӘСЕ

### Т.М. Фаринаны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында

Республиканың сәламәтлек саклау системасы үсешенә зур өлеш керткән өчен Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы Эшләр идарәсенең гомуми бүлеге башлыгы Тәнзилә Мансур кызы Фаринаны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2013 елның 3 июле
№ 438-РК

## 983. ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ РӘИСЕ КҮРСӘТМӘСЕ

### Л.М. Галиәкбәрованы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында

Татарстан Республикасының сәламәтлек саклау системасы үсешенә зур өлеш керткән өчен Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының юридик бүлеге әйдәп баручы консультанты Лилия Миңнәхәт кызы Галиәкбәрованы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2013 елның 3 июле
№ 439-РК

## 984. ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ РӘИСЕ КҮРСӘТМӘСЕ

### Г.Ю. Дмитриеваны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Икътисадый анализ һәм фаразлау идарәсенең бюджет акчалары буенча икътисадый анализ бүлеге башлыгы Дмитриева Галина Юрьевнаны республиканың сәламәтлек саклау системасы үсешенә зур өлеш керткән өчен Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2013 елның 3 июле
№ 440-РК

## 985. ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ РӘИСЕ КҮРСӘТМӘСЕ

### И.Н. Барановыны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында

Татарстан Республикасының сәламәтлек саклау системасы үсешенә зур өлеш керткән өчен Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы «Республика суд-медицина экспертизасы бюросы» ССДАУ идарәсенең автоматлаштырылган системалар бүлеге электрон-исәпләү һәм исәпләү машиналары операторы  Баранова Ирина Николаевнаны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2013 елның 3 июле
№ 441-РК

## 986. ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ РӘИСЕ КҮРСӘТМӘСЕ

### О.А. Осиповны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында

Татарстан Республикасының сәламәтлек саклау системасы үсешенә зур өлеш керткән өчен Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Эшләр идарәсе секретариаты 1 категорияле белгече Оксана Анатольевна Осипованы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2013 елның 3 июле
№ 442-РК

## 987. ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ РӘИСЕ КҮРСӘТМӘСЕ

### С.И. Шәрифуллинаны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында

Чистай муниципаль районы Иске Роман авыл җирлегенең социаль-икътисадый үсешенә зур өлеш керткән өчен Чистай муниципаль районының Иске Роман авыл җирлеге башлыгы Суфия Ибраһим кызы Шәрифуллинаны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2013 елның 3 июле
№ 443-РК

## 988. ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ РӘИСЕ КҮРСӘТМӘСЕ

### Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты М.Ә. Гаделшин тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасы Бюджет кодексына һәм Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 513-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын (бюджет процессын камилләштерү өлешендә) алдан карау хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Регламентының 87 статьясы нигезендә:

1. «Татарстан Республикасы Бюджет кодексына һәм Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 513-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын, закон проекты буенча җаваплы итеп билгеләп, Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Бюджет, салымнар һәм финанс комитетына, депутат берләшмәләренә алдан карау өчен, шулай ук Татарстан Республикасы Хисап палатасына бәяләмәгә һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппаратының Хокук идарәсенә юридик экспертизага җибәрергә.

2. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Бюджет, салымнар һәм финанс комитеты  әлеге закон проектын 2013 елның 2 сентябренә кадәр Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан беренче укылышта карауга әзерләргә тиеш.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2013 елның 5 июле
№ 453-РК

## 989. ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ РӘИСЕ КҮРСӘТМӘСЕ

### Н.М. Якушкинны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында

Вазыйфаи бурычларын мактауга лаеклы башкаруы һәм дәүләт хакимияте органнарында озак еллар хезмәт эшчәнлегендә ирешкән югары уңышлары өчен Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры урынбасары Якушкин Николай Михайловичны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2013 елның 6 июле
№ 454-РК

## 990. ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ РӘИСЕ КҮРСӘТМӘСЕ

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты В.Н. Липужина тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 514-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын (җирле әһәмияттәге мәсьәләләргә территориаль оборонаны гамәлгә ашыру һәм реклама конструкцияләрен урнаштыру схемаларын раслау мәсьәләләрен өстәү өлешендә) алдан карау турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Регламентының 87 статьясы нигезендә:

1. «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 514-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын, закон проекты буенча җаваплы итеп билгеләп, Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Дәүләт корылышы һәм җирле үзидарә комитетына, депутат берләшмәләренә алдан карау өчен, шулай ук Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты Хокук идарәсенә юридик экспертизага җибәрергә.

2. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Дәүләт корылышы һәм җирле үзидарә комитеты күрсәтелгән закон проектын 2013 елның 27 сентябренә кадәр Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан беренче укылышта карауга әзерләргә тиеш.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2013 елның 9 июле
№ 459-РК

## 991. ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ РӘИСЕ КҮРСӘТМӘСЕ

Балык Бистәсе муниципаль районы Советы тарафыннан кертелгән «Балык Бистәсе муниципаль районының Олы Елга һәм Сорочьи Горы авыл җирлекләрен үзгәртеп кору һәм «Балык Бистәсе муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 515-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын (җирлекләрне берләштерү өлешендә) алдан карау хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Регламентының 87 статьясы нигезендә:

1. «Балык Бистәсе муниципаль районының Олы Елга һәм Сорочьи Горы авыл җирлекләрен үзгәртеп кору һәм «Балык Бистәсе муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 515-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын, закон проекты буенча җаваплы итеп билгеләп, Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Дәүләт корылышы һәм җирле үзидарә комитетына, депутат берләшмәләренә алдан карау өчен, шулай ук Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты Хокук идарәсенә юридик экспертизага җибәрергә.

2. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Дәүләт корылышы һәм җирле үзидарә комитеты күрсәтелгән закон проектын 2013 елның 27 сентябренә кадәр Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан беренче укылышта карауга әзерләргә тиеш.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2013 елның 9 июле
№ 460-РК

## 992. ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ РӘИСЕ КҮРСӘТМӘСЕ

### Р.Г. Йосыповны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында

Балтач муниципаль районының социаль-икътисадый үсешенә зур өлеш керткән өчен Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Смәел авыл җирлеге башлыгы Рифнур Гайнан улы Йосыповны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2013 елның 19 июле
№ 495-РК

## 993. ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ РӘИСЕ КҮРСӘТМӘСЕ

### Ә.Б. Мирхәйдәровны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында

Татар мәдәниятен үстерүгә һәм саклап калуга зур өлеш керткән өчен «Дуслык» халык ансамбленең сәнгать җитәкчесе Әбделхәким Барый улы Мирхәйдәровны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2013 елның 24 июле
№ 505-РК

## 994. ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ РӘИСЕ КҮРСӘТМӘСЕ

### Ә.Ә. Мирхәйдәрованы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында

Татар мәдәниятен үстерүгә һәм саклап калуга зур өлеш керткән өчен «Дуслык» халык ансамбленең концертмейстеры Әсмабикә Әсмәт кызы Мирхәйдәрованы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2013 елның 24 июле
№ 506-РК

## 995. ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ РӘИСЕ КҮРСӘТМӘСЕ

### Е.В. Кузьминаны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында

Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсешенә зур өлеш керткән өчен Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты Оештыру идарәсенең Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Икътисад, инвестицияләр һәм эшкуарлык комитеты эшчәнлеген тәэмин итү бүлеге мөдире Елена Викторовна Кузьминаны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2013 елның 25 июле
№ 511-РК

## 996. ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ РӘИСЕ КҮРСӘТМӘСЕ

### «Кулонстрой» ЯАҖ хезмәткәрләрен Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында

Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсешенә зур өлеш керткән өчен «Кулонстрой» ябык акционер җәмгыятьнең түбәндәге хезмәткәрләрен Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләргә:

| | |
|---|---|
| капиталь төзелеш бүлеге башлыгы | Нәбиуллин Рамил Кави улын; |
| баш экономист | Газизова Лилия Мансур кызын; |
| автотранспорт диспетчеры | Мөхәммәдияров Ирек Миннегали улын. |

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2013 елның 25 июле
№ 512-РК

## 997. ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ РӘИСЕ КҮРСӘТМӘСЕ

### И. Ю. Әминовны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында

Татарстан Республикасының социаль-икътисадый һәм мәдәни үсешенә зур өлеш керткән өчен «Яңа Гасыр» телерадиокомпаниясе» ачык акционер җәмгыять генераль директоры Илшат Юныс улы Әминовны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2013 елның 26 июле
№ 515-РК

## 998. ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ РӘИСЕ КҮРСӘТМӘСЕ

### Н.Н. Гаяновны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында

Мамадыш муниципаль районының социаль-икътисадый үсешенә зур өлеш керткән өчен Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Келәүш авыл җирлеге башлыгы Назыйм Нурми улы Гаяновны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасары**
**А.П. Гусев**

Казан шәһәре,
2013 елның 30 июле
№ 524-РК

## 999. ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ РӘИСЕ КҮРСӘТМӘСЕ

### В.В. Мошковны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында

Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсешенә зур өлеш керткән өчен «Алексеевск аграр колледжы» УҺБ ДАМУ филиалы мөдире Василий Васильевич Мошковны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2013 елның 31 июле
№ 526-РК